PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№2 (314) – ФЕВРАЛЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Мәскәү мәктәбе: татарча өйрәнәбез

Резеда Ганиева: «Талантлы кешеләрне һәрчак яклыйсым килде»

Ташка уелган хәбәрләр

ЗИФА КАДЫЙРОВАДАН – БИШБАРМАК!

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Эльнар Байназаров, Гадел Хәеров,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: язучы Зифа Кадыйрова.
Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: **3500** данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-308

Басарга кул куелды: 22.02.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Коммерция бүлеге белгече:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ДӘРВИШЛӘР БИСТӘСЕ – ЧЕМПИОННАР ВАТАНЫ!

Февральнең бездән башка да җылы сүз белән искә алучылар табылачак традицион бәйрәмнәрен онытып торып, ниләр белән хәтердә калуын искә төшерик әле. Татарстанлылар аны, әлбәттә, чып-чын кышкы бураннар һәм җиңүләр белән хәтерендә саклар. Соңгы егерме ел эчендә телдән төшмәгән глобаль җылыну турында ай буе ник кемдер искә алсын. Буран көртләре республиканы күмеп узды да кышның нинди булырга тиеш икәнен күрсәтте безгә. Чын Россия кышы башкача була да алмый – ул йортларны да, машиналарны да, кешеләрне дә баштанаяк күмеп китәргә тиеш. Әнә шул кырыслыгы белән Олимпия чемпионнарын да сынмаска, сынатмаска өйрәткән инде безнең табигать. 2018 елгы җиңүчеләр арасында татарстанлыларның булуы чиксез куандыра. Дәрвишләр бистәсе бездән дә ныграк куанадыр, мөгаен. Казанның әлеге бистәсе исеме телдән төшми хәзер – ул фигуралы шуу буенча команда ярышларында көмеш медаль иясе булган Евгения Тарасованың ватаны бит. Спортчы парлар арасындагы ярышлар вакытында партнеры Владимир Морозов белән дүртенче урынга калуларына көендек, билгеле. Әмма Дәрвишләр бистәсе ул арада инде дан казанып өлгергән иде – дөньядагы массакүләм мәгълүмат чараларының искә алулар рейтингын шактый бизәде ул. Димәк, Евгенияне дә, Дәрвишләр бистәсен дә чын күңелдән котлыйбыз!

Дәрвишләр бистәсе нинди генә кар-бураннарны күрмәгән дә, аларны ничек кенә башыннан кичмәгән. Чемпионнар тәрбияләгән кече ватаныбыз белән горурланырга була бу айда. Безнең җиңүләр әле алда!

ҮЗЕНЕКЕЛӘР ӨЧЕН ҺӘРВАКЫТ УТ ЙОТЫП ЯШӘҮЧЕ РЕДАКЦИЯГЕЗ.

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Рамил Әбүбәкеров. «Кышкы иртә». Саба районы, Сатыш авылы.

ФЕВРАЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Мәскәү мәктәбе. Татар акценты.
Мәскәү татарлары туган телләрен кайда өйрәнәләр

10. Бөтен галәм бер күзәнәктә.
Атом энергиясенең романтикасы нидә

13. Татарстан әтиләре
Коткарылган 34 тормыш

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

22. Кухня.
Зифа Кадыйровадан – бишбармак!

26. Фотопроект.
Кышкы матурлык

34. Сәер базар.
Китап фанатлары

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

40. Кече ватан патриотлары.
Казанда Шаляпин эзләре кайда саклана

48. Резеда Ганиеваның тормыш линиясе.
«Фән ул – объективлык дигән сүз»

52. Төрки каганат.
Ташка уелган хәбәрләр

56. Китап киштәсе.
Тынлыкка сусау, яки Чынбарлыкның җайсыз кешеләре

84. Татар авыллары.
Сатыш: бүтәнчә яшәү

88. Татарстан риваятьләре.
Гәрәй талы басуындагы фаҗига

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

25.01

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – Казанда, студентлар клубларының «Бергәләп алга!» Бөтенроссия белем бирү форумында катнашучыларга мөрәҗәгать итеп:

– Сез – яңа чорда туып-үскән кешеләр. Элегрәк туып-үскәннәр белән чагыштырганда мөмкинлекләрегезнең бик зур булуына ышаныгыз. Бернәрсә турында да уйламыйча, бүген үк рәхәтләнеп яңа мода, яңа музыка, яңа сәнгать, яңа технологияләр тудыра аласыз. Хаталардан курыкмагыз, һәрчак аларны җиңеп чыгу, үзегез өчен кулай юлларны эзләгез, һәм шул вакытта сез, һичшиксез, бәхетле, булдыклы буын булырсыз. Мин сезгә ихластан шуны телим. Уңышлар сезгә!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

5.02

Владимир Васильев, Дагыстан Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, – Махачкалада, Татарстан Республикасы белән Дагыстан Республикасы арасында Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү имзалаганнан соң:

– Алда барганнардан һәрвакыт өйрәнергә, үрнәк алырга кирәк, дип саныйм. Бүген инде хезмәттәшлек дәрәҗәсенә җитә торган тәкъдимебезгә колак салганнары өчен Татарстан Президенты һәм аның коллегаларына рәхмәтлемен. Без сәүдә мәйданчыгы турында сөйләштек. Бу бик мөһим. Татарстан үз бюджетын шундый итеп контрольдә тота ки, безгә аннан өйрәнергә кирәк. Алар 100 гә якын күрсәткечне кертеп, бюджет акчаларының тотылышын турыдан-туры вакыт режимында күзәтә. Безгә бу нәрсә җитешеп бетми.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

24.01

Сергей Когогин, «КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры, – «Бигеш» аэропортында «Дакар-2018» раллие җиңүчесе «КАМАЗ-мастер» командасын каршы алганда:

– Сезнең җиңү белән кайтачагыгызга без ышандык, ләкин мин шунысын төгәл әйтә алам: сезне монда һичкайда булмаганча көттеләр. Сез өегезгә кайттыгыз! «КАМАЗ-мастер» узышчылары дөнья осталары белән безнең өчен ярышып, үзләрен дә, трассаны да һәм көндәшләрне дә җиңәләр.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Мәскәү мәктәбендә татарчага **НИЧЕК** өйрәтәләр

Атом энергиясенең романтикасы **НИДӘ**

Татарстан әтиләре балаларын **НИЧЕК** тәрбияли

PRESSA.RU

МӘСКӘҮ МӘКТӘБЕ: ТАТАРЧА ӨЙРӘНӘБЕЗ

Такси Люблинога килеп керә. Люблино – Мәскәүнең көнчыгышында урнашкан, нигездә тугыз катлы, яки аннан да биегрәк соры йортлардан тора ул. Кыяфәте буенча Казанның Горки тирәләренә охшаган. Муса Җәлил исемендәге 1186нчы мәктәп, ягъни Россия башкаласында ачылган беренче татар мәктәбе, нәкъ шушы, кайчандыр үзе дә аерым бер шәһәрчек булган бистәдә урнашкан.

Автор:
Эльнар Байназаров

HABIBRAKHMAN, PLEASE*

Мәктәпнең ишекләре өстендә – татарстанлылар өчен гадәти булган «Рәхим итегез!» транспаранты, ә ишегалдында килгән һәркемне Җәлил бюсты каршы ала. Ишектән атлап керү белән үк сакчы постында утыручы ханым белән: «Исәнмесез, директорны каян табып була?» – дип, сүземне татарча башлыйм. Ханым балкып елмая, ләкин җавабын рус телендә кайтара: «Не надо искать, я вас проведу к директору». Сакчы вазыйфасын башкаручыларны мин байтак кына уку йортларында күреп өлгердем, алар арасында төрлесе бар, ләкин әлеге мәктәптәге ханымны бер күрүгә туганым шикелле үз иттем. Ул да мине, татар телендә эндәшүчене, каяндыр адашып килеп кергән дә, үз өен эзләп тапкан баланы каршылагандай, бик җылы кабул итте.

Муса Җәлил исемен йөртүче 1186 нчы мәктәпнең төп үзенчәлеге – уку программасында татар милли компоненты каралган. Һәм әлеге милли компонент үз чагылышын барлык өлкәләрдә дә тапкан: математика дәресе булсынмы ул (әйтик, мәсьәләләр болайрак корылган: «Хуҗа Насретдинның алмалары шулкадәр булган, әгәр фәлән алманы алып куйсак, Хуҗа Насретдинның ничә алмасы кала?»), география дәресеме (коридорда балалар үз куллары белән ясаган Татарстан карталары эленгән), инглиз телеме (мәктәпнең юбилее уңаеннан укучылар Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын Шекспир теленә тәрҗемә итеп сәхнәләштергән, баш рольне башкарган егеткә аннары бөтен мәктәп «Habibrakhman, please» дип эндәшә башлаган хәтта).

1-4 нче сыйныфларга атнага бер дәрес күләмендә татар теле керә. Бер генә дәрес күләмендә булса да, тел мәҗбүрилек статусын саклый алган. Прокурор тикшерүләре бередә федераль кануннарга каршы килгән бернәрсә дә тапмаган, татар мәктәбендә рус теле дә нәкъ Мәскәүнең башка мәктәпләрендәге күләмдә укытыла.

5 нче сыйныфтан башлап, туган тел урынына махсус проект эшчәнлеге кертелә – укучылар әлеге дәрес кысаларында мөстәкыйль әзерләгән проектларын камилләштерергә, аны публика алдында якларга өйрәнә. Бердәнбер таләп – эшең Татарстан яки татар теле белән бәйле булырга тиеш. Проектларның күпчелеге этнография, гуманитар фәннәр өлкәсенә карый (әйтик, гаилә шәҗәрәсен төзү, Каюм Насыйри иҗатын тәфсилләп өйрәнү һ.б.), шулай ук IT-проектлар да бар.

Милли компонент бүтән өлкәләрдә дә чагыла. Мәктәптә ел саен үткәрелә торган милли көрәш турниры моңа ачык мисал. Кайчандыр уку йорты диварларыннан үтеп чыкмаган әлеге ярыш – бүген Муса Җәлил исемен йөртүче төбәк дәрәҗәсендәге абруйлы турнир. Моңа ирешү өчен мәктәпнең күптәнге дусты, Мәскәүнең Көньяк-көнчыгыш административ округының элеккеге җитәкчесе Владимир Зотов күп көч куя, көрәшчеләр өчен махсус зур келәм дә – аның бүләге.

ҖЫЙНАК. УҢАЙЛЫ. ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

1186 нчы мәктәп мөстәкыйльлеген саклап калган уку йортларының берсе. Нинди мөстәкыйльлек дигәндә, Мәскәүдә 2012 елдан алып бер кварталда урнашкан мәктәпләрне эре комплексларга кушу программасы башкарыла. Дүрт ел эчендә бу программа кысаларында башкаладагы мәктәпләр саны икеләтә кими – программада теркәлгән 1572 мәктәптән 2016 елга нибары 700е генә кала. Әлеге эреләндерүләрнең уңай ягы (әйтик, алдынгы мәктәпкә берничә уртачасын кушу белән уку сыйфаты үсә, укытучылар арасында конкуренция барлыкка килә) белән беррәттән, тискәре яклар (киңәйгән уку комплексында директор белән педагогик коллектив арасында рәсми, абстракт аралашу барлыкка килә, чикләр туа, ата-аналар белән булган элемтәләр дә йомшый) да күзәтелә.

Татар мәктәбенә әлегә тимәскә булалар. Бүгенге көндә биредә 441 бала укый, бөтен укытучыларның да эш урыннары сакланып

Фотолар: Эльнар Байназаров

* Хәбибрахман, плиз

калган. Шуңадыр, бәлки, «мәктәбегезне тасвирлагыз әле» дигән сорауга бөтенесе диярлек җавабын «җыйнак», «уңайлы», «үзебезнеке» кебек сүзләрдән башлады.

Мәскәүдәге реформаның төп үзенчәлеге – дәүләт тарафыннан өләшелгән матди ярдәм күләме хәзер турыдан-туры укучылар санынан исәпләнә. Бу мантыйк буенча фикер йөртсәк, татар мәктәбенең чагыштырмача мөстәкыйльлеге, димәк, аның чагыштырмача фәкыйрьлегенә дә сәбәп, дигән сүз. Ләкин әлеге мәктәп логик күзаллауларны тулаем җимереп ташлый. Ул тулысы белән заманча җиһазландырылган, һәр бүлмәдә диярлек интерактив такта, ноутбук бар, укытучыларның айлык хезмәт хакы да Мәскәү стандартларына ярашкан – 65-70 мең. Мәктәптә өч музей – татар разведчикларының мирасын өйрәнүгә багышланган махсус разведка, дөнья халыклары мәдәнияте, татар милли гореф-гадәтләре музейлары эшләп килә.

КАЗАН – КИЛӘЧӘК ЭШЕМЕ?

Татарстан белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, алар бар һәм шактый гына сизелә. Мәктәп эчендә йөргәндә, берәр татар әдибенең үткен карашы астына эләкмичә калу мөмкин түгел – сурәтләре һәр диварда диярлек. Хәер, дивардагы ул әдипләр мәктәптәгеләрнең рус әдипләре телендә аралашуын берничек тә төзәтә дә, кисәтә дә алмый, күзәтә генә.

Матди ярдәмгә килгәндә, 2011 елда мәктәпкә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов килеп киткәннән соң, татар телле уку йортына интерактив такталар, ике автобус, китапханәне тулыландырыр өчен 1 мең данә татар китабы бүләк ителгән. КФУның да мәктәпкә битараф булмавы сизелә, Казан лабораторияләре белән видеоконференцияләр үткәрү өчен махсус бүлмәләр булдырылган биредә. Балалар 850 км ераклыктагы университетта укылган кызыклы лекцияләрне мәктәптән чыкмыйча гына карый һәм тыңлый ала.

Мәктәпне тәмамлаучылар нигездә Мәскәү, Санкт-Петербург вузларына укырга керә, чит илләргә дә китүчеләр бар, статистика мәгълүматларына ышансак, аларны күбрәк Европа, Согуд Гарәбстаны илләре тарта. Ә Казанга килүчеләр бармы, дип кызыксындым укытучылардан һәм директордан. Табигый сорау бит, югыйсә: милли мохиттә телне дә яхшырак үзләштерергә була, үз халкыңа якынрак та буласың, дигәндәй. Ни хикмәт, Казан уку йортларын әлегә берсе дә сайламаган. Бәлки, монысы киләчәк эше булыр, Татарстан башкаласы үсә, үзгәрә, үзенә бик күпләрне җәлеп итә бит хәзер.

ТАТАР ТЕЛЕ – LINGUA FRANCA** РОЛЕНДӘ

– Мәскәүнең постсовет тарихындагы беренче татар мәктәбе үз ишекләрен 1997 елда ачып җибәрде, – дип сөйләде безгә аның директоры Роза Шакирова. Ул әңгәмәбезне баштан ук Тукай телендә башлап җибәрде, аның «балигъ», «зарур» ише мин инде онытарак төшкән сүзләрдән корылган йөгерек сөйләме шунда ук әсир итте. Сөйләме җирле татарларныкыннан (сүз Мәскәү татарлары турында бара, әлбәттә – авт.) шактый аерылып тора, дип уйлап куйдым. Баксаң, Роза ханым Нижгар өлкәсеннән икән. Ул гаиләсендә дә гел татарча гына сөйләшә булып чыкты. Мәктәп үзе рәсми рәвештә 1997 елда ачылса да, аның тарихы да нәкъ менә шул елда башланган дип исәпләү бик үк дөрес булмастыр. «Ул тарих тамырлары белән гасыр башына ук барып тоташа», – дип ассызыклады Роза ханым.

1913 елда Баку нефтьчесе Шәмси Асадуллаев Иске мәчет тирәсендә (Третьяков галереясыннан 20 минут ераклыкта урнашкан) башкаладагы беренче татар мәктәбен ача. Мәктәп ул чакта шәхси булып, тулысы белән рус, француз мәктәпләренә охшатып ясалса да, биредә ислам тәртипләре хөкем сөрә. Уку теле итеп ул вакытта Россия мөселман-

**Лингва франка

PRESSA.RU

Мәктәп ул чорда шәхси булып, тулысы белән рус, француз мәктәпләренә охшатып ясалса да, биредә ислам тәртипләре хөкем сөрә. Уку теле итеп ул вакытта Россия мөселманнарының lingua franca вазыйфасын үтәгән татар теле билгеләнә.

нарының lingua franca вазыйфасын үтәгән татар теле билгеләнә. Мәктәп үз эшен 1941 елга кадәр алып бара, сугыш башлану белән бинаны госпиталь урнаштырыр өчен алалар (ул чакта башка Мәскәү мәктәпләре дә бу язмышны уртаклаша – авт.). Сугыш бетүгә, бинада Тышкы эшләр наркоматы хезмәткәрләре өчен – тулай торак, аннары стенографисткалар көллияте ачалар.

Сталин исән чакта бинаны кайтару турында сүз дә чыкмый. Җепшеклек чоры җитүгә, милли телләргә карата да мөнәсәбәт үзгәрә башлый. Якуб Чанышев КПСС Үзәк комитетына ачык хатлар яза: «80 мең татар яшәгән башкалада татарларны мәктәпсез калдырдылар, кайтарыгыз!» ди. Ләкин бинаны кайтармыйлар гына түгел, бөтен Иске мәчет тирәсен биш катлы йортлар белән уратып алалар, мәчетнең югары манарасын шартлаталар, ә эчендә военкомат ачалар. Кайчандыр юлбашчы башлап җибәргән милли мәктәпләрне ябу сәясәте, ахыр чиктә, Хрущевның 1958 елдагы милли мәгарифнең мәҗбүри була алмавын, уку телен сайлау иреген чикләүне нигез иткән кануннарга китерә.

90НЧЫ ЕЛЛАР ДИПЛОМАТИЯСЕ ҺӘМ НУЛЕНЧЕ ЕЛЛАР СТРАТЕГИЯСЕ

Асадуллаев йортының кире татарларга кайтарылуы – фәкать 90нчы елларның дипломатиясе һәм нуленче елларның уңышлы стратегиясе үрнәге генә. Ул елларда бу мәсьәлә федераль дәрәҗәдә хәл ителә, Татарстан җитәкчелеге катнашыннан башка алай тиз чишелмәс иде дә, бәлки. Ул елларда татарлар, совет чорында үз мәктәпләрен җуйган яһүдләр кебек, Мәскәү хакимиятеннән татар мәктәпләре булдыруын таләп итә башлагач, башкаланың берничә уку йортында татар класслары ачыла. Иң беренче класслар 28нче (хәзерге 1650нче) мәктәптә ачыла. Бу мәктәп һәр якшәмбе саен милли татар мәктәбенә әйләнә.

– Укучылар күп булды, укытучылар без идек, – дип, Роза ханым сүзен дәвам итә. – Шәрыкны өйрәнүчеләр – Урал Шәрипов һәм Гөлсем Галимова укучыларга борынгы татар телен, рун язуларына кадәрге әлифбаны, иске имляны өйрәттеләр. Венера Хәбибуллина, минем әнием һәм Нәзифә Кәримова (ул вакытта «Азатлык радиосы» хәбәрчесе) бүгенге кулланылыштагы заманча татар телен өйрәттеләр. Бераздан якшәмбе класслары гына безгә тар була башлады. Укырга теләүчеләр байтак, ә буш урындыкларга, такталарга кытлык. Шунда ата-аналар, актив укытучылар Мәскәү хакимиятенә ачык хатлар юллый башлады. «Яһүдләрнең үз мәктәпләре бар, алар тыныч кына үз телен укыта, әрмәннәрнең, грузиннарның, хәтта норвегияләрнең дә үз милли мәктәпләре бар, ә татарларныкы – юк...» Хатларның эчтәлеге әнә шундыйрак иде. Берничә ачык хаттан соң, безгә 66нчы номерлы кечкенә мәктәпнең беренче катын билгеләделәр.

90нчы елларда бөтен Мәскәү татарлары, ниһаять, башкалада татар мәктәбен булдыру идеясе тирәсенә берләште. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россия башкаласында яңадан татар мәктәбе ачылуга күп көч куйды. Ул чакта Лужков та, аның командасы да милли мәсьәләләргә уңай караштa иде. Махсус шартнамә төзелде, ул шартнамәгә нигезләнеп, татарларга, ниһаять, Люблинода үз мәктәпләрен ачарга рөхсәт бирелде. Ни өчен Люблино, дисезме? Биредә ташландык балалар бакчасы бинасы бар иде. Әмма эш булган бинаны ремонтлап керүгә генә калган икән, ул инде яртылаш эшләнгән, дигән сүз.

Мин директор бүлмәсен күзәтәм. Диварларда – Татарстанның классик тезмәсе – РФ Президенты Владимир Путин, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев сурәтләре. Янәшә диварда исә Россия мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдин сурәте эленгән – Диния нәзарәте мәктәп белән тыгыз элемтәдә тора, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша икән. Әйтергә кирәк, мөфтиләр шурасының беренче урынбасары Рушан Аббясов та, балалары татар телен укы-

сын өчен, гаиләсе белән мәктәпкә якынрак күчеп урнаша.

Зур һәм якты бүлмәнең диварлары миндә һичнинди хафалы (ә бит бу директор бүлмәсе!) уйлар кузгатмый. Әлеге тәэсирләремне Роза ханымга җиткерәм, ул елмая.

– Мәктәбебездә нибары 441 бала укый, һәрберсенә исеме белән эндәшә алам. Балалар минем алар яклы икәнемне абайлый, бу шулай булырга тиеш тә. Ышанычын яуламый торып, бала белән уңышлы эшләү мөмкин түгел. Бездә бар да гади, ясалма кыенлыкларсыз – мине, мәсәлән, кочаклап була.

Шулвакыт директор бүлмәсенә бер укытучы ханым килеп керде, алар тыныч кына бер-берсе белән сөйләшеп алдылар. Мин Роза ханымның җавапларын абайлап өлгерәм: «Ә, теге безгә яңарак кына күчеп килгән егетме... Тәрбияле, максатына ирешә белгәнгә охшаган. Аның әле каратэ белән дә мавыгуы безгә горурлык кына китерәчәк, Алла боерса...» Менә шулай җентекләп якын киләләр укучыларны кабул итү мәсьәләсенә бу мәктәптә.

– Бездә барлык укытучылар да татар телендә сөйләшми, шуңа җыелышларыбыз да нигездә рус телендә уза, һәркем аңласын өчен, әлбәттә. Ә «исәнмесез», «рәхмәт», «апа», «абый»ны аңламаган кеше бездә бөтенләй юк. Зур горурлыгыбыз – бездә 35 милләт баласы укый, ләкин нинди генә милләт вәкиле булмасын, бала монда беренче тапкыр «исәнмесез»не өйрәнә, өйрәнә дә актив рәвештә куллана башлый.

БЕЗ – ГАДӘТИ ДӨНЬЯВИ МӘКТӘП, ЯЛГЫШМАСЫННАР!

– Баштарак без тулысынча татар телле мәктәп булыр дип күзалладык, баласының телен саклап калырга теләгән ата-аналарны көттек. Әмма андыйлар ташкын булып агылмады. Бүгенге көндә мәктәптә укуаралашу нигездә рус телендә алып барыла, татар телендә аралашу, кызганычка каршы, җитеп бетми. Татар мәктәбенә үз балаларын Урта Азия, Кавказ, гарәп илләреннән килгән ата-аналар да китерә. Безнең мәктәпне «мөселманнар мәктәбе» дип ялгыш кабул итүчеләр дә бар, әмма без дини кануннардан ерак. Без – заманча, гадәти дөньяви уку йорты. Кайчак кайбер балаларның рус телен белү дәрәҗәсе бик түбән була: бала ике сүзне бер сүзтезмәгә дә куша алмый. Андыйларга татар теле ярдәмгә килә. Димәк, татар теле, нәкъ гасыр башындагы кебек, төрки халыкларның үзара аралашу ысулы булуын дәвам итә әле, – дип сөйләде Роза Шакирова.

Татар мәктәбенә килүем елына берничә тапкыр үткәрелә торган Милләтләр фестиваленә туры килде. Өч этаптан торучы бу бәйге мәктәпнең бөтен классларында үткәрелә. Беренче этап – җыр бәйгесе, менә ике үзбәк егете матур яшел камзулдан халык җырын башкара, менә яшь кенә кыз җитәкчесе белән «Туган тел»нең соңгы куплетын кабатлый. «Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм, әнкәмне, Ходам...» – әлеге гади, үтә дә таныш, кадерле сүзләрдән никтер күңел тула, тамакка төер утыра.

P.S. Мәктәп ишекләрен ябып, чыгып барганда артымда укучыларның «Сау булыгыз!» дигәнен ишетәм. Нәкъ өйдәгечә, иялəшкәнчә, озын «а» яңгырый башта, әмма азакта аны безнеңчә үк яңгырап бетми торган «ы» күмеп китә. Мин бу кадерле булып өлгергән бинадан каршылыклы тәэсирләр өермәсендә чыгам. Ә аннары, юлда барганда, аның барлыгына сөенү күңелнең бер почмагын яктыртып, җылытып җибәрә.

PRESSA.RU

ГУМАНИСТ ИСЕМЕНДӘГЕ АУДИТОРИЯ

Узган меңьеллык студентлары 15 февральдә Казан университетында җыелдылар. Монда отличник студентлар да, икелегә укыган студентлар да, активист студентлар да, дәрес калдыручы студентлар да бар иде... Һәм чәчләренә чал төшкән студентлар да. Газеталар, журналларга җитәкчелек итүче студентлар да. Телеканалларга һәм медиахолдингларга җитәкчелек итүче студентлар да. Үзләре укытучылар булып җитешкән студентлар да. Шушы фән хөрмәтенә фән гранитын кимереп бетергән студентлар да.



Юрий Фролов, Җәвит Акчурин фотолары

Бу көнне алар барысы бергә КФУның Югары журналистика һәм медиакоммуникацияләр мәктәбендә Казан университетындагы журналистика факультетының беренче деканы Флорид Имамәхмәт улы Әгъзамов исемендәге аудитория ачылу уңаеннан җыелды.

Узган меңьеллык студентлары хатирәләре белән уртаклашты, бүгенге көн студентларын тыңлады. Үзе турында моңарчы күп тапкырлар ишеткән әлеге кешенең, деканның студентлары йөрәгендә шулкадәр күп җылы, хәтта шәхси, туганнарча диярлек истәлекләр калдыруы турында гаҗәпләнеп тыңладылар.

– Ул совет журналистикасының гуманисты иде. Ә кем советныкы түгел, аңлатыйк: шундый профессия – Ватанны данлау профессиясе бар иде. Бар иде һәм Советлар иле белән бергә ул акрын гына юкка да чыкты. Әмма Флорид Әхмәтович үз студент-журналистларында тәрбияләгән гуманизм (уңайлы булсын өчен, «хезмәткәрләр соравы буенча» ул әтисенең исе-





мен кыскартырга рөхсәт итә иде) исән – ул безнең профессия өчен җавап бирүче тән күзәнәкләребездә сакланып калган. Югыйсә һәртөрле көчләүләргә, шакшы эчке киемнәргә, «Ашыгыч ярдәм» чакырасы урында, үлеп баручы кешенең газапларын төшерү өчен айфоннарга үрелүчеләргә карата бездә нәфрәт хисе тумас иде...

– Ул безгә бер фактка гына нигезләнеп глобаль гомумиләштерүләр ясарга ярамавын өйрәтте.

– Ул халыклар дуслыгы яклы һәм каршылыкларны бик тиз йомшарта белә иде...

– Әгәр хаклы булмаса, ул студенттан гафу үтенә ала иде. Башкалар алдында һәм ихластан.

– Ул безгә журналистика буенча сыйфатлы белем бирде. Казан университетын тәмамлаган журналистлар – һәркайда!

– Ул безне беркемнән дә көнләшмәскә өйрәтте, чөнки көнчелек кешене эчтән кимерә, дия иде...

– Ул мине, дәресләр калдырып йөрүче студентны, берничә тапкыр университетны ташламаска, укып бетерергә өндәде. Мине кабат укуда торгызырга булышканы өчен үзе хәтта кисәтү дә алды...

– Шәкертләренең уңышлары турында ишеткәндә, ул шулкадәр сөенә иде!..

– Ул әтиләрчә кызларның башларыннан сыйпый һәм аларга «кызым» дип дәшә иде...

– Ул авыл балаларының шәһәргә авыр ияләшүен аңлый һәм аларга булыша иде. Чөнки үзе дә тумышы белән Башкортостан авылыннан һәм беренче рус кешесен дә яшүсмерлек чорында гына очратуын сөйли иде. Фәнни белемнәрнең аңа ничек авыр бирелгәнен күз алдына китерәсезме? Бөтен профессиональ китаплар һәм дәреслекләр бары рус телендә генә иде бит...

– Ул аралашырга бик тә җайлы кеше иде. Безнең белән һәрвакыт Журналистлар көнендә табигатькә чыкты. Анда, таныш штормовкасыннан, бер учактан икенчесенә күчеп йөри иде... Гомумән, ул искиткеч иҗади кеше иде. Ул безгә фәннәрне түгел, иң мөһиме – иҗатка мөнәсәбәтне тәрбияләде.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН



Игорь Тарчевский – биология фәннәре докторы, СССР һәм Татарстан Фәннәр академиясе академигы. Казан университетында биохимия кафедрасына нигез салучы. 17 ел СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында Казан биохимия институтын җитәкли, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге президиумы рәисе, Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты булып тора. Фотосинтез химизмы, күзәнәк информатикасы, үсемлекләрнең чыдамлыгы һәм иммунитетында молекуляр механизм төшенчәләрен үстерүгә зур өлеш кертә. 11 китап авторы. 50 дән артык фән кандидаты һәм докторы әзерләгән. 2011 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнә.

БАР ГАЛӘМ БЕР КҮЗӘНӘКТӘ

«Башта үзе тыйнак кына яшь кеше булып күренгән иде. Лабораториясендә тыныч кына утырыр, дип уйладык. Ә ул нәрсә ниятләгән булып чыкты? Фәнни түгәрәк оештырды, бөтен студентны диярлек үзенә тартып бетерде, эш конкурска кадәр барып җитте... Аннары зур-зур кешеләрне тәнкыйтьләргә кереште...» – дип яза Игорь Тарчевский турында үзенең «Казан университеты турында хатлар»ында күренекле очерк остасы Анатолий Аграновский. Мәшһүр биохимикның, хезмәттәшләре хәзер атаганча, «фотосинтез классигы»ның зур фән дөньясына сәяхәте әнә шулай башлана.

Әзерләде:
Ольга Туманская

АТОМ ЭНЕРГИЯСЕНЕҢ РОМАНТИКАСЫ

Юк, гыйсъянчы булмадым, ләкин студентларны мавыктыра ала идем. Ул вакытта КДУда иң яшь лаборатория мөдире идем, лабораториянең дә ниндиендә әле! Без анда үсемлекләргә углерод яки фосфорлы радиоактив кушылмалар кертә идек. Стресс шартларына эләккән күзәнәкләрнең үз-үзен тотышындагы серләрне ачу иде ниятебез. Һәм әнә шулчакта атомчы физиклар хезмәте турында баш рольдә Алексей Баталов уйнаган «Бер елның 9 көне» фильмы экраннарга чыкты!

Университет ректоры Михаил Нужин радиоактив изотоплар лабораториясен булдыру идеясен бишкуллап хуплады. Биология гыйлеменең мондый юнәлеше физика-математика фәннәре докторының күңеленә бик хуш килде. Чын ноу-хау! Америкалы химик-органик Мелвин Калвин үсемлек фотосинтезын радиоактив изотоплар белән тикшергән өчен Нобель премиясе алды. Аның методын мин Мәскәүдә Үсемлек физиологиясе институты хезмәткәре белән бергә үзләштердердем. Ләкин тиздән ул хезмәткәр бөтенләй башка өлкәгә күчте, һәм әлеге метод Мәскәүдә тәмам югалды. Ә Казанда чәчәк атты! Һәм Советлар Союзында әле озак еллар ул, бездән кала, беркайда да юк иде.

УҢЫШ ТАМЫРЫ

Мин һичвакыт бер генә юнәлештә эшләү тарафдары булмадым. Билгеле бер нәтиҗәгә ирешә идем дә, аннары... хезмәттәшләремне гаҗәпкә калдырып, тикшеренү темасын алыштыра идем. Сәбәбе нидәме? Кызыксынуда, эчке сиземләүдә. Шәкертләрем дә минем арттан барды, үстеләр, фән докторлары булдылар, бу юнәлешләрдә лабораторияләр җитәкләделәр... Менә липидлар синтезын өйрәнүдә гаять зур нәтиҗәләргә ирешкән Александр Гречкинга (бүген РФА академигы)

Фото: Александр Ефремов

мин капма-каршы процесс – липидларның таркалуы белән шөгыльләнергә тәкъдим иттем. Бу тема өметле генә түгел, сука күрмәгән кыр иде әле. Докторлык диссертациясен яклаганда Гречкинның оппоненты – фән дөньясында исеме билгеле ханым: «Нобель премиясе лауреатлары арасында аның фамилиясен күрсәм, гаҗәпләнмәячәкмен», – диде.

Бервакыт Мәскәүдә бер атна эчендә институтыбызның берьюлы өч хезмәткәре докторлык диссертациясен яклады – Казаннан әнә шундый фән десанты килеп төшкән иде! Минем өчен дә үзенчә рекорд. Аларның барысында да мин фәнни консультант булдым.

КАМЕРАЛАР ҺӘМ КАДРЛАР

1937 елда миңа алты яшь тулды. Гаиләбез өчен авыр чаклар иде. Без, «халык дошманнары», ул вакытларны Омскида уздырдык. Техник фәннәр кандидаты булган әтиемне, Себер шартларында тракторлар сынау буенча белгечне, бармактан суырып ясалган җинаять эше ачып, кулга алалар. Аңа үлем җәзасы яный. Әни шул чакта шәһәр читендә, нәкъ төрмә каршында бер бүлмә алып тора, һәм көн саен үзе кебекләр – башка тоткыннарның хатыннары белән ирләренең һаман да шундамы икәнлеген белергә килә. Кайбер хатыннарны «төрмәгә башка «передача» алып килмәгез», дигән хәбәр көтә. Әни шул сүзләрне ишетер көн килер дип үлемнән курыккандай курыккан... Ләкин ике елдан әтине иреккә чыгаралар. Бер-бер артлы кулга алулар белән хәлсезләнгән ил өчен андый кадрлар кирәк вакыт булганга, мөгаен. Сугыш башланырга күп тә калмаган иде, без Чабаксарга күчендек. Әти андагы авыл хуҗалыгы институтында механикалаштыру кафедрасын җитәкләде.

БАР ГАЕП – ЕФӘК КҮБӘЛӘГЕ КОРТЫНДА

Ух, куып та карады соң безне каравылчы! Шәһәр скверы коймасы аша үрмәләп... күбәләк корты җыярга керә идек. Каравылчы исә безнең чынлыкта үсемлекләргә ярдәм итүебезне аңламый – йөгерә-чаба качарга туры килә иде. Кортларны Чабаксарга җибәрелгән күренекле зоолог галим, профессор Григорий Граве үтенече белән җыйдык. Ә соңрак ефәк күбәләкләре минем тормышыма да килеп керде. Без аларны яшь натуралистлар станциясе кушуы буенча үрчеттек, имән яфраклары ашата идек үзләренә. Бәлки, бу бөҗәкнең кортлы кузыларыннан алынган ефәктән парашютлар тегелгәндер – яшь натуралистлар җиңүгә әнә шулай өлеш керткән, дип уйлыйм. Минем язмышымда исә ул күбәләк кортлары биологиягә таба юлның беренче баскычлары булды. Ләкин һөнәр сайлавымда хәлиткеч рольне әтием бүләк иткән «Кояш, тормыш һәм хлорофилл» китабы уйнады. Үсемлекләр тормышын шулкадәр мавыктыргыч итеп сурәтләгән автор фәнне бик уңышлы популярлаштыручы мәшһүр галим Климент Тимирязев үзе иде.

КИЛӘЧӘК ИНСТИТУТЫ

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы карамагындагы Биология институты директоры итеп билгеләнгәч, иң беренче эш итеп, мин анда яшь биохимикларны һәм... чит тел укытучысын чакырдым. Институтның яңа хезмәткәрләре мәҗбүри рәвештә инглиз теле курслары узарга тиеш иде. Мин шуңа инанып эш иттем: чит илләрнең фәнни әдәбиятын белмичә, эшкә яңа ысул-алымнар кертү мөмкин түгел.

1976 елда өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев чакыруы белән Казанга СССР ФА вице-президенты, академик Юрий Овчинников килде. Безгә дә кагылып чыгарга уйлады. Мин аны лабораторияләр буйлап алып киттем. Аларның беренчесендә үк ул өстәлдә чит ил мәкаләсе ятканын күрде. Нәрсә турында икәнен сорады, аңа җавап бирделәр. Инглизчәгә күчте, әңгәмә дәвам итте. Һәм шул рәвешле – һәр бүлмәдә. Мәскәүдә, физик-химик биология бүлекчәсенең чираттагы бюро утырышында, академик безнең турында «киләчәк институты» буларак сөйләде. Күп яктан нәкъ менә Овчинников ярдәме белән институтыбыз физик-химик биология буенча бөтенсоюз фәнни программасына кертелде, әлеге программага ҮК карары белән шактый әйбәт акча бүленә иде. Чит ил аппаратурасы, импорт реактивлар сатып алырга һәм иң мөһиме, штатка яшь, өметле химиклар, физиклар, математиклар чакырырга мөмкинлек туды... Киләчәктә оешманың исемен Биохимия һәм биофизика институты дип үзгәртергә мөмкинлек биргән төп юнәлешләргә нәкъ менә шул чакта нигез салынды.

ЯЗМЫШНЫ БИЛГЕЛӘГӘН ОППОНЕНТ

«Бу нәрсә мөмкин түгел!» – Советлар Союзында фотосинтез буенча төп белгеч булган, чәчүлекләрнең продуктивлыгын тикшерү эшен ил күләмендә җитәкләгән профессор Анатолий Ничипорович әнә шундый нәтиҗә чыгарды. Тикшеренүләребезнең нәтиҗәләре турында сөйләр өчен, мин аның янына Мәскәүгә килдем. Изотоплы ысул безгә бөтен үсемлекнең фотосинтезын билгеләргә һәм бөртекләләрнең уңышын фаразларга мөмкинлек бирде. Бу очракта яфракларда гына түгел, үсемлекләрнең башка әгъзаларында, әйтик, башакларындагы хлорофилл да исәпкә алына. Ләкин бу ысул һәркайда кулланыла торган Ничипорович методына каршы килә. Ул метод хлорофилл күләмен түгел, ә яфракларның гомуми мәйданын ачыклауны күздә тота. Ахыр чиктә безнең ысул барыбер гамәли кулланыш тапты.

Иң кызыгы шунда, фәнни тема сайлавыма кайчандыр нәкъ менә Ничипорович йогынты ясаган иде. Аспирантурада укуымның иң әүвәлге чорында мин стресс шартларында үсемлекләрдә фотосинтез барышы турында аның мәкаләсен укыдым. Бу язма мине шулкадәр мавыктырды ки, җитәкчем профессор Алексеевка шушы юнәлештә эшләргә теләвем турында белдердем. Аның коты чыкты. Моның бөтенләй яңа ысуллар һәм җиһазлар таләп итүен, ә андый нәрсәләрнең бездә булмавын сөйләп китте. Шул исәптән нинди дә теоретик нигез дә, эксперименталь тәҗрибәләр башлангычы да юк... Тик без шулай да тәвәккәлләдек. Менә шуннан барысы башланып китте дә инде. Ә бүген – яңа баскыч, яңа үр! Үз методыбызны хәзер иген уңышын пилотсыз очу аппаратлары ярдәмендә фаразлауда кулланырга планлаштырабыз. Моның өчен басу-кырларның яшеллек дәрәҗәсен теркәргә сәләтле билгеле бер оптик характеристикаларга ия видеокамералар белән җиһазландырылган дроннар кирәк булачак.

Икенче бер эшебез чит ил белгечләренең игътибарын бик җәлеп итте. Кешелеккә мөмкин кадәр тизрәк арада җирләрнең ярлылану проблемасын хәл итәргә кирәк, ә без исә туфрактагы авыру тудыручы микроорганизмнар белән үсемлекләр арасында үзара бәйләнешне аңлауда яңа сәхифәне ачып җибәрә алдык. Минем шәкертем – фән кандидаты Алевтина Егорова ирешкән нәтиҗәләр үсемлекләрне саклау мәсьәләсен пестицидлар ярдәмендә түгел, ә туфрактагы микроб дөньясы «эшен» активлаштыру бәрабәренә чишүдә тагын бер адым ясарга мөмкинлек бирә. ▪

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU






ТАТАРСТАН ӘТИЛӘРЕ

Февральдә чын ир-егетләрне олылау матур бер гадәт санала. Әлеге ир-егетләр, зарурият килеп туса, Ватанны сакларга тиешләр. Иксез-чиксез туган илебезнең барлык ир-егетләре дә бу көнне тәбрикләүләр кабул итә. Бары тик ир затыннан булганнары өчен генә. Хәер, юк, тагын әле көчле, гаярь булганнары өчен дә. Без, хатын-кызлар тарафыннан, яратылганнары өчен икәнен... Хәер, анысын әйтеп тору да артык. Ә шулай да иң күп котлауларны әтиләр кабул итә бу көнне. Алар олы Ватаныбызны саклаучылар гына түгел, ә үз гаиләләре, ягъни Ватаныбызның кече моделе сагында торучылар да.

Безнең бу сандагы проектыбыз да әтиләргә багышлана. Балаларын ташламаучы, эштән бушагач, бар ирекле вакытларын аларга багышлаучы әтиләргә. Сабыйларына кыйммәтле бүләкләр биреп котылып, аларны тәрбияләүгә бармак аша гына караган әтиләр хакында бармый сүз. Ә үз белемнәре, тәҗрибәсе белән уртаклашып, ул-кызларына чын-чынлап әти булучы затлар – игътибарыбыз үзәгендә. Татарстанның чын әтиләре ягъни.

PRESSA.RU



КОТКАРЫЛГАН 34 ГОМЕР

Ул тәрәзәне ачып җибәрә. «Кара әле син!» – дип хозурлана аннан соң. Чыннан да йөрәк чымырдап китә – ап-ак бозлар эчендә калган Идел елгасы уч төбендәгедәй. «Хәзер аңлыйсыңмы инде? – дип сорый, җитдиләнә төшеп. – Барысы да минем күз алдымда. Әнә эрегән күлләвек, әнә – икенчесе...»

Үзенең 59 ел яшәү дәверендә ул яраткан Иделендә кешеләр батканын күп тапкырлар күргән. Барлыгы 34 кеше. Ул һәммәсен дә коткарган.

Автор:
Ольга Туманская

ДӘВАМЛЫ ТАРИХ

Дәрт-дәрманы ташып тора, күзләре елмая, сөйләшүе ихлас. Танышуга ук аны балачактан бирле беләсеңдер кебек тоела башлый. Шундый ул Виктор Давыдов. «Пират» дип йөртәләр аны әйләнә-тирәдәгеләр Иделгә тартылганы өчен.

– Кайчандыр ул безнең туендыручыбыз иде, – дип искә төшерә Виктор Львович. – Елгадан агып килгән бүрәнәләрне эләктереп алабыз – ягарга ярый. Балык тотсаң, гаиләңә генә түгел, сатарга да җитә. Яр буйлары көймәләр белән тулган иде!

Ул шулкадәр образлы итеп сөйли, мин аның ерак совет чорындагы Югары Осланын бик җиңел күз алдыма китерәм. Элеккеге үзәктә, Давыдов сүзләренчә, хәзер нигездә дача тотучылар урнашкан, кышларын «бер ярым кеше җыелмаган» урында заманында узып йөрерлек булмаган. Балалар үзләре генә дә утызлап! Кыш көне – таудан шуу, ә җәйләрен, әлбәттә инде, су коену.

Менә ул үн яшьлек дусты Витя белән ярда утыра. Ерак та түгел апалы-сеңелле өч кыз бала көймәгә кереп урнашканнар. Һәм кинәт – кычкырган тавыш. Кызларның берсе суга егылып төшкән дә чыкмый. Витя, йөгереп барып, чишенеп тә тормыйча, суга ташлана һәм кызны төптән үк сөйрәп чыгарырга өлгерә. Шундый зур шатлык була ул – кызның гаиләсенә дә, малайның үзенә дә. Галинаның әнисе ул чакта аңа бер кило шоколад конфет бүләк итә!

– Күптән түгел Галяны ире белән урамда очраттым, – дип сөйли Виктор Львович. – Исәнләштем, ә ул мине танымады. Ул түгел, аның кызы булган икән. Сораштырдым, мин коткарган беренче кызның инде оныклары да туган икән!

Оныгы Диана белән.

БЕР ТӘРӘЗӘ АША

– Әнә бер кеше килә, – дип күрсәтә миңа тәрәзә аша Давыдов. Ә мин берни дә күрмим – карлы Идел күз чагылдырырлык аклыгы белән кояштан да ныграк яктырта. Ул көлә, шкафтан зур бинокль алып, миңа суза.

Чыннан да, сукмактан ачык төстәге курткалы бер егет атлый. Аны ничек күрмәк кирәк? Әмма Виктор Львовичның күзе очлы, кешеләрне коткару тәҗрибәсе МЧС хезмәткәрләренеке кебек – тормыш аны үзе өйрәткән. Тиешле арсеналы да бар бит! Яр буенда, гаражда – ике катеры, күтәргече. Ә тумбочкасында – чын мегафон. Аның ярдәмендә Давыдов ничә фаҗигане булдырмый калган. «Игътибар, игътибар, боздагылар! – аның тавышы Идел

Ната Смирнова фотолары

өстенә тарала. – Сак булыгыз – алдыгызда бәке, артка борылыгыз».

Әмма кешеләрнең аның кисәтүләренә ышанмаган чаклары да була яки бөтенләй ишетмиләр. Әйтик, узган ел Давыдов коткарган өч кешенең берсе шикелле. Колакчыннарындагы музыка ярдан килгән тавышны күмә. Давылов хәлне бик тиз аңлап ала. Һәм авыр сулап куя: «Бетте, менә хәзер бата», – ди. Аннары берниди хәвеф сизмәгән меломанны коткарырга ташлана. Бавы, баскычы – барысы да әзер тора аның. Шулчакта дусты да килеп өлгерә.

Батып баручы егет янына барып җиту мөмкин түгел – боз бик юка, уалучан. Баскычны элэктерәләр дә, аңа таба ташлыйлар. Бичараны шуның белән ярга кадәр өстерәп чыгаралар, бәхетенә, ара әллә ни ерак булмый. Ә анда машинада әнисе каршыларга төшкән. Каршы ярга озын юлдан улын алырга барасы килмәгән – вакытына экономия ясарга уйлаган. Күз алдында улы һәлак булса, ничек үкенер иде...

«ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ – АЛГА!»

Дөресен әйткәндә, мондый туры килеп торган кушамат Пиратка бик тә җитди һәм хәтта кырыс кеше булган атасыннан күчкән. Әтисе гомере буена Идел буенда яшәгән, кочегар булган. Ә Виктор Львович үзе күп еллар буе төзелеш кранында эшләгән – бүген Казанны үзләреннән башка күз алдына китереп булмый торган биек объектларны күтәргән. Гүзәл башкалага кызы Оксананы чыгарып җибәргән, үзе исә туып-үскән Югары Осланына җаны-тәне белән бирелгәнлеген күптән аңлаган инде.

– Минем беркайчан да монннан китәсем килмәде, – дип сөйли Виктор Львович, Иделдән күзен алмыйча. – Мин армиядә Ерак Көнчыгышта хезмәт иттем. Матур яклар. Ә туган як матуррак.

Ул миңа борынгы урамнарның тынычлыгы һәм яшеллеге турында сөйли. Җәяүле бураннарны һәм давылларны яратуы хакында да. Ә бирегә – Иделдә – мондый хәлләр гаҗәеп күренеш.

...Ул көнне елга гадәттәгедән ныграк дулый – дулкыннар шаулый, җилле! Давыдов, тәрәзәдән карап, аңа сокланып тора. Көз. Инде беркем коенмый, әмма суднолар һәм паром йөри әле. Кинәт бик еракта, көмеш дулкыннар өстендә күзенә нәрсәдер чалынгандай була. Корыган агач дисәң инде, тик барыбер күңеле тыныч түгел. Бинокльдән карый – чыннан да: көймә капланган!

Фаҗига урынына күршесе белән катерда килеп җиткәндә, биш кешене чамалап алалар. Ике хатын-кыз һәм өч егет. Берсе шунда ук боларга таба ыргыла. Ә Давыдовның үз уставы – ишкәген күтәрә дә: «Хәзер үк кит! Хатын-кызларны бортка күтәрмичә, сине чыгармыйм!» – ди. Беренче хатын-кызны күтәрәләр, ул шунда ук аңын югалта, икенчесе дә – шулай ук... Аларга Иделнең аргы яры якынрак була. Батучыларны шунда чыгаралар. Үзләре дә төнге өчкә кадәр кайта алмый торалар – давыл шундый көчле була.

БОЗ ӘСИРЛЕГЕНДӘ

– Хәзер Иделдә боз бик юка – элекке кебек түгел, – дип сөйли Давыдов. – Элек боз калын, ташулар да көчле була иде. Әмма боз киткәндә дә кешеләрне көймә белән аргы ярга чыгарудан туктамыйлар. И кеше төялә иде!

Төрле хәлләр булгалаган. Әйтик, көймәне бозлар кысып ала да Камага кадәр алып китә! 90нчы еллар башында Югары Осланның үз коткару станциясе булган. Әмма, Давыдов сөйләвенчә, ул әллә ни файда китермәгән. Бәлки, шуңа күрә дә аның боздагы кешеләрне коткару тәҗрибәсе зурдыр? Күптән түгел тагын кирәге чыккан әле.

...Теге ир-ат аның мегафоннан кисәтүләрен ишеткән. Хәтта кирегә дә борылган, ләкин тискәрелеге үзенең иткән. Бер минут – менә инде бәкедән башы гына күренеп тора. Ә Давыдов тизрәк көймәсенә таба йөгерә! Булышчылар да табыла, ишкәкләргә утыралар. Үзе – койрыкка, аягы белән бозны ватарга. Шулай үрмәләп диярлек алга баралар. Әлегәчә Виктор Львович ул кешенең күзләрен хәтерли. «Син, бәгърем, кыймылдама гына. Тагын бер минут түз», – ди ул аңа әкрен генә. Ә үзе, ялгыш аның өстенә менмәс өчен, аскы яктан, агымга каршы борыла. Якынрак киләләр, бу ир сузыла, ләкин батучыга кулны бирергә ярамый. Чытырдап ябышачак та, үзе белән сөйрәп төшерәчәк. Анда инде берсен дә коткарып булмаячак. «Син кулыңны сузма», – ди аңа Давыдов, ә үзе тиз генә батучыны киеменнән элэктереп ала да көймәгә чыгарып сала. Аны чыгарган арада, коткару хезмәте дә – һава мендәрендәге судно, ярдагы ашыгыч ярдәм килеп җитә.

– МЧС барлыкка килгәч, барысы да оперативлашты, – дип, хәйләкәр генә күз кыса ул. – Ләкин без дә йокламыйбыз!

ТОРМЫШ ТАНТАНАСЫ

Миңа шунысы кызык: безнең тормышны яхшырак итүче генә түгел, аны коткаручы да кеше нинди булырга тиеш? Инстаграмга кадр кую өчен мобильникка тотынмыйча, ярдәмгә йөгерү өчен нинди холыкка ия булырга кирәк?

– Әйе, коткардым инде, коткардым, – дип иңнәрен сикертә Давыдов. – Медаль өчен эшләмим ләбаса мин аны. Берәрсе бата башлый икән – булышырга кирәк, өстәвенә, ни рәвешле коткарырга мөмкинлеген аңлагач.

Хәер, медале дә булган, тик оныклары, уйнап, каядыр югалтканнар. Бабалары янына кайталар, шунысы шатлыклы. Янәшәдә генә күл, анда – бакалар, тузбаш еланнар, кондызлар, балык тотарга да була. Күл туңгач, кәшәкә белән алка куарга. Аннары салкыннан битләре алланган оныклар белән бергәләп гөр килеп чәй эчәргә яраталар. «Без – дуслар», – ди ул бер малай, бер кыз оныклары турында.

– Мин йомшак күңелле кеше, – дип елмая Виктор Львович. – Ачуланган чакларым була, әмма ачуым бик тиз басылучан. Бер генә тапкыр яшибез бит! Ә тормыш шундый матур!

Сүзләренә дәлил итеп, тагын бер тарих турында сөйли – тормышның тантана итүе турында, әлбәттә. 70нче елларда була бу вакыйга. Иделдә бер көймә каплана. Яннарына киләләр – бер ир кеше йөзеп йөри, үзе як-ягына карана: «Хатыным батты!» Аны да, көймәне дә буксирга алып чыгаралар. Ир үз-үзен кая куярга белми.

– Ярга чыгып җиттек, көймәне әйләндерсәк, хатыны шунда – исән! Астан ничектер ябышып кала алган, көймә койрыгында барлыкка килгән һава мендәре аша сулап торган, – дип көлеп искә ала бу гаҗәеп вакыйганы Давыдов. – Мин аңа: «Син шунда хет төчкергән булсаң иде!» – дим. Күрәсең, бик каты курыккандыр. Ире әй үпте инде үзен, әй үпте!

Фотога төшәр өчен, урамга чыгабыз. Давыдов гадәтенчә тәрәзә аша Иделгә карап ала.

– Идел киң, әмма Идел буенда яшәү зур хезмәт, тырышлык сорый. Юкка гына тельняшкадан йөрибезмени без! – дип күз кыса ул һәм, свитер якасын кайтара төшеп, үзенең тельняшкасына күрсәтә. ■

ХАТЫН-КЫЗ ӘШЕ ТҮГЕЛ

Син үзеңне балаларың өчен үрнәк әтигә саныйсыңмы? Димәк, чит балалар өчен дә шундый әти була аласың. Бер көнгә генә булса да. Мамадышның әтиләр клубы әгъзалары моңа дәлил.



Автор:
Алсу Троицкая

2017 елның май аенда Түбән Камадагы парашют каланчасы янына 45 баладан торган Мамадыш «экспедициясе» килеп төшә. Алар барысы да 2нче лицей базасында оештырылган яшь десантчылар клубына йөриләр. Парашют белән сикерү идеясе клубның беренче көннәрендә үк туган була инде. Һәм менә әтиләр клубына йөрүче җирле десантчылар балалар хыялын тормышка ашырырга карар кыла. Каланчадан 2–3 мәртәбә, хәтта 5 тапкыр сикереп караучылар була. Малайлар да сикерә, кызлар да, запастагы десантчылар да. Монда алган тәэсирләр, хис-кичерешләр балалар хәтерендә ничек уелып калмасын, ди.

– Шулкадәр шатландык! – дип сөйли ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы әгъзасы, Мамадышның академик К.Вәлиев исемендәге 2нче лицее укытучысы Рамил Сафин. – Юк, без балаларның үз әтиләрен тулысынча алыштырырга тырышмыйбыз. Ләкин барлык әтиләрнең дә балалары белән шөгыльләнер өчен буш вакыты булмаска мөмкин бит. Кайбер балалар тулы булмаган гаиләләрдә үсә. Син үз балаларыңа үрнәк әти булсаң да, кем өчендер тагын бер мәртәбә әти булып тора аласың. Бер генә көнгә булса да.

Һәм, мөгаен, Мамадыш балалары өчен мондый көннәр бер генә елга җыелмастыр.

Җәй көне – чатырлы лагерьлар, кышын – традицион кышкы балык тоту фестивале һәм республика чана фестивале. Автосервисларга, янгын частьларына, спорт турнирларына бару, Җиңү бәйрәме һәм ВДВ көне парадларында катнашу...

БАШТА ХОККЕЙ БУЛГАН

Мамадышта әтиләр клубын оештыручы Айрат Шакиров турындагы көннән-көн популярлаша барган ролик меңнәрчә россиялене кузгатып җибәрә: «Мине һәрвакыт үзенең комфорт зонасыннан чыгарга җөрьәт иткән кешеләр гаҗәпләндерә. Алар кем өчендер нидер эшли, кыенлыкларга очраганда да төшенкелеккә бирелми...», «Һәр кеше герой була ала, иң мөһиме – гел үзең турында гына уйламаска...», «Якташ, рәхмәт, ярый әле, синең кебекләр бар...», «Гаҗәеп һәм илһамландыргыч вакыйга!», «Шундый гади, әмма нәтиҗәле идея...»

Фотолар: Александр Ефремов һәм Айрат Шакировның шәхси архивыннан

Аның ике улы да – Азамат белән Салават – җитди рәвештә хоккей белән мавыга. 2014 елның мартында Айрат аларның берсен сборга озата барган. Яшь хоккейчылар кортта үзләрен кечкенә гладиаторлар кебек – кыю һәм ышанычлы тота. Әмма Айратка бу сәяхәтнең икенче ягы – тормыш-көнкүреш белән бәйле асылы ачылып китә. Кечкенә спортчы өлкәннәр ярдәменнән башка ничек вак-төяк керен юа, урын-җирен төзәтә, душка керә? Ахыр чиктә, әти-әнисе кочагыннан башка йокыга китә? Вакытлыча команданың кечкенә әгъзаларына «әти» булып торырга туры килә аңа:

– Мин аларга һич авырсынмыйча булышып тордым. Өйрәнгән эш бит. Акылым белән аңлыйм: ата-аналары эштә, яшәр өчен акча эшлиләр, карьера ясыйлар. Һәр кеше дә, мөһим эшләрен ташлап, бала белән сборга чыгып китә алмый. Әмма мин әнә шулчакта бөтен барлыгым белән баланың нәкъ менә әтисе белән уртак эшләре булуы мөһим икәнлеген тойдым. Әнисе яисә әбисе сөйли алмаганны әтисеннән өйрәнергә тиеш ул.

ИРЛӘР ӨЧЕН ГЕНӘ КЛУБ

Шулай итеп, өч ел элек әтиләр клубының тарихы башланып китә. Шакиров ул чакта коррекция мәктәбендә педагог булып эшли. Бу хакта уйланучылар Мамадыш ир-атлары арасында тагын бар булып чыга.

– Миңа дусларым – ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы әгъзалары ярдәм итте. Алар барысы да әтиләр клубына язылды. Шулай итеп, безнең «әтиләр хәрәкәте» көчле старт алды. Бүген клубта 80 гә якын кеше. Монда эшкуарлар да, спортчылар да, укытучылар да, янгын сүндерүчеләр дә бар. Без балаларга үз белем-тәҗрибәбезне җиткерергә әзер. Бүгенге көндә Мамадыш мәктәпләренең барлык классларында 3–4 активист әти бар. Күбесенчә, алар – үзләренең «ирләрчә» тәҗрибәсе белән уртаклашырга теләгән кыз бала әтиләре. Икенчеләре – үзләре тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнгән һәм әтисез үсүнең ни икәнен белгән әтиләр. Мин үзем дә 10 яшемдә әтисез калдым һәм олы кешенең психологик һәм социаль халәте аның нәкъ менә балачакта әтисе белән үзара мөнәсәбәте моделеннән күчереп алынганлыгын аңлыйм. Безнең киләчәк уңышларыбызның күбесе әни белән ике арадагы түгел, ә әти белән уртак эшләребез нигезендә формалаша.

БАЛАЛАР, ГАИЛӘЛӘР, ХАТЫННАР...

– Барыннан да элек мин балаларны яратам, – ди Айрат. – Үзем белгәнне чит балага тапшыру да миңа бик җиңел. Иң мөһиме – балалар өчен файдасы булсын. Элегрәк кадак та кага белмәгән балалар өчен хәзер моны эшләү берни тормый. Үзара сөйләшер темалар да бар, алар өлкәннәр кебек фикерли. Теләсә кайсы эш барышында балаларда патриотлык хисен үстерергә, олыларга һәм якын кешеләргә ихтирам тәрбияләргә тырышабыз. Дуслар белән бөтен көчне балаларны һәрьяклап үстерүгә юнәлтәбез. Минем улларымда бернинди көнчелек хисе юк, киресенчә, алар безнең дәресләргә үзләре дә теләп йөри һәм инде миңа чын өлкәннәрчә ярдәм дә итәләр. Гаиләбез әтиләр клубы булдыру идеясен башта ук аңлап, хуплап кабул итте, рәхмәт хатыныма. Югыйсә, аңлашылмаучанлык килеп чыгуы да мөмкин иде. Әмма барлык энтузиастларыбызның хатыннары – акыллы һәм ихтирамга лаеклы ханымнар.

P.S.: Ярты ел элек Айратны Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлегенә эшкә чакырганнар. Педагогикадан түрәлеккә атлау – бер карасаң, шактый икеләнү тудырырдай перспективалар белән бәйле карар. Әмма ул үзенең карарын тыныч кына аңлата:

– Бездә ныклы команда тупланды, әтиләр клубының десантчылар белән дуслыгын күздә тотып әйтүем. Минемчә, бу очракта җәмәгать оешмасы һәм башкарма хакимиятнең көчен берләштерүдән тагын да тизрәк оешучы синергия балалар файдасына гына булачак. Һәм бу уртак тырышлык, һичшиксез, уңышлы булыр!

ӘТИЛӘР КЛУБЫНДА НИ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘЛӘР? **БАЛАЛАРНЫ НИЧЕК БӘХЕТЛЕ ИТӘРГӘ?**

Рафаэль Галиуллин, ветераннар һәм инвалидларның «Бастион» хәйрия фонды рәисе, Россия десантчыларының үзәк советы әгъзасы:
– Балага тормышта үз урынын табарга ярдәм итәргә кирәк...

Никита Белобородов, ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннары район иҗтимагый оешмасының иң яшь әгъзасы:
– Баланы якыннары турында кайгыртырга, җавапка берни көтмичә, башкаларга ярдәм итәргә өйрәтү мөһим...

Рамил Сафин, ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы әгъзасы, Мамадышның академик К.Вәлиев исемендәге 2нче лицее укытучысы:
– Бар да бик гади. Балага күбрәк вакытны багышларга кирәк...

Рафаэль Әхтәриев, ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы әгъзасы, эшкуар:
– Аларга ышанырга...

Виктор Лазутин, ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы әгъзасы:
– Иң мөһиме – теләсә нинди очракта да үзеңне лаеклы тотарга өйрәтү...

Фәнил Гыйззәтуллин, ВДВ һәм махсус билгеләнешле «Гвардия» гаскәрләре ветераннарының район иҗтимагый оешмасы җитәкчесе:
– Балага мөстәкыйльлек күрсәтергә комачауламаска һәм үз фикерләрен белдерү мөмкинлеге бирергә...

Салават Гыймранов, Мамадышның академик К.Вәлиев исемендәге 2нче лицее директоры:
– Үзебезгә аларны аңларга өйрәнергә кирәк...

PRESSA.RU

«АННАН БАШКА МИН БЕРКЕМ ТҮГЕЛ!»

Очрашырга сүз куешкач ук алар: «Сезгә кайда уңайлы, шунда күрешик», – диделәр. Мин, гаҗәпсенеп: «Юк, сезгә ничек җайлы, шунда киләбез», – дим. Кыскасы, ир белән хатын биш яшьлек улларын ияртеп үзләре килде. «Шуннан нәрсә булган?» – дияргә ашыкмагыз. Бу гаиләдә бердәнбер сау кеше – биш яшьлек Йосыф. Ә ата белән анада – тумыштан церебраль паралич диагнозы. Алар – беренче, икенче төркем инвалидлар.

Автор:
Руфия Фазылова

МИХАИЛ

Исәнләшеп, хәл-әхвәлләр белешкәч, Михаил әйтеп куйды:

– Минем турында мөселман басмалары язды инде. Ә менә хатыным Миләүшә гел күләгәдә кала. Ә бит безнең гаилә тормышында аның роле зуррак. Мине дә, улыбызны да тәрбияли ул. Аннан башка мин беркем дә түгел!

Михаилга 45 яшь. Югары белемле юрист. Дөрес, бу юнәлеш буенча эшләми. Гаҗәп түгел, аяклары начар йөри, сөйләме бик үк анык түгел. Ә мондый юристларга эш табуы мөмкин хәл түгел дисәм дә була.

Михаилның язмышы шактый катлаулы. Игез сыңары ул, туганда җәрәхәт алган. Табиблар церебраль паралич диагнозы куйган.

– Абыем сау-сәламәт, – дип сөйләде Михаил. – Табиблар карында ике бала барлыгын башта белмәгәннәр. Ярты сәгатьтән соң гына туганмын. Шул вакыт

Фото: Лилиана Вәлитова

эчендә баш миенең бер өлешенә зыян килгән. Нәтиҗәдә, акылым, интеллектым сакланган, ә менә аяк-кулларым начар йөри. Мин бик тырыш һәм үҗәт булдым. Мәктәптә «5» билгеләренә генә укыдым. Укытучылар һәрвакыт башкаларга үрнәк итеп куя иде. Шуңа иптәшләрем, хәтта игезәк сыңарым да миннән көнләшәләр иде кебек. Башкалар урамда йөргәндә, мин гел укыдым. Әлбәттә, яшьтәшләрем кебек кызлар белән аралашасым, алар белән сөйләшәсем килде. Тик «гарип» дигән тамга белән әллә нәрсәгә өмет итеп булмый. Кызлар сиңа жәлләп карый. Аралашсалар да, бары тик яхшысынмаганнан гына, дип уйлый идем...

Михаилның әнисе дә, әтисе татарлар. Гаилә Комсомольск-на-Амуре шәһәрендә яшәгән. Башка халыклардан аерылып тормасын өчен ата белән ана балаларына рус исемнәре биргән. Тел турында әйтеп торасы да юк, балалар татарча бер сүз дә әйтми үсә. Казанга килгәч кенә Михаилда татарлык, милләтпәрвәрлек уяна. Анысы тагын бер тарих.

– 2000 елда кинәт кенә әнием вафат булды, – ди Михаил. – Ялгызы ничек яшәр дип, әнинең туганнары мине Казанга алып кайтты. Монда исә татар мохитен күреп шаккаттым! Үземнең татар икәнлегемне белсәм дә, безнең халык турында бөтенләй дөрес фикердә булмавымны аңладым. Без тырыш, бик акыллы халык икән! Казанда минем төп максатым – күбрәк татарлар белән аралашу булды. Ә алар белән ничек танышасың? Өйдә бикләнеп ятып кына булмый, урамнарга чыгып йөри башладым. Берсендә туган апа әйтә: «Миша, нишләргә җыенасың? Университетлар Казанда бик күп, барып, күреп, танышып кайт!» Апаның шушы сүзе җитә калды, автобуска утырып, Казан дәүләт университетына киттем. Ак пулатларны күреп сокланганым истә. Шушы уку йортын тәмамласам, тормышта нәрсәгәдер ирешә алырмын сыман тоелды. Комсомольск-на-Амуре шәһәрендә югары уку йортына кергән идем. Ләкин бирედә яңадан имтиханнар тапшырырга куштылар. Ныклап әзерләндем. Һәм хыялыма ирештем – КДУның юридик факультетына укырга кердем...

Михаил тормышын чорларга бүлеп карый: бәхетле балачагы, әниле-әтиле еллары; аннан студент чоры; ислам диненә килү һәм гаилә кору. Акыл утырткан егетнең дингә килүе дә үзенчәлекле:

– Туган шәһәремдә христиан динен кабул иткән идем, – ди Миша. – Минем кебек кешеләргә эчке бер ышанусыз яшәү бик авыр. Анда бик күпләр христиан динендә иде. Мин дә аларга иярдем, чиркәүгә йөри башладым. Әле Казанга кайтканда да христиан динен тоттым. Тик минем көннән-көн сорауларым күбәйде, чиркәүгә барып кайткач, күңел тынычлыгы тапмый башладым. Шуннан акрынлап Коръән сүрәләре белән таныштым, мәчеткә бардым. Монда исә үземне борчыган күп сорауларга җавап таптым, ә иң мөһиме – мөселманнар арасында җылы мөнәсәбәт тойдым...

Хәләл җефете белән танышу тарихлары исә кызык та, кызганыч та: 37 яшьлек Михаил Казанның 6нчы дәваханәсендә клиник психолог булып эшләүче Миләүшәгә мөрәҗәгать итә. Егет ялгызлыктан интегүен сөйли. Ул көнне кыз белән егет озак сөйләшеп утыра. Иртәгә дә килергә рөхсәт сорап, Михаил өенә юнәлә. Ә киләсе очрашуга егет Миләүшәгә... чәчәк түгел, бер кочак мәхәббәт шигырьләре алып килә.

МИЛӘҮШӘ

Миләүшәнең тормышы җиңелрәк кебек тоелды, дөрес, аңа да кечкенәдән церебраль паралич диагнозы куелган. Тик кызның куллары эшли, аяклары әйбәтрәк йөри. Шуңа да КДУның психология факультетын тәмамлагач, эшкә урнашкан, социаль ипотекага фатир алган. Ә менә күңеленә якын кешесен очратмаган була.

Миләүшәнең әти-әнисе исән-сау, оныкларын карарга булышалар икән. Бу урында кызның әтисе белән булган мөнәсәбәтләре турында әйтергә кирәктер.

– Мин беренче сыйныфта укыганда әти белән әни аерылышты, – ди Миләүшә. – Бер урамда яшәсәк тә, әти миңа ундүрт яшь тулганчы безнең янга килмәде. Әле бит бертуган сеңлем дә бар. Әтине аеруча туган көнемдә көтә идем. Ишек ачылып китәр дә: «Кызым, туган көнең котлы булсын!», – дияр төсле иде.

Ундүрт яшемдә әтинең әтисенә хат яздым: «Бабай, әтигә укыт бу хатны. Белсен: мин аны бик көтәм. Алдыма йөз әти тезеп куйсалар да, мин барыбер аны сайлар идем, чөнки ул минеке, ул бердәнбер... Әни белән мөнәсәбәтләрен белмим, әмма ул бездән – кызларыннан баш тартырга тиеш түгел. Бабай, әгәр син аннан баш тартсаң, әти нишләр иде икән?!» – дидем хатымда. Мин ул вакытта Казан шәһәренең 4нче интернат-мәктәбендә укый идем. Шушы хатны язып бер атна үткәч, әти белән бабай яныма килде. Өчәү бергә кочаклашып озак елаштык...

Миләүшә бер елдан артык рәсми рәвештә беркайда да эшләми. Эштән китүенең сәбәпләре бар.

Беренчедән, хезмәт хакы аз, икенчедән, психолог булып эшләп бик алҗып, хәлдән таеп кайта торган була. Әле бит гаилә дә бар.

– Миләүшә, Михаилны беренче күргәч нинди хисләр кичердегез? Үзегезнең дә сәламәтлек белән проблемаларыгыз бар, тагын шундый ук иргә кияүгә дә чыккансыз, – дим.

– Икенче очрашуыбыз зур тәэсирләр калдырды. Михаилның шигырьләрендә тирән фәлсәфә ята иде. Аның эчке дөньясына таң калдым. Мондый кеше начар була алмый, дидем. Берничә көннән ул миңа тәкъдим ясады, ике дә уйламыйча, риза булдым.

– Ә әти-әниегез бу карарны ничек кабул итте? Каршы килмәделәрме? – дим.

– Дөресен әйтим, башта бик риза булмадылар. Бу аңлашыла да, ике сау булмаган кешегә бергә гаилә корып яшәү шактый авыр... кебек. Ә чынлыкта син бер-береңне ныграк аңлыйсың, кимсенү юк. Кияүгә чыкканда миңа 36 яшь иде. Якыннарымның сүзләренә игътибар итүдән узган идем... «Балабыз була», – дигәч, әти-әни, сеңлем, башка туганнар бөтенләй һушсыз калды. Яшем дә кырыкка җитеп килә бит. Тик без ирем белән сау-сәламәт бала табачагыбызга ышана идек. Беренчедән, Аллаһтан бик күп сорадык, икенчедән, «ДЦП» диагнозы безгә нәселдән килмәгән, икебез дә туганда җәрәхәт алганбыз. Теләкләребез, ниятләребез кабул булды: авырлыгы 3 700 г булган сау-сәламәт малай таптым. Йосыфны беренче көннән Михаил белән икәү генә карадык. Әни килгән иде: «Рәхмәт, тик без үзебез дә булдырабыз. Балалы тормышка беренче көннән үк яраклашасыбыз килә», – дидек. Һәм әнине кайтарып җибәрдек.

Миләүшәне күзәтәм: мөселман хатын-кызларына хас булган бер сабырлык белән, ире сүзгә кушылса, бүлдерми генә тыңлап утыра. Ана кеше газиз баласының беренче адымнарын күргәндәй, иренең һәр фикеренә елмая, башын кага. Мөнәсәбәтләрдә гармония дигән әйбер шушыдыр ул, мөгаен...

ГАИЛӘ

Бу гаиләнең фәлсәфәсе кызык, үзенчәлекле. Сау-сәламәт килеш күпләребез зарланып, сыктап яшәгән заманда, алар тормышка икенче күзлектән карый. Ата белән ананың диндә булулары (ай буе ураза тоталар, намаз укыйлар), икесенең дә югары белемле, күп укулары – барысы да йогынты ясый торгандыр.

– Безнең өйдә режим, – ди Михаил. – Йосыфны иртәнге җиденче яртыда уятабыз, кичке тугызда йокларга яткырабыз. Аннан Миләүшә белән чәй эчәбез. Өстәл артында узган көнгә нәтиҗә ясыйбыз: нәрсәне дөрес эшләмәдек, иртәгә нишлибез. Баланың сүзләрен, тәртибен тикшерәбез. Үзара мөнәсәбәтләрне уртага салып сөйләшәбез: үпкәләр юкмы, булса, конкрет нәрсәгә? Болай көнгә нәтиҗә ясау уңайлы, низаглар булмасын өчен кирәк.

Михаил, начар йөрүенә карамастан, һәр көн баласын балалар бакчасына үзе илтә икән. Якын-тирәдәге йортларда яшәүче ата белән улны белеп бетергәннәр инде. Юл буе сөйләшеп баралар. Кичкенә чагында ата кеше баласын урамга бәйләп алып чыккан: үзеннән читкә йөгереп китмәсен өчен. Михаил Йосыф артыннан куып җитә алмый. Соңрак исә бала, үзе әтисен җитәкләп йөри башлаган.

– Йосыф белән күбрәк үзем йөрергә тырышам, малай кеше бит, – ди Михаил. – Улыбызны мөстәкыйль итеп үстерәбез. Ни өчен дигәндә, аңа 20 яшь булганда, безгә 60 тулачак. Димәк, әллә ни ярдәм итә алмаячакбыз. Физик яктан кимчелекләребезне бала аңлый, күрә. Шуңа аңа киләчәктә бары үзенә генә таянырга туры киләчәк.

– Безнең җәмгыятьтә балаларга күп нәрсә ярамый, – дип сүзгә кушыла Миләүшә. – Йосыф йөри торган бакча матур, яңа. Тәрбиячеләр анда гел бармак селкеп: «Моңа тияргә ярамый», – дип тора. Ә баланың бөтен әйберне тотып карыйсы, уйныйсы килә. Шул рәвешле балаларда агрессия туа. Без улыбызга өйгә кайткач, зур табакка су салып бирәбез. Шунда ташлар атып уйный. И, рәхәтләнә инде! Шул рәвешле бөтен тискәре энергиясен чыгара. Бер «ярамый» урынына бер «ярый» булырга тиеш.

Йосыф, чынлап та бик тере бала. Ата-анасы безнең белән сөйләшеп утырганда, читтә иркенләп уйнап йөрде. Мин исә малай күздән югалган саен: «Ай, Йосыф күренми», – дим. Ана кеше, елмаеп: «Шунда гына ул, безгә әйтмичә бер кая да китми. Таныш булмаган кешеләр белән дә аралашмый, бу хакта аның белән әллә ничә тапкыр сөйләштек. Күңел тыныч, без аңа ышанабыз!», – диде.

Хисмәтуллиннар миндә соклану да, гаҗәпләнү дә тудырды. Алар башка күпчелек гаиләләргә дә охшамаган. Монда аерым фәлсәфә, аерым мөнәсәбәт. Бүген алар интернет-проектлар белән шөгыльләнә. «Татар хыялы» исеме астында төркем булдырганнар. Анда Михаилның шигырьләрен урнаштыралар, татарның гореф-гадәтләрен яктыртып баралар. Киләчәктә бу өлкәдә планнары зурдан. (Әлегә бу хакта язмавымны үтенделәр. «Башта эшлик, аннан сөйләрбез», – диделәр.)

– Йосыфта бүгеннән үк чын ирләр холкы күренә, – диде ата кеше, горурланып. – Миләүшәнең дә, минем дә аяклар авырта. Баскычтан менгәндә безгә кул суза Йосыф: «Әти, син булдырасың!» – ди. Без аның үзенә кечкенәдән шулай дия идек. Хәзер Йосыф безгә яшәргә көч бирә, канат куя. Ул өметебез дә, горурлыгыбыз да. Киләчәктә аның иманлы, акыллы егет булуын телибез.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бишбармакны **НИЧЕК** әзерлиләр

Кышкы матурлыкны **КАЙДА** күрергә була

Китап базарында **НИЛӘР** саталар

PRESSA.RU

ЗИФА КАДЫЙРОВАДАН – БИШБАРМАК!

Зифа Кадыйрова белән күрешкән журналистлар: «Гаҗәеп кунакчыл, гади, ачык кеше ул», – диләр. Хак икән, шуңа өстәп тагын: «Кулы тәмле», – дияр идем. Ир-атлар бәйрәме уңаеннан популяр язучыдан үзенчәлекле милли ризык пешерүен үтендек. Берсүзсез ризалашты Зифа апа. Искиткеч тәмле, туклыклы бишмармак пешереп күрсәтте. Язучы үзе әйтмешли: «Шулпа да, икенче аш урынына да бер дигән ризык…»



Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

«ЯҢАЧА ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНДЕМ»

Зифа апа белән Чаллыда аның заманча җиһазланган ике бүлмәле фатирында очраштык. Монда бар да зәвык белән эшләнгән, хуҗабикәнең эстетик тоемлавы сизелеп тора.

– Фатирыгызны дизайнер чакыртып ясаттыгызмы әллә? – дим.

– Юк, мин бит үзем төзүче, – ди Зифа апа, елмаеп. – Сеңлем белән эшләп чыктык. Бик күп еллар штукатур-маляр булып эшләгәч, ремонт ясауның бөтен нечкәлекләрен беләм.

Зифа апа белән беренче очрашуым иде. Газета-журналларда басылган әңгәмәләрендә еш кына ул: «Үземне язучы дип санамыйм. Китаплар да күп укымыйм. Мин бит гап-гади төзүче генә», – ди. Инде үзе белән күрешкәч, тормыш рәвешен күргәч, шунда ук аңлыйсың: Зифа апа гади генә кеше түгел, монысы бәхәссез. Шүрлектәге китаплар, җиһазлар, картиналар... Сәнгатьне аңламаган, эчке дөньясы тирән булмаган ханым болай итеп фатирын ясый алмас. Монда хәтта йокы бүлмәсе дә үзенә бер серле дөньяны хәтерләтә. Хәер, гади кешедән шундый әсәрләр туар идеме икән?!

Зифа апа табын янына чакырды: килгән кешене иң беренче кайнар чәй, баллы ризыклар белән сыйлау бу гаиләдә күркәм бер гадәт икән.

– Әйдә, тәмләп чәйләрегезне эчегез дә эшкә тотынырбыз,-диде хуҗабикә. –Бишбармакка дигән сыер белән сарык итен пешереп куйдым, шулпа да әзер. Җәймә генә хәстәрлисе калды.

Зифа Кадыйрова иҗаты, тормышы белән кызыксынып барган кешеләр белә дип уйлыйм: язучы дүрт ел элек тормыш иптәшен югалтты. Ике ел бер әсәр дә язмаган, кая ул, йоклый да алмый интеккән ханым бүген инде тернәкләнгән дисәм була. Яңача яшәргә өйрәнеп килә.

– Ялгызлык авырмы? – дим Зифа апага.

– Авыр, бик авыр... Аеруча бу яшьтә, син әле ни бөтенләй карт, ни яшь түгел, дигәндәй. Яңа тормыш башларга инде соң кебек, әмма картларча да яшисе килми әле.

– Көннәрне ничек уздырасыз?

– Өйдә утырмыйм да дияргә була. Улым да, кызым да гаиләле булды, Аллага шөкер. Оныклар бүләк иттеләр. Килен эшкә чыкты, оныкны карарга анда барам.

– Ә иҗат? Яңа әсәрегезне кайчан күрәчәкбез?

– Бу сорауны миңа кая барсам да бирәләр. Яңа бер әсәр язып маташам. Быел ул әзер булыр, дип уйлыйм. Аллаһы Тәгалә исәнлекне бирсен.

– Очрашуларга элеккечә күп йөрисезме?

– Хәзер сирәгрәк. Кызым Регина бәби алып кайтты, машина белән ул йөртә иде бит. Алай да улым Русланның вакыты булганда, ялларга туры китереп булса да, чакырган җиргә барып кайтабыз.

БАШКОРТ, КАЗАХ, ТАТАР РИЗЫГЫ?

Зифа апа кыстый-кыстый янә чәй өсти: «Кунакларның ашап-эчеп утырганын яратам», – ди.

– Ә сезгә кунаклар еш киләме? – дим.

– Бездән гомергә кеше өзелмәде. Ирем Марсель кунаклар яратты. Тундыргычта һәрвакыт пилмән, мантый торды. Көтелмәгән бер кунак килсә, тиз генә шуны пешереп

ЗИФА КАДЫЙРОВАДАН БИШБАРМАК РЕЦЕПТЫ:

Камыр:

1. Йомырка – 2 данә
2. Он – 3-4 стакан
3. Сыек май – 2 аш кашыгы
4. Су – ярты стакан

Эчлек:

1. Сыер яки сарык ите – 1 кг
2. Бәрәңге – 1 кг
3. Суган – 2 баш
4. Тоз – чама белән
5. Борыч – чама белән
6. Каз мае – чама белән (булган очракта)

PRESSA.RU

Редакция кухнясы

бирә идем. Хәзер дә шулай, балалар белән өмә ясап, күп итеп пилмән бөгеп куябыз. Бик җайлы, рәхәт нәрсә ул. Кайвакыт бер күрмәгән кешеләр дә телефоннан шалтыратып: «Сезгә сөйләр сүзем бар, яныгызга килим әле», – диләр. Каршы килмим, бар кешегә дә ишек ачык.

Зифа апа җәлт кенә бишбармак өчен җаймәгә йомырка тугларга керәште. Аннан су, сыек май өстәп, камыр басты.

– Бишбармакны еш пешерәсезме? – дип кызыксынам.

– Пешергәлим. Аны әзерләүнең әллә ни авырлыгы юк бит. Кирәк әйберләр барысы да кул астында бар. Һич онытылмый, Башкортстаннан ике туганыбыз килергә тиеш иде. Шулпа өчен зур булмаган бер тавык пешереп куйдым. Туганнар шалтырата: «Унлап кеше булабыз», – диләр. Инде нишләргә? Дүрт кешелек әбәдкә дип пешергән шулпа белән унбиш кешене ничек ашатырга? Иремә тиз генә бәрәңге әрчергә куштым, үзем ике җаймә ясадым. Кунаклар килеп табын янына утырганчы бишбармагыбыз әзер дә булды. Унбиш кешегә рәхәтләнеп җитте ул, әле калды да. Кунаклар аеруча камырын яратып ашады...

Чынлап та, бишбармак гади ризык кебек: итне, бәрәңгене пешерәсең дә, җаймәне токмач камыры кебек җәясең. Һәм аны суда пешереп аласың. Тик, моның берничә сере бар икән.

– Беренчедән, бишбармакка майлы ит кирәк, шулчак шулпасы тәмле була, – ди Зифа апа. – Бу ризык татарга да, башкортка да казахлардан кергән. Ә алар майлы ит ярата һәм нигездә сарык ите ашый. Бишбармакны туган ягым Башкортстанда сарык итеннән пешерәләр. Мин исә сарык, сыер ите кулланам. Алай тәмлерәк күрәм. Сарык итен хәзер күпләр ашамый, яратмый димме, ул очракта сыерныкын гына алырга була.

Зифа апа камырны җәеп тә куйды. Җаймәләрнең калынлыгы токмачныкына караганда калынрак булырга тиеш икән. Нәзек камыр суда эреп юкка чыккандай була, тәме сизелми. Бер җаймәне шакмакларга бүлде, икенчесен түгәрәк килеш калдырды.

МАЙЛЫ ШУЛПАГА – ӘЧЕГӘН КОРТ?!

Ит алдан пешкәнгәме, бәрәңге әрчелеп куйгангамы, эш барышы шулкадәр тиз кебек тоелды, күз йөртеп, язып кына өлгер. Хуҗабикә кәстрүлдән итне ала:

– Күр, ничек майлы, тәмле ит! – дип елмая.

– Зифа апа, хәзер күпләр сәламәт яшәү рәвеше алып бара. Майлы, тозлы ризыклардан баш тарталар, кичен җиңел ризыклар белән генә тукланалар. Сез ничек? – дим.

– Юк, теләгән вакытта утырып ашыйм. Көзгә Алла боерса 60 яшь тула. Авырлыгым гел шушы 68 кило. Майлы итләр ашарга ярамаса да, бөтенләй баш тарканым юк. Чама белән бар ризыкны да ашыйм.

Зифа апа суган вааклады да, аны кәстрүлгә шудырды. Шуның өстенә ит салды, аларны берничә минут утта тотасы икән. Ул арада икенче кәстрүлдә су кайнап чыкты.

– Җаймәләрне аерым пешерәм, – ди Зифа апа. – Кайбер кешеләр аны ит шулпасына сала, мин алай яратмыйм. Шулпа тәмен югалта кебек. Мин шулпага бик таләпчән, сөзмичә аш пешергәнем юк. Баскан токмач ашына бәрәңге салмыйм. Шулпаның тәме китә...

Хуҗабикә җаймәләрне барыбер коры суда гына пешерми, каз мае сала ул аңа. (Булмаса, сыек май салсаң да ярый икән.) Зифа апа, бүленмәгән түгәрәк җаймәне, куна тактасыннан иплән кенә алды да, кайнап торган каз шулпасына салды. Шакмаклап киселгән камырны да шунда төшерде. Камыр өч-биш минут пешә. Шуннан газда пешеп утырган бәрәңгенең суын саркытты.

– Хәзер була, – ди Зифа апа. – Шулпаны икегә генә бүләм дә... Мин бит Башкортстанда туып үстем. Безнең якта әче корт ясау гадәте бар, аны Татарстанда бер дә ясамыйлар. Менә шул әче кортны яратабыз инде. Шулпага аеруча тәмле була. Туган якка кайткан саен әллә ничә савыт алып киләм. Аны туңдыргычта саклыйм.

Әче корт дигәнне куе әчегән катыкка охшаттым. Без ясый, ашый торган кортка якын да килми. Аны озаклап әчетеп ясыйлар. Бу сөт ризыгы казахларда да популяр, имеш. Майлы иттән соң әче корт салган шулпаны эчеп куйсаң, ашказанына җиңелрәк була дип санала икән.

Хуҗабикә шулпаны икегә бүлде, шуның бер өлешенә әче корт салды. Шулпа катык салган сыман аксыл төскә керде, тәме дә үзгәрде. Катыктан аермалы буларак, башкорт корты тамакта аерым бер әчкелт тәм калдыра.

– Түгәрәк җаймәне тәлинкә төбенә куям, – диде Зифа апа. – Матурлык өчен. Җаймәне бөтен килеш калдырмыйча, пешергәндә үк шакмаклап салсаң да ярый. Аны кем ничек ясый инде, аермасы юк. Пешкәч камырны барыбер кисеп ашыйсың.

Хуҗабикә түгәрәк җаймә өстенә ит, бәрәңге салды, борыч сипте. Шуның өстенә матурлап теге шакмаклап киселгән камырларны тезде. Авыздан сулар килә... Ит, шулпа, суган исе. Өстәвенә, ярмаланып таралып киткән бәрәңге...

– Зифа апа, бәрәңгегез ничек шулай изелеп пешә, – дим. – Хәзер бәрәңгеләр сабын кебек, ничә сәгать пешерсәң дә, таралмый лабаса, – дим.

– Үзебезнең бакчада үскән бәрәңге. 8 сутый җиребез бар, җәй буе шунда мин. Ирем исән чакта алган идек. Ирем үлгәч тә дүрт ел шунда яшәдем. Кышын да утны, газны өзмибез. Ике этебез шунда яши. Улым кереп карап йөри. Ялларга мин дә барам. Җирне, табигатьне яратам. Гел шунда гына яшәр идем, балалар каршы килә. Кышын юллар начар, авырып китә калсаң, «Ашыгыч ярдәм» машинасы да килә алмый, диләр.

«АЧЫКЛАНМАГАН МЕҢ СОРАУ КАЛДЫ»

Зифа апа барыбызны да түгәрәк табын янына чакыра. Шуңа игътибар иттем: язучы ир-атларга аерым илтифат күрсәтә. Ике Александрны – журналыбызның фотографы белән машина йөртүчесен дикъкать белән тыңлый. Тәлинкәләренә берничә кат өстәп ризык сала. Тегеләре мактый-мактый ашый. (Бишбармагы чынлап та телеңне йотарлык!) Хуҗабикә канәгать булып елмаеп утыра. Әйтерсең, ана кеше нарасыйларының сыйланганын күреп сөенә...

– Зифа апа, сез нинди хатын идегез: аралашуыбызга караганда бер дә басынкы кешегә охшамагансыз? – дим.

– Белмим дә... Туры сүзле мин, иремә ачуланып, эчемә бикләнеп, көннәр буе сөйләшми йөрүләр минем өчен түгел. Хәер, мәрхүм ирем үзе дә шундый иде. Ир-атларны кызгану да бар. Нинди физик эш булса тартынып тормадым: ирем белән бергә күтәрдем дә, төшердем дә...

– Алайса сез ирегезгә дус та, ярдәмче дә булгансыз?

– Башкача булдыра алмыйм. Елап, сыктап утыра белмим. Гомер буе ирләр белән төзелештә эшләп, аннан шабашкаларга йөргән хатын-кыз көчсез була алмый. Физик көч хакында да, рухи халәт турында да әйтәм.

– Ләкин ирегезнең вафатын бик авыр кичергәнсез икән...

– Әйе, сындым. Балалар, әнием, сеңлем, туганнарым булганга, алар хакына яшәргә яңадан көч таптым. Иремне югалту көтелмәгән хәл булды. Ачыкланмаган мең сорау калды...

– Нинди сораулар?

– Бәхетле идеме икән ул? Мине яратып яшәдеме икән? һ.б. Бихисап сорау...

– Гомер буе бергә яшәп бу сорауларга җавап табып бетереп булмыймы? – дим.

– Үзе исән чагында ул хакта уйламыйсың икән. Дөнья куасың, аны эшләргә, моны корырга, дисең. Ә икең бергә утырып сөйләшергә әллә вакыт, әллә җай тапмыйсың...

Зифа апа – гаҗәеп кеше. Әле генә тормыш турында фәлсәфәгә бирелгән тол ханым:

– Йә, ничек бишбармак? – дип елмайды.

Минем исә телгә килгән беренче сүзем: «Бик туклыклы!» Әллә майлы шулпа шулай итә, әллә итле бәрәңге.

«ӘСӘР ИТЕП ЯЗАРЛЫК ЯЗМЫШЛАР БАР УЛ»

Зифа апа белән тагын бер сәгатьләп сөйләшеп утырдык. Алда озын юл булмаса, тагын күпме аралашыр идек әле, гади, эчкерсез ул, рәхәт кеше. Кем беләндер тыңлашергә, кем беләндер узышырга җыенмый. Ул хәтта ТР Язучылар берлеге әгъзасы булып та тормый. Бер карасаң, шундый популяр язучы, ун ел эчендә биш китап чыгарган, аның дүртесе «Ел китабы» исеменә лаек булган. Бер әсәре – «Язмыш сынавы» – буенча Чаллы дәүләт татар драма театры спектакль дә куйды. Бүген дә зур уңыш белән бара ул.

– Көн саен хатлар алам, – ди Зифа апа. – Кемдер почта белән җибәрә, кемдер социаль челтәрләр аша яза. Нигездә хатын-кызлар үз башларыннан кичкән вакыйгалар белән уртаклаша, фаҗигале язмышлар турында сөйли. Кайберләре белән дуслашып, хәтта якын кешеләргә әйләндек. Әсәр итеп язарлык язмышлар бар ул. Аеруча соңгы әсәрем – «Синсез килгән язлар» китабы дөнья күргәч, күп итеп хатлар ява башлады. Баксаң, хыянәт белән очрашкан никадәр хатын-кыз бар икән! Гаилә тормышын бөтенләй икенче яктан ачтым: гаҗәп тә, куркыныч та...

Саубуллашканда язучы бер китабын сайлап алырга тәкъдим итте. «Очрашу истәлеге булсын, бүләк итәм», – диде. Зифа апаның өч китабын укыганым бар, ә менә «Синсез килгән язлар» әсәре белән таныш түгел идем. Шуңа әлеге китапны сайладым. Һәм... Чаллыдан Казанга кайтканчы, машинада әсәрнең ике бүлеген укып та чыктым. Караңгы төште, күренми, ә мин телефонны алып, фонарьны яктырттым – бигрәк мавыктырды. Белмим, язу осталыгымы, әллә инде берәр тылсыммы, Зифа апа каләменнән төшкән әсәрләрне бер укый башласаң, туктап булмый. Хәтерлим, декрет ялында утырганда «Көтеп узган гомер»не бер төндә укыдым. Көне буе бала карап тылчыгуга карамастан, кулга ул китап кергәч, бөтен арыганлык юкка чыккан иде. Зифа апаның әсәрләрен икенче көнгә калдырып булмый. Бу юлы да нәкъ шулай булды, өйгә кайткан «Синсез килгән язлар»ның өченче бүлеген укып бетердем.

Икенче көнне язучы белән телефоннан сөйләштек:

– Зифа апа, «Синсез килгән язлар»дагы төп герой Фирая ире үлгәннән соң аның хыянәте турында белә. Һәм моны бик авыр кичерә, хәтта мәрхүм иренең каберенә дә бармый. Бу сюжет тормыштан алынганмы? – дим.

– Әйе, тормыштан. Фирая – көчле хатын-кыз. Андыйларга тормышта җиңел түгел. Бу әсәрне ир-атлар да укысын иде. Иренең хыянәте турында белгән хатын-кызларның ниләр кичергәнен аңлар өчен булса да...

1. Сытабыз!

2. Туглыйбыз!

3. Җәябез!

4. Салабыз!

5. Бутыйбыз!

6. Өстибез!

7. Кисәбез!

8. Пешерәбез!

9. Утка куябыз!

10. Бүләбез!

БЕЛЕШМӘ

Зифа Әбделвәли кызы Кадыйрова 1958 елның 7 октябрендә Башкортстанның Учалы районы Ахун авылында туа. 1976 елда Ахун урта мәктәбен тәмамлый. Гомере буе төзелештә эшли. Тормыш иптәше белән улы Руслан, кызы Региналы тәрбияләп үстерә. 48 яшендә кулына каләм ала. Зифа Кадыйрованың биш китабы дөнья күрә. Алар төрле елларда дүрт тапкыр Татарстан үзәк китапханәсенең «Ел китабы» исеменә лаек була.

PRESSA.RU

ФЕВРАЛЬ. ТАТАРСТАН. ДОЛГАЯ ПОЛЯНА. ТӘТЕШ РАЙОНЫ

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Фото: Александр Кашкин, Екатерина Иванова

ФЕВРАЛЬ. ТАТАРСТАН. ЭТ ЕЛЫ

Фото: Сергей Фомин

ФЕВРАЛЬ. ТАТАРСТАН. СТАЛИНГРАД СУГЫШЫНЫҢ РЕКОНСТРУКЦИЯСЕ

PRESSA.RU

ФЕВРАЛЬ. ТАТАРСТАН. ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

Фото: Сергей Фомин

СӘЕР БАЗАР

Урамда егерме градус суык. Якшәмбе. Базар. Иртәнге сәгать тугыз. Халык кар өстенә тезеп куелган әйберләрне карап йөри. Кызык бередә. Сатулаша-сатулаша товар сайламыйлар, ямьсез сүзләр дә ишетмисең. Киенү, сөйләшү рәвешләре буенча башка бер генә базарда да мондый кешеләрне очратмыйсың.

Автор:
Руфия Фазылова



Фото: Александр Ефремов

КИТАП ФАНАТЛАРЫ

Кемдер аны «хәерче базары», кемдер «китап базары» ди. Казанның Кәрим Тинчурин паркында атнаның һәр якшәмбесендә җыела ул. Ни генә юк монда: яңа уенчыклардан башлап, СССР чорында эшләнгән патефон, самовар, корал, кием-салым, егерме-утыз ел элек чыккан кассеталар һ.б. Мөгаен, башка бер җирдә дә мондый манзараны күрмәссең: кешеләр бер-берсенә, ихтирамлы итеп, исеме һәм әтисенең исеме белән эндәшә.

Базарда иң күп ихтыяҗ – китапка. «Узган атнада әйткән китапны алып килдегезме?» – дигән сорауны бер тапкыр гына ишетмәдек. Бу «әдәбият белән җенләнгән» кешеләрне үз күзләрең белән күрмәсәң, аралашмасаң, дөньяда андый кешеләр бар дип уйламыйсың да. Китап укучы юк, дип зарланабыз бит. Бар икән, менә алар!

Базарны бер кат әйләнеп чыктык. Салкын булгангамы, сатып алучылар әллә ни күп түгел. Китаплар сата торган сәүдә ноктасы янында таптанабыз. Сатучы кызыксына:

– Сезне кайсы чор әдәбияты кызыксындыра: унсигезенче, унтугызынчы, егерменче гасыр?

– Татар китаплары бармы? – дим.

– Бар.

Һәм миңа балалар өчен булган берничә китап күрсәтә.

– Ә классик әдәбият?

– Сезне кем кызыксындыра. Әйдәгез, язып алам. Киләсе атнага алып киләм...

Янәшәмдә торган ир:

– Андрей Болотовны таптыгызмы? – ди сатучыга.

– Кайтып җитмәде. Киләсе атнага алып килергә тырышырмын...

Болотов китабын сораучы абзыйга күтәрелеп карыйм: өстендә калын бишмәт, аягында йон итек. Яше шактый өлкән булса да, гәүдәсе төз, матур.

– Андрей Болотов исемен күпләрнең ишеткәне дә юктыр. Әдәбиятны яхшы беләсез, ахры. Болотовның китапларын табу шулай авырмы? – дим.

– Әйе, авыр. Совет чорында да бастырылмаган, хәзер дә юк.

– Интернеттан эзләп карагыз, – дип киңәш бирәм.

– Интернет?! Зинһар, миңа ул турыда әйтмәгез. Тынычлап, шул зәхмәтсез калган гомеремне яшәп бетерергә бирегез. Интернет дигәнегез бүген халыкны чиргә сабыштырып бетерде инде...

Бу абый белән тагын егерме минутлап гапләштек. Казанның бер һөнәр училищесында укытучы-мастер булып эшләгән, укымышлы, зыялы ир-ат. Халыкның китапка битараф булуына, яшьләрнең көне-төне интернетта утыруларына көенеп, ачынып сөйләде ул. Аның тагын бер фикере кызык тоелды:

– Хәтта армиядә дә булмаган кешеләрнең сугыш турында фильм төшерүләре яки әсәр язуларына шаккатам! – диде ул. – Соң, үзең күрмәгән, кичермәгән әйберләрне ничек халыкка җиткереп булсын? Менә шуңа күрә бүген кино да, әдәбият та ясалма. Ышандырмый кешене, фәлсәфәсе юк...

ИШ ЯНЫНА КУШ

Җиргә бүрекләр тезеп куйган бер бабайга күз төште. «Бәясе 300 сумнан» дип язып куйган. Шунда ук тагын бер төлке тун да эленеп тора.

– Бүрекләрне үзем тегәм, кирәк булса ал, – дип, бабай җирдән мутон бер бүрекне алып бирде.

– Ә бу һөнәргә ничек өйрәндегез? – дим.

– Өйдә «Зингер» тегү машинасы бар. Безнең йортта тегә белмәгән кеше юк иде. Балаларга кием кирәксә дә, җәлт кенә машинага утырдык.

Бабайның исеме Зиннәт Зәбиров икән. Сиксән дистәне тутырган. Иш янына куш булыр дип, менә шулай бүрекләр тегә, ял көнне аларны базарга алып чыгып сата. Бүрек өчен чималны Колхоз базарыннан барып ала яки танышлары иске мутон туннар бирә. Бер туннан дүрт-биш бүрек чыга икән.

– Өч ел элек хатыным вафат булды, – дип сөйләде Зиннәт абый. – Ике кызым бар, алар Канадада яши. Хатыным бакыйлыкка күчкәч, бик авыр булды. Тату, матур яшәдек без. Укымышлы, сабыр кеше иде. Без аның белән сәяхәткә кая гына бармадык. Менә бу төлке тунны да Норвегиядән алып кайткан идек...

Зиннәт бабайның пенсиясе 12 мең сум икән. Кызларыннан ярдәм сорыйсы килми, шуңа да кар-

– Өйдә «Зингер» тегү машинасы бар, – диде Зиннәт Зәбиров.

– Ипилек-тозлык булса да, акча кермәсме дим, – диде Фирүзә апа Фатыйхова.

тайган көнендә базар сатучысына әйләнгән. Хәер, икенче сәбәп тә бар:

– Бүрекләрне теккәндә ялгызлыкны онытып торам, – диде бабай. – Өйдә көнелсезләнеп ятканчы, монда чыгып, кеше белән аралашып керәм. Бу базарда сату итә башлаганга, ике елдан артык инде. Җәен дә, көзен дә киләм...

Зиннәт бабай кебек өлкән яшьтәге сатучылар күп бирелә. Дөрес, алар барысы да үзе эшләгән, үзе җитештергән товар белән сату итми. Күбесе базарга кулланылышта булган, көндәлек тормышта артык дип табылган әйберләрен алып чыккан. Шундыйларның берсе – Фирүзә апа Фатыйхова. Совет заманында эшләнгән тимер кашык-пычаклар, чәйнек, кәстрүл, пәлтә...

– Пәлтәне бер-ике генә кидем, – диде Фирүзә апа. – Үземнең менә туным бар, ничәнче кыш шуны киям инде...

– Бу иске пычаклар ничә сум тора. Алучы бармы? – дим Фирүзә апага.

– 25 сумнан бирәм. Әле бер нәрсә дә сатмадым бүген, салкын, кеше дә бик йөрми.

Фирүзә апа укытучы булып эшләгән, хәзер дә әлеге һөнәр ияләренә хас пөхтәлек, зыялылыгын югалтмаган.

– Сорарга да әллә ничек инде, бу салкында базарга чыгарга нәрсә этәрде? – дим лаеклы ялдагы мөгаллимәгә.

– Ипилек-тозлык булса да, акча кермәсме дим... Ун мең сум пенсия алам, шуның 7 мең сумы фатир өчен түләргә китә. Өч бүлмәле фатир безнең. Бабай белән икәү генә шунда яшәп ятабыз.

Фирүзә апа тормыш иптәше Мөхәммәт абый белән бер ул үстергән. Бик күп өлкән яшьтәге әти-әниләр кебек, Фатыйховларның да балаларына йөк буласылары килми. Ничек тә шул пенсия акчасына көн итәргә тырышалар.

– Бабай сумкамны базарга китереп куйды, бердә янә килеп ала, – диде Фирүзә апа. – Чыккан бае йөз сумлык сата алсам ярый...

– Монда сезнең өс киемнәре сатучы өлкәннәр шактый, алучы бармы икән? – дим.

– Булгалый инде. Узган атнада бер кофта саттым, 150 сумга бирдем. Кырык яшьләрдәге бер ханым алды. Ул киемнәрне, без үлгәч, барыбер ташлаячаклар, болай ичмаса аз булса да, акчасы була.

«КАЙГЫНЫ БАСАМ, ДИП...»

Базарның ике-өч җирендә картиналар саталар. Бәяләр төрле: биш йөз сумнан башлап унбиш

PRESSA.RU

Миләүшә апа Әхмәтованың хыялы – картиналар сату өчен кечкенә генә булса да сәүдә ноктасы ачу.

меңгә кадәр. Ләкин халык картиналар белән бик кызыксынмый. Берәм-сәрән бәя сорап киткән булалар.

– Картиналар үзегезнекеме? – дип сатучы ханымга.

– Әйе, үзем ясыйм. Рәсем сәнгате белән күптәннән кызыксынам. Кызым вафатыннан соң ныклап торып картиналар ясарга алындым, кайгыны онытыр өчен…

Миләүшә апа Әхмәтовага алтмыш яшь тула икән. Бер ел элек КФУның беренче курсында укып йөргән чәчәк кебек кызын югалткан. Хастаханәдә җан биргән ул.

– Табибларның салкын карашы гына баламның үлеменә сәбәп булды, – ди әни кеше. – Бала хәсрәте бик авыр, сөйләп-аңлата торган гына түгел. Депрессиягә бирелдем. Кызым бишкә генә укыды, бик акыллы бала иде…

Миләүшә апа йокысызлыктан интегә. Күп вакыт төне буе рәсем ясап чыга икән. Гаҗәп, күңелендә кара буран өермәсе булса да, Миләүшә апаның картиналары якты төсләрдән тора. Нигездә алар – табигать күренешләре. Җил-давылда ботаклары сынган, сыгылган агач рәсеме, ялгыз ат, ялгыз көймә дә бар.

Картиналарга сорау юк икән. Ашаган белми, тураган белә, дигәндәй рәсем сәнгатенең дә үз проблемалары бар:

– Рәсем ясау өчен киндер тукыма гына да 500 сумнан башлана. Башка кирәк-яракларын да кушсаң, хезмәтең бушка булып чыга, – диде һәвәскәр рәссам.

– Миләүшә апа, картиналарыгызны кибетләргә тәкъдим иткәнегез юкмы, бәлки алар сатарга куярлар иде, – дим.

– Кибеттә дә берничә картинам тора. Минем бәягә тагын шулкадәр өстәгәннәр. Алучы булмастыр.

– Интернет аша сатып карарга була, – дим.

– Әйе, уйлап карарга кирәк…

Миләүшә апаның хыялы бар – картиналар сату өчен кечкенә генә булса да сәүдә ноктасы ачу. Олы хәсрәт кичергән анага сабырлык, иҗат уңышлары теләп саубуллаштык.

«КОРАЛ – ИР-ЕГЕТНЕҢ КАНЫНДА!»

Ир-атлар күпләп җыелган урынга күзем төште: корал, ядрәләр саталар икән! Әйе, чып-чын корал. Төрле бизәкле пычаклар да бар. Тагын хатын-кыз аңламаган әллә ниләр…

Корал сатучы ир белән уртак телне тиз таптык. Саф татарча сөйләшүче сәүдәгәр Ирек исемле икән:

– Кайчакта икешәр, өчәр тапкыр полиция хезмәткәрләрен чакырталар, – диде Ирек. – Мине монда тәртип сакчылары белеп бетерде, популяр кеше…

– Ә ни өчен полиция хезмәткәрләре чакырталар? – дим.

– Янәсе, җәмгыятькә куркыныч тудырам. Әбиләр дә еш кына килеп сүгә башлый: «Хәзер халык сездән алган корал белән бер-берсен үтерә башлый», – диләр. Мин көләм генә. Гади кешегә, бигрәк тә хатын-кызга моны аңлату кыен. Әйе, бу корал, ләкин ул чын корал кебек атмый, махсус шулай көйләнгән. Ә бу ядрәләр дә инде бер тапкыр атылган, аның дарысы юк.

– Ул коралны кемнәр ала? – дим.

– Мәктәп укытучылары ала. Тормыш иминлеге нигезләре дәресләрендә укучылар корал төзелешен өйрәнә, шулай ук атып та карыйлар.

Интернет аша заказ биреп, якшәмбе монда килеп алучылар да күп икән. Корал коллекцияләре җыючылар бар. Кыскасы, Ирек Миңнебаев сәүдә ноктасында беркайчан кеше өзелми.

– Бу эш белән күптәннән шөгыльләнәсезме? – дим.

– Әйе, күптәннән. Элек иске пычакларга сап ясап, матурлап сата идем. Хәзер әзер пычаклар алып кайтып сатам. Мылтыкларны исә үзем җыям. Иске корал сатып алам да төзәтәм, яңартам. Атарга өйрәнер өчен, бер дигән мылтык барлыкка килә.

Улы белән зур булмаган пистолет карап торган бер иргә мөрәҗәгать иттем:

– Бу пистолет белән нишләргә җыенасыз?

– Дустымның туган көне җитә, бүләккә аласым килә. Дусларга мин шулай корал бирергә яратам, оригиналь бүләк бит.

Пистолетның бәясе 3 мең сум икән. Мылтыклар исә кыйммәт, маркасы, зурлыгына карап 50 мең, 150 мең сумга да бар.

– Иң арзан товар биредә – бер тапкыр атылган ядрә, – диде Ирек. – Алар 40 сум тора. Аны гадәттә сувенир итеп алалар.

ПУШКИН КИТАБЫ – 150 МЕҢ СУМ

Сәгать уникегә таба кеше шактый күбәйде. Ләкин аларның күбесе бирегә әйбер сатып алырга килмәгән. Бу – аларның сөйләшү,

– Кайчакта икешәр, өчәр тапкыр полиция хезмәткәрләрен чакырталар, – диде корал сатучы Ирек.

күрешү урыны. «Якшәмбене көтеп алабыз», – диләр.

Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: сатучылар авызыннан еш кына: «Сыйфат билгесе», – дигән сүз ишетәсең. Ягъни товар СССР заманында чыккан. Бер сөйләшү аеруча кызык тоелды. Урта яшьләрдәге ир Сталин портретын карый:

– Бу Кытайда эшләнгәнме? – дип сораган иде, сатучы, берәр начар сүз әйткәннәр диярсең, кабынып китте:

– Нинди Кытай булсын? Нәрсә сөйлисең? Ул вакытта бездә Кытайның исе дә, эзе дә булмаган! Менә, язуын кара, 1965 елда эшләнгән диелгән… Биш йөз сум гына, ал…

Күп еллар Казан дәүләт университетында эшләгән аксакаллар белән дә сөйләшеп тордык. Базарның барлыкка килү тарихы кызыксындырган иде, тик төгәл генә җавап бирә алмадылар.

– Әнә, бәлки Айдар беләдер, – диделәр.

Китап, патефон, СССР байраклары сатучы Айдар Әюпов танылган шагыйрь Харрас Әюповның улы булып чыкты. КДУның тарих факультетын тәмамлаган.

– 1980нче елларда биредә базар булган, монысын төгәен әйтеп була, – диде Айдар әфәнде. – Нигездә анда күбрәк китаплар сатылган. Әле мин белгәндә дә базарда акча, чүпрәк-чапрак бик юк иде. Күрәсең, сорау бар, әнә китаптан тыш та нәрсә генә сатмыйлар.

Айдар Әюпов бик иске китаплар белән дә сәүдә итә. Букинист дип атасам, дөресрәк булыр. Базарга ул гарәп-рус сүзлеген алып килгән.

– Бу сирәк китапның бәясе 5 мең сум тора. Узган атнада Кытайдан килгән бер студент кыз заказ биргән иде, – диде Айдар Әюпов. – Әле килеп җитмәде, алып китәргә тиеш…

Айдар Әюповта китаплар әллә ни күп түгел: затлы, тарихы булган басмалар белән генә сәүдә итә ул. Мисал өчен Толстойның үзе исән чагында басылган китабы 50 мең сум тора. Китапның бәясе аның тышкы кыйфәте, ничек сакланганлыгына да бәйле икән.

– Классик әсәрләргә сорау зур, – ди Айдар әфәнде. – Әгәр язучы исән вакытта нәшер ителгән басма сатуга чыкса, аны шунда ук сорый башлыйлар. Базарда алыпсатарлар күп, алар арзан бәягә яхшы китапны эзләп кенә йөриләр. Пушкинның 1823 елда басылган «Евгений Онегин» китабы 150 меңгә кадәр тора. Әлбәттә, сыйфаты әйбәт булса. Әгәр кеше базар бәяләрен белмәсә, шундый затлы китапны бик арзанга да сатып җибәрергә мөмкин.

Биредә сатучылар, сирәк китапларны каян алулары белән уртаклашырга яратмый.

Һәркемнең үз юлы, таныш букинистлар белән эшлибез, – диләр. Әйе, бу өлкәдә алар аз, чөнки китап, иске әйберләр белән сату итү өчен бизнес булудан тыш, тормыш, яшәү рәвеше.

Тагын бер букинист белән таныштым – Олег Добролюбов. Биредә аны белмәүче кеше сирәк, студент вакытыннан бирле китап сату белән шөгыльләнә. Олегның хыялы – кулланылышта булган китаплар өчен махсус кибет, яки үзәк ачу. Айдар Әюповтан аермалы буларак, Олег арзанлы китаплар белән дә сату итә. Кулланылышта булган дәреслекләр, балалар әдәбияты, нәрсә генә юк.

– Тарих белән бәйле китапларга сорау зур, – диде букинист. – Революциягә кадәр чыккан басмалар аерым статуска ия. Тик аларны монда бик алып килмим, заказ буенча гына эшлим. Ни өчен дигәндә, затлы китап йөртә-йөртә таушала яки югалырга мөмкин.

Олег үз эшенең остасы – янына килгән кешене китапсыз җибәрми дияргә була. Толстойның бер томын башта илле сумга тәкъдим итте, сатып алучының икеләнгәнен күргәч 30 сумга «төртте».

…Әлеге базар миңа бүгенге җәмгыятьнең йөзе сыман тоелды. Кичәге укытучы соңгы пәлтәсен сатарга чыккан, чөнки пенсиясе ашарына да җитми. Ә атналар буе эшләп, күпме җан җылысы, хезмәт кергән картиналарга сорау юк. Китаплар да карлы җирдә үз укучысын көтеп ята. Аерым автор, әсәрләрне санамаганда, аларга ихтыяҗ бик юк икән.

Китап, патефон, СССР байраклары сатучы Айдар Әюпов:
– Классик әсәрләргә сорау зур.

Григорий Ивойлов, төбәк тарихын өйрәнүче, коллекционер:

– Тинчурин паркындагы базарда сатучы, сатып алучы буларак та еш булам. Тарихына килгәндә, аны махсус өйрәнгән кеше юк дип беләм. Һәрхәлдә, минем ишеткәнем юк. Әйе, аерым мәгълүматлар тупладым. Ләкин ул нигездә кешеләр сүзенә, аерым фактларга корылган.

Сәүдә тарихын карасак, Россиядә 1860–1870нче елларда үсеш алган сәүдә культурасы 1917 елгы революциядән соң җимерелә. Беренчедән, сатарга әйбер калмый, икенчедән, сәүдәгәрләр конфискация яки үтерелүдән куркып, эшләрен ташлый. Күпләр качарга мәҗбүр була.

1920 елда РСФСРның Җинаять кодексына «спекуляция» өчен аерым статья кертәләр. Шул рәвешле урамнарда ачыктан-ачык сәүдә итүләр юкка чыга. Әмма акрынлап барыбер «итәк астыннан сату» чәчәк ата. 1940нчы елларда Россиядә «кара базар» тамыр җәя башлый. Ни өчен дигәндә, дәүләтнең фронтта да проблемалары җитәрлек, ә «барахолка» көн кадагына килеп баса. Яңасын алырга халыкның мөмкинлеге юк. 1950нче елларда урамнарда сәүдә нокталары барлыкка килә. Комиссион кибетләр ачыла, шул исәптән Казанда да. Хәтта фабрика эшчеләренең, күрсәтмичә, шкаф-урындыкларны сатуга алып чыгулары билгеле. 1960нчы еллар – «барахолка»ларның чәчәк аткан чоры. Революциягә кадәр булган әйберләрне җыю модага керә. Шуның белән бергә, илгә көнбатыштан совет кибетләрендә сатарга ярамаган джинс чалбарлар, кроссовки, тәмәке кайта башлый. Боларны сатып алу өчен халык ниләр генә эшләми! Иң зур базар Компрессорлар заводы тирәсендә була. Нәкъ шул вакыт Ленин бакчасы мәйданында нумизматлар һәм Тинчурин паркында китап базары – «Книжка» оеша. Соңгысы сәүдә үзәге булудан тыш, китап сөючеләрнең аралашу, җыелу урыны була. Анда китаптан башка әйбер сатылмый. Димәк, Тинчурин паркындагы базарның якынча илле еллык тарихы бар. Әйе, ул бүген үзгәрәк, Ленин бакчасыннан нумизматлар да килеп кушылды. Әбиләр чүпрәк-чапрак сатарга да чыгып утыра. Тик илле ел элек кебек үк, нигездә, биредә китап сөючеләр җыела.

2017 ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ
«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

ЕЛНЫҢ ДӘҮЛӘТНЕКЕ БУЛМАГАН ПЕНСИЯ ФОНДЫ

ГОМЕР КӨЗЕ «АЛТЫН» БУЛСЫН ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?

Бүгенге көнеңнең муллыгы иртәгәсе көн өчен ышаныч ул, диләр. Егерме елдан артык «иртәгәсе көн» өчен, төгәлрәге, бик күп татарстанлыларның тупланма пенсия өлешенең киләчәге өчен Милли ДБПФ җавап тота. Пенсия тупланмалары белән идарә итүнең заманча алым-таләпләре турында «Татарстан» фондның генераль директоры вазыйфаларын башкаручы Эльвира Розяева белән сөйләшә.

– Эльвира Михайловна, гыйнвар ае башында «Татарстан» журналы 2017 ел лауреатларын билгеләде. Басманың сайты аша укучыларыбыз арасында уздырылган сораштыру нәтиҗәсендә, «Милли ДБПФ» «Елның дәүләтнеке булмаган пенсия фонды» номинациясендә җиңү яулады. Әлеге бәйгедә ул шактый өстенлек белән җиңде – аның өчен респондентларның 56 проценты тавыш биргән иде.

– Бу хакта ишетү бик күңелле. Татарстан Республикасы – безнең фондның туган ягы, аеруча яраткан төбәгебез: Милли ДБПФ монда оештырылган. 20 ел эшләү дәверендә республиканың пенсия белән тәэмин итү системасында бик күп эш башкарылды. Фондның акционерлары – Татарстанның иң эре предприятиеләре: «Татнефть» ГАЖ, Зенит Банкы ГАЖ, «Казан Оргсинтез» ГАЖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ, «Татэнерго» Идарәче компаниясе» АЖ һ.б. Татарстанда яшәүчеләр – үз киләчәгенә җаваплы караганнар арасында безгә ышаныч белдерүчеләр саны елдан-ел арта бара. Тавыш бирү нәтиҗәләре моны тагын бер раслый.

– «Пенсия» дигән сүзне ишетүгә, күп сораулар һәм шик-куркулар барлыкка килүе инде гадәткә кергән. Гомер көзе «алтын» булсын өчен нишләргә?

– Пенсия белән бәйле генә түгел, һәр очрак өчен кулай киңәшем – әзерләнергә! Финанслар ягыннан дөрес эш йөртү бу мәсьәләдә бездән җитди караш таләп итә. Шуңа күрә беренче адым – хәлгә дөрес бәя бирү. Монда сезгә пенсия калькуляторы ярдәмгә килер, аны, әйтик, Милли ДБПФ сайтында санатып карарга була. Бик гади хисаплаулар нәтиҗәсендә сез үзегезне нинди пенсия көткәнен күрә аласыз.

– Әлеге нәтиҗә Милли ДБПФ белән хезмәттәшлек очрагына гына карыймы?

– Шуны аңлау зарур: хәзерге заман шартларында киләчәк пенсионеры, үзенең пенсия тупланмасын формалаштыру өчен, фондны үзе сайларга хокуклы. Пенсия тупланмасы – пенсия кертемнәре һәм дәүләтнеке булмаган пенсия фонды алган инвестиция керемнәре ул. Пенсия акчаларын инвестицияләү белән бәйле керемлелек дәрәҗәсе күрсәткечләре һәр фондта төрлечә.

– Булачак пенсияне хисаплап караганнан соң, икенче адым – тупланмаларны формалаштырып, алар белән идарә итәчәк фондны сайлау. Керемлелек күрсәткеченә игътибар юнәлтергәме?

– Пенсия тупланмаларын инвестицияләү белән бәйле керемлелек дәрәҗәсе буенча Милли ДБПФ югары күрсәткечләргә ия. 2017 елның 9 аенда без 11,96% керемлелек күрсәттек һәм иң эре 20 ДБПФ арасында янә беренчелекне яуладык*. Киңәшем шул: фонд сайлаганда, киңрәк фикер йөртергә кирәк. Фондның акционерларына, базардагы эш тәҗрибәсенә, бәйсез рейтинг агентлыгының фондка биргән рейтинг дәрәҗәсенә бәя бирү мәслихәт. Фондның шәһәрегездә яки төбәктә рәсми офисы булу да бик әһәмиятле, бу исә, сораулар туганда, аларны оператив рәвештә хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

– ДБПФның масштабы әһәмияткә ияме?

– Милли ДБПФ гигант фондка, бердәнбер, иң зур фондка әйләнү максаты куймый. Без үз клиентларыбызны бик саклыйбыз, аларның һәрберсен шәхсән беләбез дияргә була. Фондыбызның командасы ничә ел эш дәверендә әллә ни үзгәрмәде, нигездә ныгыды гына. Шуңа күрә клиентларыбызның һәм пенсионерларыбызның күбесе, сораулар туганда, кая, кемгә мөрәҗәгать итәргә икәнен белә. Без фондыбызда клиентлар белән йөзгә-йөз, ачыктан-ачык сөйләшәбез, чөнки мөһим карарлар кабул иткәндә, шәхси аралашуның кыйммәте бәһаләп бетергесез, дип саныйбыз.

– Шулай да булачак пенсияне ничек арттырырга соң?

– Фондта пенсиянең тупланма өлешен мөмкин кадәр иртәрәк формалаштыра башларга кирәк. Фондтан фондка күчеп йөрергә түгел, чөнки шул рәвешле инвестиция керемен югалтырга да була. Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары программалары буенча «икенче пенсия» булдыру турында уйлый башлау зарур. Милли ДБПФ бернича шәхси пенсия программасы тәкъдим итә, алар төрле керемле, төрле мөмкинлекле кешеләргә иң кулай вариантны сайлап алу җаен тудыра. Шәхси финанслар һәм булачак пенсиягә карата бик акыллы эш итүегезне телим!

«Милли дәүләтнеке булмаган пенсия фонды» акционерлык җәмгыяте – дәүләтнеке булмаган тармакара пенсия фондларының иң эреләреннән. 1997 елда оештырылган. Акционерлары: «Татнефть» ГАЖ, Зенит Банкы ГАЖ, «Казан Оргсинтез» ГАЖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ, «Татэнерго» Идарәче компаниясе» АЖ һ.б. Милли ДБПФ үрнәк булырлык профессиональ абруйга ия, бу исә алдынгы «Эксперт РА» (RAEX) рейтинг агентлыгы тарафыннан бирелгән RuAA (Тотрыклы фараз) ышанычлылык дәрәҗәсе белән расланган.

Татарстан Республикасында фондның бүлекчәләре:
- Казан, Сибгат Хәким ур., 17;
- Әлмәт, Маяковский ур., 60;
- Яр Чаллы, Муса Җәлил пр., 29/2 (ГЭС бистәсе 4/01), 3 нче кат, 314 нче офис.
- Түбән Кама, Шинчылар пр., 53А, 26 нчы офис;
- Чистай, Карл Маркс ур., 47А, 5 нче офис.

8-800-555-999-1 номеры буенча белешмә линия эшли (Россиядән шалтырату бушлай)

* РФ Үзәк банкының рәсми сайты мәгълүматлары буенча: www.cbr.ru/finmarket/supervision/sv_coll/

Лицензия № 288/2 ФСФР РФ. Ачыларга тиешле мәгълүмат чыганагы – nnpf.ru.
Фото «Милли ДБПФ» тарафыннан тәкъдим ителде. Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казанда Шаляпин эзләрен **КАЙЛАРДА** күрергә була

Фәндә дә, тормышта да **НИЧЕК** кеше булып калырга

Ташка уелган хәбәрләр **НИ** сөйли

Яшьләр күп кала торган авыл **КАЙДА** урнашкан

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ШАЛЯПИННЫҢ КАЗАНДАГЫ АДРЕСЛАРЫ БУЙЛАП

Бер танылган Мәскәү шагыйре болай дигән иде: «Соңгы елларда Казан бик нык үзгәрде. Европа затлылыгы пәйда булды аңарда. Әмма ун ел тирәсе элек килгән чакта аның манзарасы тәэсирлерәк булып хәтердә калган. Ун ел эчендә җылылык, Идел буе калаларына хас күркәмлек, провинциядә генә була алган ямь юкка чыккан… Аның яңартылган урамнары инде Шаляпинны да, Пешковны да, Хлебниковны да хәтерләми. Менә шунысы кызганыч».

Казанда Шаляпинны хәтерләтүче нинди дә булса эзләр калганмы соң? «Страницы из моей жизни» китабында безнең атаклы якташыбыз калдырган беренче хатирәгә тукталыйк әле. Ул үзе үк озын көй башы шикелле яңгырый: «Көзге кара кичләрнең берсендә утырам мин шулай Казанга янәшә Әмәт авылында, тегермәнче Тихон Карпович эргәсендә». Димәк, күрсәтелгән адрес буенча юлга кузгалабыз…

Автор:
Гадел Хәеров

Менә кайчандыр Әмәт авылы урнашкан тауга да килеп җиттек, бу тауны шәхси йортлар белән коттеджлар бизи. Кайчандыр бу авыл Казанның читендә урнашкан булса да, акрынлап шәһәр тарафыннан «йотыла». Дөрес, монда әле авылдагыча яшәү рәвеше, көнкүреш кагыйдәләре озак еллар буена сакланып килә.

КАЗАН ЭЧЕНДӘГЕ АВЫЛ

1970нче елларда биредә яшәгән туганыма кунакка сугылганда, кышкы юлларга мичтән алынган көлне сибүләренә үземнең дә шаһит булганым бар. Суны да көянтә белән яисә махсус агач чаналарга урнаштырылган сөт бидоны белән ташыйлар иде. Күпләр тавыклар асрады ул елларда, ә кайберәүләр күгәрченнәр дә тотты.

Хәзер инде манаралары һәм флюгерлары балкып утырган фазендалар пәйда булды. Шулай да, әле метро ачылгач та, монда сарык бәтиләре бәәлдәп торган сараена печән ташучы кәләпүшле бабайларны очратырга була иде. Бакчалардан юлга алмалар тәгәрәп чыгуын да онытасым юк. Кемдер мунча яга, һавага төтен исе тарала. Җирле халык урамнардан кәлүш яки өйдә кия торган чүәкләрдән генә йөри, көнбагыш яра.

Шаляпиннарны бер сум ярымга гына яшәп торырга керткән тегермәнченең килбәтсез йорты яныннан балачагымда йөзләп мәртәбә узганым булгандыр. Аның янәшәсендә туристлар белән тулы автобус тукталып торганын да, фотоаппаратларын кабызып, бер-бер артлы сурәт төшерүче туристларның үзләрен дә күргәнем булмады. Дөрес, күрше йорттагыларның 90нчы еллар уртасында бирегә бик җитди кыяфәтле бер карчыкның килеп, диварларны үбеп диярлек йөрүен сөйләгәне булды. Шулчакта күпләр монда кайчандыр Шаляпин яшәгәнен белеп ала да инде, ә теге карчык аның Америкада яшәүче оныгы булып чыга. Каршыдагы йорт тәрәзәсеннән күргән күренеш шушы еллар эчендә инде тәмам риваятькә әйләнгән: имеш, Федя утырырга яраткан бусаганы да ялт иттереп куйганнар океан аръягыннан килгән кунак өчен, шәмнәр сөреме белән капланган тәрене дә,

Фотолар авторныкы

тастымалга төреп, кулына тоттырганнар, күренекле якташыбызның балачак кулсызымнары сакланып калган обойны да кисеп биргәннәр. Бушка түгел, әлбәттә. Карчык бит бик бай графиня, диләр. Ул киткәч, өйнең хуҗасы үзенә «Жигули» сатып алган, хак булса...

Озакламый йортны кадаклап куялар һәм буйыйлар. Янәшәсендә кирпечтән ясалган ят бер төзелеш тә пәйда була. 1912 елда истәлекле урыннарны йөреп чыгу нияте белән Казанга махсус фотограф ияртеп килгән Федор Ивановичның үтенече белән ясалган сурәттәге йортка багам да аны танымыйм. Югалган бу йорт! Яңасы аны үз эченә тәмам «йоткан».

Янәшәдә генә елга чуерташы белән капланган таудан төшү юлы була. Әлеге юлдан Федорның әтисе Иван көн дә Земская управага эшкә йөри. Ул идарәдә писарь вазыйфасын башкара. Хәзер аның эш урынында – Жуковский урамы адресы буенча урнашкан бинада Әүһәдиев исемендәге музыка училищесы балкып тора. Кайчандыр өй белән эш арасындагы иң кыска юл шушы саналган. Тикшереп, үлчәп карадым: ярты сәгатьләп чамасы вакыт китә. Юл хәзерге Тихомиров урамы аша сузыла да, аннары Иван Шаляпин сукмак буйлап тау битенә күтәрелә торган була. Тау битендә Осокин агачлыгына килеп эләгә (1910 елда монда атаклы Шамов хастаханәсе пәйда була), агачлыкны узгач, Лядской бакчасына таба юл тота һәм эшенә дә барып җитә.

ЮКТАН БАР БУЛУ

Улы белән аралашу рәвеше үзенчәлекле була Иван Шаляпинның. Әтисеннән Федор ишеткән иң назлы сүз «скважина» була, хәер, кечкенә Федя ул сүзнең мәгънәсен барыбер дә аңламый. Ә инде иркәләүгә килгәндә, еш кына аны чалт итеп сугып җибәрүләр алыштыра торган була.

Әмма үзенең истәлекләрендә әтисен айный алмый эчә торган сәрхүш һәм гаугачы итеп сурәтләгән Шаляпин, миңа калса, буяуларның артык караларын кулланган.

«Ул алагаем зур таяк күтәреп миңа ташланды. Тотып үтерә икән, дип куркып, өстемдә нәрсә бар, шул килеш кенә урамга чыгып йөгердем. Җиңел генә ыштаннан һәм күлмәкчән хәлдә, яланаяклап, 15 градуслы салкында ике кварталны чабып уздым һәм дустым өенә кереп постым».

Шаляпин бу истәлекләрен язганда инде танылган артист булгач барлыкка килгән тормышы белән үткәне арасында контраст кирәклегенә төшенгән булса кирәк. Укучы аның нинди түбәннән – тормышның иң төбеннән күтәрелгәнен белеп шаккатсын, янәсе. Күрегез, ул хәзер Зур театр сәхнәсендә патша киемнәреннән балкый – коеп куйган Борис Годунов! Казаннан башкалага эләккән Шаляпин рус хыялының чып-чын үрнәге: юктан бар булганнарның берсе ул!

Шулай да вакыт-вакыт Федор, хатирәләргә бирелеп һәм китабының төп идеясе хакында онытып җибәреп, ә бәлки, күңеле нечкәреп китеп, мондый истәлекләр белән дә бүлешеп куя.

> «Аның чәчләре йомшак һәм һәрвакыт яхшы итеп тарап куелган булыр иде, андый матур причёсканы минем башка берәүдә дә күргәнем булмады. Безнең аралар йомшарып киткән чакта аның чәчләрен сыйпау – үзе бер куаныч иде. Әнием үзе тегеп биргән күлмәктән йөри иде ул, ул күлмәк тә йомшак тукымадан тегелгән, якасы кайтарып куелган, галстук урынына тасма тагылган. Ә инде соңрак, «фантазия» күлмәкләре пәйда булгач, тасма урынына бау тагып куя иде әни».

Ниндидер гади рус мужигына охшамаган сәрхүш сурәте килеп баса күз алдына, килешәсезме? Французга тартымрак... Шулай да, асылда нинди булган соң Иван Шаляпин? Әйе, балаларын ул артык иркәләмәгән, бишек каршында мөлдерәп хисләнеп утырмаган, үтенечләр һәм гаризалар язып, иге-чиге юк документларны күчереп язып, хәстәрләп, күз аллары караңгыланганчы эшләгән дә эшләгән. Әгәр айный алмыйча эчеп, иртән куллары калтырый торган булса, ничек каләм һәм кара белән эш итәр иде икән



1. Иван Шаляпин.

соң ул? Югары дәрәҗәле түрәләргә юллана торган гаять әһәмиятле кәгазьләрнең кайсыберләре нәкъ менә Иван Шаляпин гына яза торган «тантаналы» почеркны таләп итә торган була, җитмәсә. Мин бу кәгазьләрне үз күзләрем белән күрдем. Иван Шаляпин башкарган бу эшне, һич курыкмыйча, каллиграфия сәнгате үрнәге дип атарга була.

Әмма язвадан интегүче барлык писарьлар һәм канцелярия хезмәткәрләре кебек үк, өлкән Шаляпин да айга ике тапкыр егылып эчә торган була – аванс һәм получка алган көннәрдә, билгеле. Җанына шулай ял тапкан!

> «Кайвакыт, эчеп алгач, әти, уйчанланып китеп, югары, хәтта хатын-кызларча тавыш белән бик сәер сүзләр тезмәсеннән торган җыр суза иде. Бу җырны җырлаганда, аның тавышы сәер, чит булып яңгырый, чөнки олпат гәүдәсе белән бөтенләй тәңгәл килми:
>
> Сиксаникма,
> Четвертакма,
> Тазанитма,
> Сулейматма.
> Биштиникма!
> Дыгин, дыгин,
> Дыгин, дыгин!»
>
> Мин аңардан бу ботарлап-чатарлап көйләнгән татар сүзләреннән торган җырның мәгънәсен сорарга тәки җөрьәт итмәдем».

Мин әлеге сүзләр тезелгән кәгазьне бер татар фольклористына күрсәттем. Һәм ул шунда ук моның татар такмагы булуын искәртте. Җырның башында саннар һәм бик нык бозып җырланган сүзләр бара, ә азакта – «тагын, тагын» дигән кабатлау. Күрәсең, Иван әфәнде бу такмакны базарда йә булмаса кабак төбендә

Господину Казанскому Губернатору
Рапортъ

1. Рапорт үрнәге. Земская управа.

2. Сукно бистәсе. Хәзерге Калинин урамы (өскә күтәрелгәндә).

ишеткән инде. Бәлки, аны хәмердән кәефләнеп киткән татар агае башкаргандыр да, тирәсенә җыелганнар «тагын, тагын» дип кабатлагандыр. Халык арасында бер-берсен мәдәни баету шулай бара ул.

АЛАРНЫ КҮМӘЧ ТАНЫШТЫРА

Әбәт җиткәч, писарьлар кәстрүл белән төшке ашларын алып ашый. Портфельдән сөт салынган шешәләр чыгып, өстәлгә кунаклый. Нәкъ төшке аш вакытында монда кайнар күмәчләр белән баллы сойкалар күтәргән Алеша Пешков килеп керә. Ризык-нигъмәт тастымал белән каплап куелган – камыр ризыгыннан, авыздан сулар китереп, кайнар бу күтәрелә. Икмәк пешерү йорты янәшәдә генә – өч йорт аша урнашкан. Писарьлар – даими клиентлар. Чандыр, сөяктән генә торган гәүдәле Пешков, кызыл пута белән буып куелган, майланып беткән Бохара халатын киеп алып килеп керә, кашлары, мыеклары картлачларныкы кебек, ап-ак онга баткан була.

Фаразлар буенча, Федор Шаляпин Казанның иң түбән катламнарын өйрәнгән булачак язучы белән нәкъ менә идарәдә таныша да. Сүз арты сүз китә, аннан болдырга чыгалар. Һава менә дигән, бераз йөреп килергә уйлыйлар. Федор, мәкле күмәч чәйни-чәйни, Алешаның писарьларның характерларын сурәтләп бирүен тыңлый: «Ә беләсеңме, әнә теге тәрәз буенда утыручысы, йоны йолкынган казга охшаганы... Йә, әйт әле, нәрсәгә аңа каләм?! Ул бит борыны белән дә яза алыр иде...»

Мөгаен, Федор яңа иптәше янына Деренков пекарнясына да сугылгалагандыр. Подвалдагы «сукыр» тәрәзәләргә карап, анда ипи өчен камыр басучы эшчеләрне дә күргәндер, соңгылары эш барышында гел җырлый торган була, җитмәсә. Бәлки, яннарына да төшкәләгәндер, тыңлап торгандыр. Әмма он тузаны артык ябышмасын өчен, урамга чыкканнар күбрәк. Янәшәдә генә – Панаев бакчасы, эштән соң, анда да кергәләгәннәр булса кирәк.

Пекарня бинасы инде яңартылган, элеккеге хәлдә сакланмаган. Дөрес, подвалы – һаман шул ук. Ә менә Земская управа бөтенләй үзгәрмәгән – ни эче, ни тышы. Узышлый кергән идем: шул ук чуен баскычлар, һаман да исән бизәкләр, авыр биек ишекләр. Музей түгел-түгелен, тик монда шул чорның рухы яши һаман да. Әнә, скрипкасы белән бер малай тәрәзә төбенә чүмәшкән дә, кәгазьгә төрелгән пәрәмәчен ашап утыра. Икенче берсе ноталар кочаклап коридордан йөгереп узды. Класстан җыр яңгырый, монысының да – үз символикасы.

СУКОНКА ҖЫРЛАРЫ

Шулай бервакыт буран ерып «Сукно бистәсе» метросына ашыккан чагым. Бураны да буран минсиңәйтим: әйтерсең, җил бозлы канаты белән биткә бәрә, тоташ кар дивары аша үткән-сүткән дә күренми. Бозлы бу җил канаты мине Духосошественский чиркәвенең ишегалдына куып кертте, һәм мин чиркәү эчендә бераз гына җылынып алырга булдым. Тынлык. Шәмнәр янып утыра. Алтарь каршында атакайның үзенең һәм чиркәүгә йөрүчеләрнең аркалары күренеп тора. Кадило селкенә. Пышылдашулар ишетелә. Шулчак хатын-кызларның җыры яңгырый башлады, тавышлар гөмбәзгә кадәр күтәрелде. Хәтергә Шаляпин килеп төште: нәкъ менә биредә, регент Иван Осипович Щербининга кыюсыз гына караштыргалап, оялчан дискантын шушы гөмбәзләргә ирештергән бит инде ул да. Шул ук аркадалы диварлар, аларга сеңеп калган элеккеге аһәңнәр һаман да яши төсле. Бары бизәкләр һәм иконостас кына яңартылган.

Күзеңне йому да җитә, син инде анда – 1886 елда. Сукно базары артында, Түгәрәк тау (Шарная гора)

Фото Валерий Глазов архивыннан

3

4

итәгендә булачак артистыбыз һәм аның регенты бер түбә астында яшиләр ул чакта. Шаляпиннар гаиләсе подвалда диярлек көн күрә, ә ялгызак Щербинин – алар өстендә. Көндезләрен ул җырлауларны тыңлый: балалар тавышларының, нәзек алтынсу башак сабагыдай, күккә сузылуын гүяки күз белән күргәндәй буласың. Ул тавышларны укытучылары өстәлгә линейка белән сугып туктатып та кала. Ә хор ягымлы, тәңгәл яңгыраганда, йортка яктылык тулгандай була. Әйтерсең, өй, шапшак Суконка йортлары тезелгән урамны калдырып, һавага күтәрелә һәм тирбәлә, тирбәлә...

Әмма төннәрен янә кара кеше пәйда була, һәм аның кулында яшел ут булып кайнап шешә чайкала. Бу адәм инде бөтенләй башка җырлар җырлый. Пычрак, башбаштак, оятсызларны. Иван Шаляпин, мендәр белән капланып, хәйран кала торган була: «Ничек бу җен пәриен чиркәүгә кертәләр микән?!» Ә менә Федя укытучысын кызгана. Аныңча, әтисе «тавышка китү»нең нәрсә икәнен күз алдына да китерә алмый. Клиростагы җырчылар бит, җырга күмелгәндә, Егор, Митя, Федя булудан туктый... алар, шәһәр паркындагы фонтанның суы шикелле, бер тавыш агымына әверелә. Аларны тыңлаган чиркәүгә килүчеләрнең күзләреннән яшь тамганчы, шәмнәр калтырап гөмбәзгәчә үрелгәнче...

Яхшы башкарылган җырлардан хәтта регентның да күзләре яшьләнә кайчак. Служба тәмамланганнан соң, ул, хорны җибәреп, якындагы гына трактирга юл тота. Әлеге трактирда Пушкин үзе йон заводындагы бер эшче белән гәп корып утырган дип сөйлиләр. Федяның Щербининны трактир ишегенә каршында каравыллаган чаклары еш була. Малай регентның еш кына стаканы өстенә иелеп йокымсырап утырганын да күрә.

> «Ул чәчләрен озын итеп йөртә һәм артка таба тарап куя, зәңгәр күзлек кия иде, болар һәммәсе дә үзенә җитди һәм затлы төс бирә. Өстендә җиңсез кара халат булыр, башында – башкисәр шапкасы. Артык күп сөйләшмәс. Әмма шушы затлылыгына да карамастан, Сукно бистәсендәге бөтен халык кебек үк, егылып эчә».

Щербинин кабактан инде шапкасын калдырып чыга торган була. Күзлекләре дә, әллә хәмердән, әллә хуҗасының чалыш адымнарыннан, келтерәп тора. Федор, ләх булып чыккан укытучысына иңен куеп, аны бусагасына кадәр илтеп куя. Кайтырга ерак та түгел-түгелен, тик регентның аяклары кабат трактирга таба борылырга алгысый.

Ходайга һәм Бахуска хезмәт итүче әлеге бәндә Шаляпинның талантын күреп алучы беренче кешеләрдән була, нәкъ менә ул Федяга ноталар таттыра, малайны «авыз белән түгел, ә күкрәк белән җырларга» өйрәтә. Аны чиркәүгә алып килә. Федор үзенең әле ул чакта хәлсез генә тавышын чиркәү гөмбәзе астында ишеткәч, беренче тапкыр гармония тоя. Гәрчә ул сүзне ул вакытта ишетеп белмәсә дә.

Казандагы төбәкне өйрәнүче Сергей Саначин халыкта Горловой исемен йөртүче әлеге кабакны эзләп таба. Бирегә килүчеләр тамакларын җыр белән иркәләргә яратканга да кабак Горловой исемен йөрткән, имеш. Ул инде күптән юкка чыккандыр, дисәләр дә, сакланган кабак. Таш йөзлекләр белән бизәлгән бер катлы тыйнак кына йорт эчендә хәзер банк офисы урнашкан икән, ул үзе Петербургская урамындагы 5нче гимназия каршындагы чыршылар артында яшеренеп утыра. Идән такталарын куптарып карасак, ярыкка төшеп тәгәрәгән бөке белән тиен-мазарны да табып алып булыр иде, минемчә.

Шаляпин тематикасына йөз тоткан Казан рестораннарының берсендә менюда «руанча


5

3. Сукно бистәсе.

4. Сукно бистәсе һәм Сошествие Святого Духа храмы.

5. 5 нче гимназия янындагы Горловой кабагы.

1. Фёдор Шаляпин җырлаган Варвара чиркәве.

үрдәк» бар, ул артистның яраткан ризыгы буларак тәкъдим ителә. Коровин исемле рәссамга язган хатында Шаляпин үзе исә, киресенчә, Парижны басып алган әлеге үрдәкләрдән гарык булуы турында яза. Хатында ул катык катып ашый торган рус пилмәннәрен сагынуын ассызыклый – «мин ул ризыкны комсызларча яратам», – ди. Пилмән Шаляпиннар йортында бәйрәм ашы исәпләнә, ә гадәти көннәрдә әниләре гади генә «мура», ягъни кваска нигезләнгән сыек аш әмәлли торган була. Бу шулпага арыш сохарие ваклыйлар, бәрәңге, суган, тозлы кыяр салып, киндер мае өстиләр.

Гел ач йөри торган Федя, чиркәүдәге клироста, йә булмаса туйларда, җеназаларда җырлавы өчен тиен-миеннәр тәти калса, шунда ук кабакка йөгерә торган була. Әйе, әйе, теге кабакка: анда ул кичәгедән калган щи белән тавык алып, туйганчы ашый. Чәйне дә варенье белән эчә хәтта, ә менә алма бөккәнен, хәстәрләп төреп, әнисенә кучтәнәч итеп алып кайта. Җырлавы белән эшләп алган вак-төякне шулай ук яраткан театрына, шапито белән Яшка балаганына тота. Соңгысы халыкны хәзерге Ленин бакчасы урнашкан урындагы ярминкәдә җәлеп итә торган була. Шулай да акчаның яртысын, нигездә, әнисенә алып кайтып тапшыра. Әнисен ярата ул, кызгана.

«Мин чын күңелдән ышанган һәм җанымда яшәгән барлык уйларны, хыял-өметләрне сөйли алган бердәнбер кеше ул иде. Әтине тыңларга кушып, ул мине асылда тормышның авыр булуына, аңа яраклашырга кирәклеккә төшендерде. Шулай ук – эшләргә кирәклегенә, чөнки ярлының, эштән кала, яшәве юк. Аңа берәү дә юл ярырга тормый».

Ул чактагы кабаклар тәрәзәләрендә пәрдәләр эленеп торган, тәрәз төпләрендә яран гөл үсеп утырган зур ызбалар рәвешендә булган. Тәрәз төпләрендәге гөлләр арасында песиләр йокымсыраган. Ә диварларда Казан песие турындагы рәсемнәр эленеп торган. Чебеннәр мыжлаган. Чисталыгы да чагыштырмача булган, билгеле. Бәйрәмнәрдә болдырга империя флагын чыгарып элгәннәр. Керә торган ишекне чыршы гирляндалары белән чәчәкләр бизәгән. Меню булмаган. Бүген, әйтик, жумба балыгыннан уха пешсә, иртәгә исә кыздырылган май кисәгенә пешкән борщ көткән. Җәйгә чыккач, әлбәттә, окрошка даими әзерләнгән. Икенче ашлардан бәрәңге, сельдь балыгы, тозлы кыяр өстәлдән төшмәгән. Ишегалдында самавырлар кайнап утырган. Аракыны графиннарда да биргәннәр, чәркәләп тә. Нигездә, ирләр җыела торган булган кабакларда. Гаиләләр белән йөрү ярамаган. Эшчеләр хезмәт хакы алган көннәрдә кабак чын мәгънәсендә халык ташкыныннан мыжлаган. Гармунга җырлап, типтереп биегәннәр. Бу җыр-биюләр еш кына савыт-саба вату, сугышу белән тәмамланган. Полицай чакырып, исерек халыкны куып тарату очраклары да еш булган. Ирләрен кабак ызбасы почмагында каравыллап, өйгә алып кайтырга килгән хатыннар тезелешеп торган. Имин кайтып җитүе, акчасыннан бөтенләй колак какмавы кадерле булган.

«Бу тоташ мәхшәр көннәре иде; кешеләр, кешелеген җуеп, бер мәгънәсезгә акырыша-бакырыша, сугыша, елый, пычракта ауный. Андый чакларда тормыш миңа куркыныч, җирәнгеч булып тоела иде...»

70нче елларда мин Тихомирнов урамы, 7 йорт, 9 фатир адресы буенча «сиреньле тәрәзләре» белән билгеле сәүдәгәр йортында яшәдем. Шулай бервакыт, Качманган кичтә, «Победа» кинотетары артындагы (хәзер анда Г. Кариев театры) күрше ишегалдында йорт яна башлады. Кешеләр фатирларда яшәүчеләрне уятып тыз-быз чабыша. Ут күрше йортларга да төшмәсен дип котлары очты. Анда бит барысы да агачтан! Мине, төреп, урамга алып чыктылар. Хәзер дә күз алдымда тора ул күренеш. Эре йолдызлар белән бизәлгән кышкы төпсез зәңгәр күк һәм «Унике ай» әкиятендәге зур учак кебек дөрләп утыручы ике катлы агач йорт. Янгынны туктату мөмкин дә булмагандыр, күрәсең. Мин ул йортны яхшы белә идем: без анда әллә ничә тапкыр качышлы уйнадык. Шыгырдап торган идәнле озын караңгы коридоры, аның иң түрендә элпә генә нур төшә торган тәрәзәсе. Шомарып, пеләшләнеп беткән тар баскычлар өскә алып менә.

Инде студент булгач, төбәк тарихына кагылышлы китапларны укый-укый, мин ул йортта Шаляпиннар торганын белдем. Бу хакта белгән кешеләр күп булган, әмма никтер саклау табличкасы да элеп куярга кирәк тапмаганнар. Хәер, ул табличка гына иске йортларны юк итү кебек масштаблы проектны тормышка ашырганда Шаляпин йортын саклап кала алыр иде микән, белмим. Могҗиза булган очракта да ул хәзерге яңа йортлар арасында бер мескен булып утырып калыр иде, миңа калса.

Ә бит Суконка Шаляпинга күп нәрсә бирә. Бу эшчеләр бистәсендә үскән кеше теплица шартларындагыча үсә алмый, ул тормышның ачысын да, төчесен дә татый. Нәкъ менә шул тормышның бар якларын күреп үсү халыкка Шаляпин кебек шәхесне бүләк итә дә инде. Василий Качалов аңа артист буларак кына түгел, ә табигатьнең камил бер үрнәге буларак та соклана идем, дип искә ала:

«Әйтерсең, кечкенә, уртача кемнәрнедер үрчетү Россиянең үзенең үк теңкәсенә тия дә, ул менә шушындыйны бар итә – олпат, иркен, колач җитмәстәйне. Инде бүтән беркайчан да мондыйны кабатламас өчен ярата ул аны гүя. Талантының зурлыгы турында гына әйтмим, ә чын ир-атларча мәгърурлыгы турында да. Күреп торасыз бит: читекче итеп яратмый ул бу ир-егетне, ә артист итеп!»



2. Кабан күле.

Ютубта Шаляпинның бер генә җырын – «Прощай, радость, жизнь моя» дигәнен тыңлау да җитә, хәтта шушы торгызылган язма да артистның тавыш көчен һәм олпатлыгын тоемларга мөмкинлек бирә. Бу безнең Суконка тавышы бит! Рус җанының колач җитмәслек киңлеге, хөрлеге! Шаляпин инде бөтендөнья күләмендә танылган артист булып җитешеп, чит илләрдә рус кешеләренең үзара аралашуларын күзәткәндә, ачу ташкыны кинәттән хис-тәэссораттан тулышкан күз яшьләренә әверелгәндә, болай дип кабатларга яраткан: «Суконканы без һәрчак үзебездә йөртәбез!» Ул аның йөрәгендә соңгы сулышынача йөргәндер, ышанам.

Казанда Федор Шаляпин дүрт адрес буенча яши, ике йорт инде фотосурәтләрдә генә сакланып калган. Ул укыган 6нчы номерлы шәһәр училищесы урынында хәзер «Туган авылым» ресторан комплексы җәйрәп утыра. Бу шәһәребезнең әле һаман төзәлеп бетмәгән иң соңгы югалтуларыннан берсе.

Ә менә Шаляпин җырлаган чиркәүләр бик яхшы сакланган. Мәсәлән, Варвара чиркәве. Аның эче яңартылган, билгеле, әмма диварлар бит үткәнне онытмый! Җырчының биографиясендәге иң төп чиркәү – Богоявление чиркәве, Шаляпинны биредә 1873 елда чукындыралар. Ләкин, ялгышлык белән, чиркәү-приход кенәгәсенә Шляпин дип теркәп куялар. Тәбәнәк кенә зәңгәр төстәге бу чиркәү Баумандагы Воскресенская чаңы артында тыйнак кына тора бирә, даһи бас иясенә куелган һәйкәлгә якынрак килсәң, күрергә була үзен. Чиркәү эчендәге акустика гаҗәеп! Әлбәттә, акустика барлык чиркәү-храмнарда да яхшы, әмма биредә ул үзенә бер төрле. Пышылдап кына әйтелгән догалар да ишетелә, тәреләр каршында пыскыган шәмнәрнең җиңелчә тавышы да...

ОЧЫП КИТТЕ УЛ!

«Минем тормышым сәхифәләре» мемуарларын Казандагы Шаляпин урыннары буйлап юл күрсәткече буларак кулланырга мөмкин. Нидер сакланган, нидер юк. Мәсәлән, Ново-Комиссаровская урамындагы (хәзерге Мөштәри урамы) Чернояров исемле сәүдәгәр йорты, бирегә йорт хуҗасы чиркәү хоры малайларын данлау җырлары җырларга чакыра торган булган, соңыннан аларны тәм-том белән дә сыйлаган. Яисә Панаев бакчасы, монда кайчандыр Шаляпинның уңышсыз дебюты була. Ул үзе бу хәлне шаярып искә алырга ярата:

«Аякларым, әйтерсең, сәхнә келәмнәренә ябышып катты, кулларым – ян-якларыма, ә телем... телем бөтен авызымны тутырып кабарды да агачка әверелде диярсең. Сүз дә әйтә, бармагымны да селкетә алмыйча тик катып калдым. Пәрдә артыннан тавышлар ишетелә:
– Әйт инде берәр сүз, шайтан алгыры!
– Аһ син, җир бит, әйт ни дә булса!
– Муен тамырына менеп төшкере... »

Монда хәзер «Динамо» стадионының буш трибуналары да туп артыннан йөгереп йөрүче берән-сәрән фигуралар гына күренгәли. Кайчандыр җәйге театр ызбасы булган, рестораннар, буфетлар гөрләп эшләп торган, эскәмияләр урнаштырылган бакча җәелгән булган дип уйламассың да.

Кабан күлендә, аның Вахитов мәйданына илтүче, ягъни күпергә барып тоташа торган өлешендә, йөзьяшәр өянкеләр һәм камыш чатырманнары сакланып калган. Бераз гына ары барсаң, Шаляпин мемуарларында сурәтләгән манзара ачыла:

«Кабанда җәйләрен искиткеч рәхәт, ә кышын – тагын да яхшырак. Рәхәтләнеп зәңгәр боз буйлап тимераякта шуарга мөмкин, бәйрәмнәрдә кул сугышлары уздырыла, бу тамашаны бик өнәмиләр, билгеле. Кул сугышында катнашучылар икегә бүленә иде: бер якта – без, Казан Русе вәкилләре, икенче якта – ихлас күңелле татарлар. Сугышны балалар башлап җибәрә. Тимераякта очып барганда, кинәт, күз иярмәгән җирдән, татар малае килеп чыга да, йөзеңә китереп сылый, аннары һай-һайлап алга ыргыла. Ә син җимерелгән борыныңа кар куеп, ачу белән түгел, ә кисәтүле бер гыйсъян белән сукранасың: «Тукта, күрсәтәм әле мин сиңа күн чырай!»

Җәйләрен Федор дуслары белән яр буена камыштан шалаш ясап куя торган була. Монда алар балык тоталар, уха пешерәләр, су коеналар. Бераз үсә төшкәч, Шаляпин бу ярларга үзе генә килеп йөрергә ярата. Агач башына менеп утырып, хыялланып утырган.

«Мине җәйләрен, бигрәк тә җәйге төннәрдә, Кабанга тарта иде. Яр буена барып утырам да, олы өянкеләрнең берсенә менеп кунаклыйм, яктырганчы, төнге кош шикелле, шунда утырам. Күлнең йөзенә карап уйланам. Мондагы тынлык миңа уйларымны тәртипкә китерергә мөмкинлек бирә иде, Сукно бистәсендәге тормыш түбәндә агып ята, ә мин, барлык шапшаклыклардан аруланып, биектә йөзәм».

Революциягә кадәр чыккан газетада мин бер Казан беллетристының мондый пассажына юлыктым:

«Шаляпин, аккош шикелле, югары очыш турында хыяллана. Кечкенә Федя, ботакка менеп утырып, Кабанның караңгы суларына төбәлеп, башкала һәм ерак илләр хакында уйлый. Һәм менә – очып китте дә ул! Еллар уза тора, ә Федор Шаляпин туган каласына җырлары белән әйләнеп кайтып тора». ■


Москва
ПРИДВОРНЫЙ ФОТОГРАФЪ


Афзал Шамов
Татар Танае
Габдулла Тукай
Кушлавыч
Янка Купала
Печищи
Туфан Миңнуллин
Мәрәтхуҗа

«Татарстан» журналы моннан ике ел элек башлап җибәргән «Кече ватан патриотлары» проектының максаты – татарстанлыларны, кызганычка каршы, исемнәре инде онытыла башлаган республиканың талантлы һәм иҗади шәхесләре белән таныштыру. «Татарстан» республика халкы арасында уздырган сораштыруларга караганда, Абдулла Алиш, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур кебек атаклы исемнәрне атаганда, «ниндидер танылган кеше», «урам исеме», «җавап бирергә кыенсынам» кебек җаваплар алынды...

Әлеге проект кысаларында Татарстанның талантлы якташларыбыз эзләре сакланган районнарга, төбәкләргә барабыз. Туристлык маршрутларыннан читтәрәк урнашкан булсалар да, әлеге музейлар, танылган шәхесләр туган йортлар – Татарстан җиренең чын күренекле урыннары.



PRESSA.RU

«ФӘН УЛ – ОБЪЕКТИВЛЫК ДИГӘН СҮЗ»

Аның дәресләре дә, ул биргән курс эше, диплом эше, диссертация темалары да башка бер генә укытучыныкы, галимнекенә дә охшамаган иде. Ничә еллар белсәм дә, «Резеда Ганиева» дигән феноменга ахыргача төшенеп җиткәнем юк әле минем. Әйтерсең, дөньяны уратып алган акыл субстанциясе аның кечкенә генә җыйнак гәүдәсе аша иректе рәвештә циркуляция ясый да, Резеда апаның тирә-юнендәгеләргә дә таралып өлгерә. Менә дигән мөгаллим булуына өстәп, чын кешелеклелек үрнәге дә Резеда апа.

Әңгәмәдәш:
Луиза Янсуар

Фотолар: Резеда Ганиева һәм Зөфәр Рәмиев архивыннан

Үз гомеремдә 7 кешенең каберенә таш куйдырдым. Әнием, ике абыем, сеңлем, энемнән башлап... кызыма һәм әтиемнең абыйсына кадәр. Бу минем намус эшем, киткәннәрнең рухы разый булсын. Безгә рәнҗемәсеннәр. Ирем Зөфәр дә туганнары каберенә ташлар куйдырды. Әтиемнең кабере Ленинградта Серифимов каберлегендә. Аның каберен зыярәт кыла алуыма, әниемә күрсәтүемә сөенәм. Шөкер, балаларны, оныкларны да алып барып, бабаларының каберен күрсәтә алдык. Зөфәрнең әтисе Мәскәү янында ятып калган булган, аныкын да онытмыйбыз.

Ачлык-ялангачлык җелегебезгә үткән буын без. Сугышның башында ук дүрт бала әтисез ятим калдык. Өстәвенә – ике карт әби! Әниебез 2нче группа инвалид. Ухылдап узган товар поездының вагоннарына үрмәләп менеп, кокс, такталар ташлый идек юлга, чокырларга, аннары сикереп төшеп калабыз да, җыеп алып кайтабыз. Ягулык була. Әле ярый сыерыбыз бар... Әмма бервакыт ул сыерны да тартып алырга җыеналар, дигән хәбәр килде. Әни коелып төште, хәсрәткә батты. Колхозларда ат та, үгез дә бармак белән генә санарлык еллар. Сугышка киткән атлар урынына сукага җигәргә алмакчы икәннәр безнең малкайны. Зәйнәп апа исемле туганыбыз коткарды: ул милиционер, әзмәвер гәүдәле чая хатын. Билбау каешына револьвер тагып кына йөри. Менә шул Зәйнәп апа киңәше белән әни малкайны камчы белән ярды. Җәрәхәтле сыерны, барыбер җигәргә яраксыз, дип, бездән тартып алмадылар. Акрынлап тернәкләнде бичара, кабат сөт бирә башлады. Ул безне ачлыктан саклап калды.

Дөньяда бер нәрсә дә – юктан бар, бардан юк булмый. Һәр вакыйганың үз сәбәбе бар. Фәнни итеп әйтсәк, «сәбәп – нәтиҗә» җепләре белән уратып алынган тормыш-көнкүреш. Кешенең кылган нияте, догасы бик зур роль уйный, ул безнең иртәгәге көнебезне билгели, язмышыбызны.

Карт бабабыз берара Казанда суфыйлар даирәсе белән аралашкан. Каты хаста булган ул чакта. «Камчылы ишан» кушаматлы рухани аны камчысы белән «пешереп» кайтарган – дәвалау ысулы шундый булган, дип сөйлиләр ул руханиның. Шуннан, ни гаҗәп, бабабыз тернәкләнеп китә. Минем әнием дөньяга килә.

«Мең сум эчендә ничә йөз сум барын беләсеңме?!» Бер хәлле генә туганыбыз әйткән шул сүзләрне үзем исәндә онытасым юк. Әни бөтенләй хәлсезләнгәч, әтиебез васыяте буенча укыйсыбыз да килгәч, Казанга күченергә ниятләдек. 13 меңгә авылдагы йортны саттык та калада 30 меңлек йорт юнәттек. Киттек теге туганыбыздан бурычка акча сорарга. Бирмәде. Аның сүзләрен ишетеп, акчага, дөнья малына карата зур дәрес алып кайттым. Ул йортта матди байлыкка мөнәсәбәт әле дә шундый. Дәреснең аннан да зуррагын икенче бер туганыбыздан алдым. Маһитап апаның җәмәгате – җизнәбез акыллы, укымышлы кеше иде. Өйләрендә пианино бар, безгә шул пианинода бик матур итеп уйнап күрсәтте. Уйнап бетергәч, сузып кына болай диде: «Маһитап, безнең бит сандыкта бер төргәк акча бар, биреп җибәр шуны Хәбирә белән балаларга, сатып алсыннар үзләренә ул иске йортны». И сөенгән идек шул чакта! Мин укыта башладым, туганнарга бурычны акрынлап, өлешләп-өлешләп кайтарып бетердек.

Кешене мал белән, дан белән сыный Ходай. Икесенә дә гомерем буе аек акыл белән карый алдым, шөкер. Без бит михнәтнең нәрсә икәнен татып үстек, шуңа артык борыныбыз күтәрелмәгәндер. Әллә никадәр дөнья малларына да ия булмадык. Төп байлыгыбыз гыйлем һәм китап булды. Аннан да зуррак хәзинә уйлап табылмаган әле җир йөзендә. Бар да китә, бетә, юкка чыга, ә сүз, гыйлем кала.

Гомерем буена талантлы кешеләрне ихтирам иттем. Талант – ул бит Ходайның сулышы белән тоташып яшәү. Андый кешеләрнең язмышы да, тормышы да җиңел булмый, кайчакта хәтта – аянычлы. Җир канунарына, кагыйдәләренә сыешып яшәп кара әле син, даһи булып! Үзебезнекеләрдән Тукайны гына алыйк, Дәрдемәндне, Исхакыйны, Әмирханны... бүгенге заманның талантлы шәхесләрен – һәрберсе күз алдында дөрләп, янып китеп бара. Үзләрендә адәм баласы гына сыйдырып бетерә алмастай алагаем зур көч йөртәләр чөнки. Талантлы кешеләрне һәрчак яклыйсым, саклыйсым килде. Ярдәм итәсем...

Фәндә дә, тормышта да аек акыллы булырга кирәк. Фән ул –

Казан дәүләт университетында эшли башлаган еллар.

PRESSA.RU

Мәскәүдә укыганда.
Август, 1961 ел.

Резеда Ганиева фикеренчә, татар әдәбиятында Ренессанс хәрәкәте өч баскыч үткән. Аның беренче баскычы Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорына – дәүләтләребез булган вакытларга туры килә. Рус дәүләтенә кушылгач та, халкыбыз торгынлык халәтенә дучар була. Бары тик XIX гасырның икенче яртысыннан, Каюм Насыйри эшчәнлеге башлангач кына, татар халкының Яңарышка – европалашуга омтылышы башланып китә. XX гасырның беренче чирегендә исә татар мәдәнияте, әдәбияты, җәдитчелек идеологиясе казанышларына таянып, моңарчы беркайчан күрелмәгән Ренессанс биеклекләренә күтәрелә, поэзия, проза һәм драматургия үзенең алтын үсеш баскычына баса. XX гасыр азагында коммунистик идеология тарих сәхнәсеннән төшкәч тә, алгарыш һәм дә чигенешләр белән татар халкының өченче Яңарышы башланып китә. Ул әле бүген дә дәвам итә.

субъективлык хөкем сөрә торган өлкә түгел, фән ул – максималь рәвештә, булдыра алганча объективлыкка, алгарышка омтылыш. Чын иҗат та – шулай. Шагыйрьләр дә, галимнәр дә асылда бер Чыганактан – Күкләрдән ала мәгълүматны, һәр ике очракта да илһамсыз булмый. Әмма ул илһамлы мизгелгә кадәр баш миендә никадәр процесс бара, никадәр хезмәт. Һәм илһамнан соң күпме сөзәсең янә фикерне... Язганнарны актарып карыйм да, аңлыйм: әйе, ялгышлар да булган, чалулаган чаклар да, әмма, мөмкин булганча, хакыйкатькә якынаерга омтылдым. Кайдадыр, аз-азлап кына булса да, моңа ирешә дә алдым шикелле. Шунысына сөенәм.

Төшләргә һәм Илаһияткә ышанам. Адәм баласының баш мие – искиткеч механизм. Олы бер аккумулятор. Әнә шул аккумулятор галәмдәге энергетик кырларга тоташа алу сәләтенә ия. Бар да идеаль уйлап табылган.

Галимнәр дөньяны акка-карага бүләргә тиеш түгелләр. Алар күзәтүче булырга тиешләр. Анализлаучы.

Гыйлем, фән минем өчен һәрчак беренче урында булды. Гомерем буе анаданлыкны күрә алмадым. Кияүгә дә акыл белән уйлап чыктым. Артымнан йөрүче, тәкъдимнәр ясаучылар шактый булды. Әмма башымны җуеп гашыйк булганымны хәтерләмим. Башта гаиләбезне карауны төп эшем дип санадым, аннан – укытуны, ә аннан инде – фәнне. Артымнан берьюлы берничә егет йөргән чак: киләчәктә исеме мәгълүм булачак шагыйрь дә бар араларында, берсе – Зөфәр абыегыз. Әни шагыйрьне беренче күрүдә үк өнәмәде, ә менә Зөфәрне ошатты. «Кызым, менә монысы тыйнак, басынкы холыклыга охшап тора, синә аның белән яшәве җиңел булыр», – диде. Яшем утыздан узган, бәби алып кайтырга вакыт, тоттым да сайладым Зөфәрне. Әни хаклы булып чыкты.

Гаиләдә беребез баш, беребез муен, дип түгел, ә бер организмның өлешләре без, дип яшәдек. Каенанамнан искиткеч уңдым, ул мине бик хөрмәт итте, «Резедәкәй» дип кенә торды. Чын дуслар идек. Хәтеремдә: Гаяз Исхакый исеме яңадан әйләнеп кайткан еллар, мин махсус курс әзерлим, аның буенча лекцияләргә әзерләнәм. Түгәрәкләнеп, өстәл артына җыелышып, Зөфәр белән әнкәй Исхакый әсәрләрен кычкырып укыйлар, берсе арыса, икенчесе дәвам итә. Миңа, лекциягә әзерләнүчегә, ярдәм итүләре. Әнкәй бик кешелекле иде. Ваннага яткырып юганда, күз яше белән елаган чакларын хәтерлим: «Мине болай тәрбияләп кем юсын тагын, Резедәкәй». Аның миннән разый булып китүен тою зур канәгатьлек бирә күңелемә.

Балаларны артык назламадык та, тиргәмәдек тә. Үз җае белән үстеләр. Шөкер, акыллы, белемле булдылар. Улыбыз Булатның хәләл җефете дә фән кешесе, алар Төркиядә яшиләр, шунда укыталар. Рәхмәт киленемә, фәнне дә ташламады, Булатка өч кыз бала да бүләк итте. Алар да акыллы балалар булып җитешеп киләләр. Олы кызлары Бостон университетына укырга керде, уртанчы кызлары Франциягә җыена. Кече кызларына әле дүрт кенә яшь, мин аны «индиго-бала» дип атыйм, ут чәчеп тора, шундый белдекле. Бәхетләре генә булсын!

«Безнең кафедрада бер генә ир-ат бар, ул да – җенесе буенча хатын-кыз затыннан». Мөхәммәт Мәһдиев минем хакта шулай диган иде. Дус булдык. Гомумән, фәндә дошманнарым юк минем, ә тормыш-көнкүреш шартларында еш кына вакчыллык, түбәнлек белән очрашырга туры килә, кызганыч. Югыйсә без бит югары белемле, аңлы-фәһемле кешеләр, ләкин, юк, фән өлкәсе спекуляция, фальсификация, бер-берең белән узышлы уйнауларга корылган. Мин университетка килгәндә, фән өлкәсендә хатын-кызлар сирәк иде, татар әдәбияты фәнендә – әйтәсе дә юк. Һәрчак үз урынымны яулап, булдыра алганымны исбатлап яшәргә туры килде. Үткенлегем дә булышкандыр, мөгаен. Мин берәүдән дә курыкмадым, берәүгә дә ялагайланмадым, астыртын эш йөртмәдем.

Ул вакытта укырга Мәскәүгә барырга җөрьәт итүчеләр сирәк иде. Мин бит Казан педагогия училищесыннан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын читтән торып тәмамладым. Дөрес, кызыл диплом белән. Укыта идем, гаиләне карарга кирәк. Тәвәккәлләп, Мәскәү дәүләт университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасына аспирантурага барып кердем. Нәзек кенә бер кыз – карап

торышка, әмма бездә рух көчле булган, күрәсең, дәрт.

Фән ир-егетләр өлкәсе дигән сүз белән килешмим. Акыллы хатын-кызларыбыз да җитәрлек. Безнең заманда хатын-кызга белем җитмәде, әле дә җитми. Әмма бүген инде хатын-кызлар, яшәргә күбрәк яраклашкан токым буларак, алга ыргылды. Мин безнең хатын-кызларны гомерем буена жәлләдем. «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендәге Гөлбану кебек яшәдек бит әле без узган гасыр буена. Миндә гел аспиранткалар күп булды: татар хатын-кызларын мәгърифәтле итәргә, кулларыннан җитәкләп, гыйлем дөньясына алып керергә теләгәнмен, күрәсең.

Кешеләрне җенес буенча бүлеп-аерып эш йөртмим. Кешедә, иң беренче чиратта, кеше булырга тиеш. Аннан гына – галим, иҗатчы, талант иясе. Синең холык-табигатең башка адәми затларга зыян китерә икән, Ходай биргән сәләтеңнең файдасы да – ташка үлчим. Шәрык культурасында һәм Ренессанс тәгълиматында «камил инсан» төшенчәсе юкка гына иң югары кыйммәт буларак исәпләнми. Безнең татар мәдәниятендә дә ул борын-борыннан килә. Күлтәгин язмалары, Йосыф китабы чорларыннан ук.

Тукайны жәлләп төннәрен елыйм. И күргән дә инде, бичаракаем! Һаман тынгы бирмиләр үзенә! Гомерем буена кызгандым мин аны. Кара син, Галимҗан Ибраһимов 1914 елда ук ничек изеп-бетереп ташлый үзен. Ятим үскән шул баланың Тукай биеклегенә күтәрелә алуын Ибраһимов җаны белән тоемлап, әчтән кичереп язмаган, әлбәттә. Ярый, Тукайны үлеме коткара. Ә калганнарны инкыйлаб давыллары «кораб» калдыкларыдай бәргәләп йөртә дә йөртә… Барысын да кызганам. Ул язмышларны уйлый башласаң, чәчләрең үрә торырлык лабаса…

Минем хакта «эксцентрик характерлы» диючеләр күп булды. Бу сүзләрдә хаклык бардыр, лекцияләр укыганда, мин үземне транска кергән суфыйлар кебек хис итәм чөнки. Фикерләр өермәсе эченә кереп чумгач, үземне онытам…

Халык хәтере – искиткеч көчле нәрсә. Шулай бервакыт Финляндиягә бардык. Татар әдәбияты, тарихы буенча лекцияләр укыйбыз. 600 кеше җыелган зал. Мин, мөнбәргә мендем дә, XX йөз башы татар әдәбияты турында сөйли башладым. Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендәге «Кайсы юллар, нинди упкын тарта безне, җан сорап?» дигән өлешен укыганда, күрәм, алдагы рәтләрдәге ирләр күз яшьләрен уч белән сыпырып-сыпырып ала.

Миңа хәзер берни дә кирәкми. Яшисе гомерен яшәгән һәм догалары, уйлары белән хөҗрәсенә кереп бикләнгән суфый кебегрәк хәлдәмен. Барлыгымны онытучылар да җитәрлек, хәтерләүчеләр дә бар. Минем әле һаман да эштән туктап торганым юк. Кеше бит ул башкаларның күзенә черки кебек кереп торса гына, истә саклана, кирәк санала. Заманы шундый. Беркайчан да яратмадым андый очсыз уеннарны.

Кешегә исемнәр генә ихтирам өсти алмый. Ул ихтирамны син гомерең буена кылган эшләрең белән яулыйсың, аңа әле лаек булырга кирәк. Минем өчен бүгенге көндә иң кадерле исем – Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе. Булды Мәскәү бүләкләре һәм исемнәре дә, кайберәүләр нәкъ менә шуларны абруйлырак дип исәпли. Миңа үз республикамныкы газизрәк.

Миңа һәрчак үз эш бүлмәм һәм лекция укыган аудиториям кадерле булды. Чөнки нәкъ менә аларда чын-чынлап энергия алмашы, алхимия процессы бара.

Безгә тәнкыйди реализмнан классик реализмга күчәргә вакыт. Татар әдәбиятында хәзер бу тенденция сизелә. Соңгы еллардагы татар прозасын күзәтеп, шундый фикергә килдем. Моны киләчәктә сезгә тормышка ашырасы.

Резеда Ганиева улы Булат һәм кызы Халидә белән.

Ренессанс сүзен татар әдәбиятына кертеп җибәргәнем өчен үкенмим. Матур яңгырый бит, безне дә эстетик яктан баета. Күп еллар дәвамында без совет иленең «кече халкы» һәм «кече әдәбияты» булып яшәдек. Мин бу гаделсезлекне һәм катып калган карашны үзгәртер өчен гомеремне багышладым. Шөкер, без әдәбиятыбызның һәм Шәрык, һәм Гареб традицияләрен сеңдереп, үз кыйбласында үскән-үзгәргән, яңа заманга меңләгән аваз-аһәң белән килеп ирешкән кабатланмас, уникаль күренеш икәнлеген исбатлый алдык. Безнең горурланырлык әдәбиятыбыз бар. Бүгенге татар поэзиясен укыган башка халыклар гомумән тел шартлата ала – мон-

БЕЛЕШМӘ

Резеда Кадыйр кызы Ганиева – әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. 1932 елның 25 октябрендә (паспортта: 13 ноябрь) Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылында туган. Авыл мәктәбендә җидееллык белем алганнан соң, Казан педагогия училищесын тәмамлый. Беренче хезмәт еллары туган авылы белән бәйле: ул Кече Шырдан мәктәбендә өч ел дәвамында рус теле һәм әдәбияты укыта. 1952–1958 елларда Резеда Ганиева читтән торып Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, университетны кызыл диплом белән тәмамлый. 1958 елда Мәскәү дәүләт университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасына аспирантурага укырга керә. «Татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатында сатира» темасына кандидатлык диссертациясен яза. Докторлык диссертациясен Кол Гали иҗатына багышлый. 1962 елдан Казан дәүләт университетында укыта башлый, профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Студентларга 60 елдан артык гарәп, фарсы, төрки-татар әдәбиятлары тарихын укыта. Резеда Ганиева ике дистәгә якын фән кандидаты һәм докторант тәрбияләгән мөгаллим. Күпсанлы фәнни мәкаләләр, китап-монографияләр авторы. Резеда Ганиева шулай ук укыту программалры, энциклопедияләр төзегән галим дә.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

ТӨРКИ КАГАНАТ: ТАШКА УЕЛГАН ХӘБӘРЛӘР

Күлтәгин – төркиләр хакиме. VII-VIII гасырлар. М. В. Горелик реконструкциясе.

VI гасыр урталарына таба, һуннар дәүләтенең дәвамчысы буларак, Үзәк Азия далаларында сибелеп утырган дистәләрчә күчмә кабиләләр берләшмәсеннән торган яңа дәүләт – Төрки каганлыгы барлыкка килә. Борынгы Кытай елъязмаларында әлеге дәүләт һәм аның идарәчеләре турында күпсанлы хәбәрләр урнаштырылган. Шулай да төркиләрнең үзләре тарафыннан ташка уеп язылган «документлар» исә безнең өчен тагын да кыйммәтрәк, чөнки әлеге язмаларда кытай чыганакларында чагылыш тапмаган уникаль мәгълүматлар теркәлеп калган.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ӨСТӘ – ЗӘҢГӘР КҮК, АСТА – КӨРӘН ҖИР

Йоллыг-тәгин – тарих битләренә кереп калган беренче төрки елъязмачысы. Ул 732 һәм 735 елларда үзенең кан кардәшләре булган Билге каган һәм Күлтәгин каберлекләренә «мәңгелеккә», «киләчәк буыннарга гыйбрәт булсын» дип биек таш баганалар – стелалар утыртып куя һәм аларның өслегенә рун хәрефләре белән багышламалар чокып яза. Ахырдан, «мин, Йоллыг-тәгин, әйтергә теләгән сүзләремне мәңгелек ташка чокып яздым», – дип үзенең исемен дә мәңгеләштерә. Әлеге багышламаларны Йоллыг-тәгин Төрк иленең оешуы һәм аның әүвәлге хакимнәре турындагы мәгълүматлардан башлап җибәрә:

«Өстә – зәңгәр Күк, ә аста көрән Җир яратылганда алар арасында, җирдә, кеше кавеме барлыкка килде. Кеше угыллары өстеннән борынгы бабаларыбыз Бумын ка-

Фотолар автордан алынды

ган һәм Истәми каган хакимлек итә башладылар. Тәхеттә утырган чорда алар Төрк иле төзеделәр һәм төрк халкының Төрәсен (кануннарын) булдырдылар. Тирә-юньдәге (дүрт яктагы) халыкларны буйсындырдылар: башлының – башын идерделәр, тезлене (аяклыны) – тезләндерделәр. Көнчыгыш тарафка һәм көнбатыш якларына (басып алынган җирләргә) үзләренең халкын урнаштырдылар. Алар зирәк һәм акыллы каганнар иде, алар батыр йөрәкле каганнар иде!»

Димәк, Төрк иленең беренче хакиме, ягъни каганы (каган ∽ каһан ∽ кахан ∽ хан) Бумын исемле булган икән. ***Бумын каган*** – төркиләрнең атаклы Ашина нәселеннән чыккан шәхес. Ул әле 534 елда ук *ябгу* (бөек кенәз) титулына лаек була һәм үзенең зирәк акылы, курку белмәс кырыс табигате аркасында төрки кабиләләрнең юлбашчысына әверелә. Ул заманнарда төркиләр әле жужаньнар кулы астында яшәргә мәҗбүр ителгән булалар. 545 елда Бумын кытай императоры Вэнь-ди булышлыгы белән Анахуань җитәкчелегендәге жужань гаскәрләрен тар-мар итә һәм бәйсезлеккә ирешә. Анахуань җәберләүләренә каршы баш күтәргән 50 мең гаиләлек *теле* кабиләләре дә (сүз уңаеннан: болгарларның нәсел җебе шул борынгы кабиләләргә килеп тоташа) нәтиҗәдә Бумынга кушылалар. 551 елда ул үзен каган дип игълан итә һәм кытай императорының кызына өйләнә. Бумын үзенең Зәңгәр Күк – Тәңре тарафыннан җибәрелгән миссиясен тулысынча үти: Үзәк Азиянең сәяси картасында яңа дәүләт – Төрк Иле (Türk Eli) барлыкка килә.

552 елда Бумын каган гүр иясе була. Аның законлы варисы ***Кара каган*** озак идарә итә алмый, 553 елда көтмәгәндә үлеп китә.

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ ТӨРКИЛӘР ИЛЕ

Тәхеткә Бумын каганның икенче улы ***Муган каган*** (553–572) утыртыла. Ул нигездә хәзерге Монголия җирләрендә идарә итә, резиденциясендә Орхон тирәсендә, элеккеге һун патшасы ставкасы торган җирдә урнашкан була. Замандашлары калдырган язмаларга караганда, «каты күңелле, рәхимсез-шәфкатьсез, әмма олы акыллы хаким башлыча сугыш эше белән шөгыльләнә, дала халыклары аннан куркып торалар». Муган каган заманында Үзәк Азиядә һәм Көньяк Себердә төркиләрнең тулы хакимлеге урнаша. Жужаньнар хакимлеге бөтенләй юкка чыгарыла, көньяк-көнбатыш Маньчжуриядә яшәп ятучы монгол телле киданьнар, отуз-татарлар һәм дә Енисей тирәләрендә көн күрүче кыргызлар (хагаслар) буйсындырыла.

Бумынның кече туганы ***Истәми-ябгу*** (553–573) турында да бераз сөйләп үтәргә кирәктер. Әле Бумын заманнарында ук аның кулы астында ун төмәнлек, ягъни якынча 80–100 мең кешелек зур гаскәр була. Тиз арада ул Төрк иленең көнбатыш биләмәләренә – Җитесу, ягъни хәзерге Казахстанның көньяк җирләренә һәм төньяк-көнбатыштарак яткан биләмәләргә хуҗа булып ала. Истәми үзен хәтта каган дип игълан итә һәм кышкы резиденциясен Иссык Күл тирәсенә урнаштыра. 555 елда ул Урта Азиядә сугышлар алып бара, Арал диңгезенә кадәр барып җитә, ә инде өч елдан, 558 елда, Көньяк Урал, Түбән Идел һәм Каспий диңгезе буйлары, Төньяк Кавказны буйсындыра, Византия биләмәләренә килеп чыга.

563–567 елларда Урта Азиядә эфталитлар дәүләте дә тар-мар ителә. Эфталитлар Бөек ефәк юлын үз кулларына алган фарсылар (персиялеләр) белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыруга каршы килеп торганнар. Бөек ефәк юлы Кытайдан турыдан-туры Константинопольгә илтә. Истәми каган фарсылар белән килешү төзү максатыннан кызын Сасанилар (фарсылар) патшасы Хәсрәү Анушираванга кияүгә бирә һәм шул ук вакытта Византия белән сәүдә килешүе турында сөйләшүләр башлый. Һәм максатына ирешә дә. Башта Истәми каганнан Константинопольгә, аннан Византия императоры Юстиннан Истәми каганга илчеләр килә. Византия илчеләрен, ут белән чистарыну йоласын үтәгәннән соң, каган үзенең ставкасында алтын тәхеткә утырып каршы ала. Сөйләшүләр уңышлы тәмамлана.

Истәми каган үзен Муган каганнан – бердәм Төрки каганатының законлы хакименнән – шактый бәйсез тота. Муган каган моңа артык борчылмый, империя белән бер үзәктән торып идарә итүнең мөмкин түгеллеген ул яхшы аңлый. Истәми каганның исә буйсындырылган халыклар арасында абруе зур була, чөнки ул җирле хакимият эшенә артык тыгылмыйча, билгеле бер күләмдә салым җыю белән генә чикләнә. Илдә тынычлык хөкем сөрә.

Баш сөяге формасы буенча ясалган төрки образы. VIII гасыр. Когэль курганы. Тыва. М. М. Герасимов реконструкциясе.

Таспар каган, Бумын каганның улы, 572–582 елларда идарә итә. Ул бертуган абыйсы Муган каганның эчке һәм тышкы сәясәтен уңышлы рәвештә дәвам итә. Аның хакимлеге чорында Төньяк Кытай кенәзлекләре Төрк иленең вассалларына әвереләләр.

Шаболио (Шаболо) каган идарә иткән чорда, 581–587 елларда, Кытайның төньягындагы таркау кенәзлекләр Суй династиясе идарәчеләре тарафыннан берләштереләләр, империя тиз арада икътисадый яктан ныгый, хәрби яктан көчәя башлый. Шул ук вакытта Төрки каганлыгында кризис башлана, илнең көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләре белән идарә итүче каганнар арасында бертуктаусыз бәрелешләр булып тора. Хәтта бер үк ыруг, кабилә вәкилләре үзара җир өчен тарткалашалар, тәхет өчен көрәшәләр. Озакка сузылган корылыктан далада маллар кырыла, коточкыч ачлык башлана.

КАГАННАР ЧАПКАН ЯУЛАР

Шаболиодан соң дәүләт белән кыска гына вакытта (587–588) ***Чулоху каган*** идарә итә.

Истеми каганның улы ***Карачурин каган*** (575–603), заманында Урал якларына һәм Идел буена яу чапкан батыр, әтисе үлгәннән соң каганатның көнбатыш өлкәләрен мирас итеп ала, алай гына да түгел, көнчыгыш биләмәләргә дә күз сала башлый. Чулоху каган каганлыкта беренчелекне яуласа, Карачурин каган үзенең

PRESSA.RU

Илиг каган Бумын ат өстендә. Кытай осталарының бронза эше. VI гасыр. Реконструкция.

биләмәләренә мөстәкыйльлек даулый.

Карачурин Урта Азияне, Хәрәземне яулауда, эфталитлар белән сугышларда катнаша. Кытай һәм Иран белән Бөек ефәк юлын үз контроленә алу өчен сугыша. 587-588 еллар кышында Чулоху Карачуринга каршы яу чаба, әмма аның гаскәре тар-мар ителә, ә ул үзе һәлак була. Сугыш 593 елга кадәр дәвам итә һәм Карачурин белән Чулоху каганнан соң тәхет иясе булып калган Шаболионың улы ***Юн Йоллыг каган*** арасында солых килешүе белән тәмамлана. Шулай итеп, каганатның бердәмлеген саклап калалар. Әмма күпкә түгел. 603 елда, яшәвенә ярты гасырдан аз гына артык вакыт үткәч, Төрки каганаты ике өлешкә таркала.

Көнбатыш Төрки каганаты составында бишәр кабилә булган дулу һәм нушиби төркемнәрен берләштергән. ***Шәгуй каган*** (610–618) һәм ***Төн-ябгу*** (618–630) идарә иткән чорда Көнбатыш каганат икътисадый яктан нык алга китә. 627–628 елларда Төн-ябгу Византия императоры Ираклий ягыннан Сасаниларга каршы сугышларда катнаша һәм Иранның Кавказ арты җирләренә үтеп керә. Сугыш Дербент һәм Тбилиси калаларын алу һәм зур байлыклар кулга төшерү белән тәмамлана. Әлеге уңышларда Төн-ябгуның керткән өлешен танып, Византия императоры аның башына кыйммәтле таҗ кигертеп куя.

Төн-ябгу үзенә буйсынган Урта Азия кенәзләренең мөстәкыйльлеген нык кыса, алар өстеннән күзәтү бигрәк тә салымнар җыйган чорда көчәя. Әмма замандашлары аны рәхимсез, комсыз, үзен деспотларча тотучы хаким буларак тасвирлыйлар. Аның бу сыйфатлары, бигрәк тә салым җыйган чактагы гаделсезлекләр гади халык арасында ризасызлык тудыра, хәтта баш күтәрүләргә кадәр китереп җиткерә. Аны заговор оештырып юк итәләр. Дулу һәм нушиби төркемнәре арасында тәхет өчен көрәш башлана. Озакка сузылган тарткалышлардан соң нушибилар төркеме 634 елда тәхеткә ***Ышбар Илтәриш каганны*** утыртып куялар. Ә 638 елда дулу кабиләләре үзләреннән тагын бер каган сайлап куялар. Ике каган арасында чын сугыш башланып китә. Һәм ул 657 елда Көнбатыш Төрки каганатының таркалуы белән тәмамлана.

Көнчыгыш Төрк каганаты ***Шиби каган*** (609–619) идарә иткән чорда күтәрелеп китә. Башында Суй династиясе торган Кытай, киресенчә, авыр кризис кичерә. Тәхет өчен барган көрәштә Шиби каган булышлык күрсәткән төркем җиңеп чыга – хакимияткә Тан династиясе килә.

Әмма Шибиның кече туганы ***Ил каган*** чорында каганатның хәле яңадан авырлаша. Аның сәбәбе ачык: ул идарә иткән 619–629 елларда Тан Кытаеның төньяк провинцияләренә 67 мәртәбә яу чабыла. Сугыш күп чыгымнар сорый, ә ул исә дәүләтнең зәгыйфьләнүенә китерә. Салымнарның күләме арта. Ачлык ел саен диярлек кабатланып тора. Халык Ил каганнан йөз чөерә, угыз кабиләләре баш күтәрә. Шул вазгыятьтән файдаланып, илгә Кытай армиясе бәреп керә. 630 елда Көнчыгыш Төрки каганаты яшәүдән туктый.

ТАШЛАРГА КҮЧКӘН ТАРИХ

Җиңелгән төркиләрне Кытай территориясенә күчереп утырталар. Сиксән елга сузылган авыр тормыш башлана. Әмма ирек өчен, дәүләтне яңадан торгызу өчен көрәш тукталмый. Баш күтәргән бер отрядның Котлыг исемле җитәкчесе Иньшан тауларына китеп яшеренә, әкренләп аңа тирә-юньдәге һәм тагын да ераграк төбәкләрдән авыл халкы килеп кушыла. Кытай императоры Ашидә ыруыннан чыккан һәм империя башкаласында төпле белем алган Юаньчжен исемле бер батыр егетне, кулына зур гына отряд тапшырып, баш күтәргән халыкка каршы җибәрә, әмма ул, фетнәчеләрнең гадел максатларын аңлап, уйлап та тормыйча, Котлыг отрядына килеп кушыла. Котлыг үзен, исемен үзгәртеп, ***Илтәриш каган*** (682–691) дип игълан итә, аның дусты Юаньчжен исә, ***Тоньюкук*** исемен алып, фетнәчеләр армиясенең башлыгы булып китә. Тоньюкук армиясе 682 һәм 686 елларда Кытай армиясе белән бәрелешә һәм икесендә дә зур җиңүгә ирешә. Нәтиҗәдә Көнчыгыш Төрки каганаты (аны Икенче Төрки каганаты дип тә йөртәләр) яңадан торгызыла.

Затлы Ашина ыруыннан чыккан төркләр Илтәриш каган җитәкчелегендә, Кытайдан китеп, кире үзләренең туган төбәкләренә, хәзерге Монголия җирләренә, кайтып төпләнәләр. Илтәриш каганга көньяк Себердә һәм көньяк-көнбатыш Маньчжуриядә яшәүче халыклар да буйсына.

Илтәришнең кече туганы ***Капыган каган*** идарә иткән чорда (691–716 еллар) дәүләтнең чикләре ахырынча билгеләнә, кул астындагы биләмәләр белән идарә итү системасы формалаша. Икенче Төрки каганатының хәрби-сәяси һәм дипломатик активлыгы да шушы чорга туры килә. 693–706 елларда гына да Капыган каган Төньяк Кытайга алты мәртәбә зур яу оештыра. Кытай императоры төркләргә җитди каршылык күрсәтә алмый, шунлыктан аларга салым түләп торырга мәҗбүр була. Тиздән Капыган каган Керулен белән Байкал арасында яшәп ятучы монгол телле киданьнарны, байырку һәм токуз-угыз кабиләләрен үзенә куша, 709–710 елларда чикләр һәм Енисей кыргызлары тар-мар ителә. 711 елда төркиләр Алтай аша Джунгариягә бәреп керәләр, түргәшләрне буйсындыралар. Аннан соң Урта Азиягә чират җитә. Тоньюкук һәм Илтәриш каганның ике улы (киләчәктә Билгә каган һәм Күлтәгин исеме астында танылачак шәхесләр) җитәкләгән гаскәр Согдка килеп җитәләр, гарәп армиясе белән сугышка керәләр. Әмма Сәмәрканд тирәсендә алар гарәпләр тарафыннан җиңеләләр.

Шуннан соңгы елларны Төрки каганаты өчен уңышлы еллар дип әйтеп булмый. Моннан элегрәк буйсындырылган токузугызлар баш күтәрә, хәтта каган даирәсенә якын ыруглар да, яклау эзләп, Кытай императорына мөрәҗәгать итәләр. Байырку кабиләләре башлаган фетнәне бастырган чакта Капыган каганны үтереп ташлыйлар.

Әле үзе исән вакытта ук Капыган каган тәхетне, кануни тәртипләргә каршы килеп, үзенең улына вәгъдә итеп калдырган була. Сугышчылары арасында зур популярлык казанып өлгергән Күлтәгин, Илтәриш каганның кече улы, тәхеткә закон нигезендә үзенең өлкән туганы Могилянны утырта (ул күбрәк ***Билге каган*** исеме белән билгеле; 716–734 елларда идарә итә). Ил белән асылда ул һәм Күлтәгин белән инде 70 яшен тутырган Тоньюкук составындагы өчлек – триумвират идарә итә. Кытай хроникаларыннан һәм кабер таш язмаларыннан күренгәчә, Билге каган күршеләре уйгыр, татар, карлук, кидань кабиләләре белән сугышып тора, 718, 721–722 елларда Тан (Кытай) империясе гаскәрләрен җиңүгә ирешә, алар белән солых килешүе төзи.

731 елда Күлтәгин үлә, Билге каганны 734 елда үзен чолгап алган якыннарыннан берсе агулап үтерә. Тәхеткә Күлтәгиннең бертуганының улы Йоллыг-тәгин утыра (***Иҗан каган***, 734–739), аны яшүсмер ***Тәңре каган*** алмаштыра (739–741). Икесе дә сарай чуалышлары вакытында һәлак була. Шуннан соң илдә тынычлык урнаша алмый инде. Яңадан элеккеге вассалары угызлар, басмыллар, карлуклар баш күтәрәләр. Нәтиҗәдә данлыклы Ашина ыругы соңгы кешесенә кадәр кырылып бетә. Төрки каганаты яшәүдән туктый, ә халкы исә яңа барлыкка килгән Уйгыр һәм Караханилар каганатына кушыла.

БЕЗ – АЛАРНЫҢ ВАРИСЛАРЫ

Менә сез, хөрмәтле укучылар, тарихи чыганаклар мөмкинлек биргәнчә, Төрки каганатының мәшһүр идарәчеләре – каганнары белән танышып чыктыгыз. Чыганакларда, кызганычка каршы, каганнарның шәхси сыйфатлары, идарә итү ысуллары һәм үзенчәлекләре турында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. Аның каравы елъязмачылар каганнар алып барган сугышлар турында күп язалар. Беренче карашка, Төрки дәүләтләренең тарихы, әйтерсең, бары тик басып алу сугышларыннан гына гыйбарәт. Бу, әлбәттә, алай түгел. Төрки каганаты – безнең Россия территориясендә оешкан һәм ике гасыр буена күп кенә төрки һәм башка халыкларны берләштереп тоткан беренче империя. Әйе, төркиләр – башлыча күчмә халык, әмма, шәһәр-ауллар корып, утрак тормышта яшәгәннәре дә шактый гына булган. Миңа калса, безнең өчен, хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен, аларның, борынгы төркиләрнең, югары үскән мәдәнияте, беренче чиратта, рун графикасына нигезләнгән язмачылыгы, монотеизм (бер аллалык) дәрәҗәсенә җитә язган дини ышанулары (Тәңречелек) булуын белү-белдертү мөһимрәк. Кулымнан килсә, мин төрки бабаларыбызның шул казанышларын һәрдаим искә төшереп тору өчен Казаныбызның Меңьеллык паркында Билге каган һәм Тоньюкук ташъязмаларына охшатыбрак, бер монументаль һәйкәл торгызып куяр идем.

1. Борынгы төрки сыны. Монголия. С. Г. Кляшторный фотосы.

2. Күлтәгин хөрмәтенә һәйкәл. Монголия. С. Г. Кляшторный фотосы.

3. Борынгы төрки сыны. V-VIII гасыр. Көнчыгыш Төркестан.

1


2


3

PRESSA.RU

ТЫНЛЫККА СУСАУ, ЯКИ ЧЫНБАРЛЫКНЫҢ ҖАЙСЫЗ КЕШЕЛӘРЕ



Бу юлы бераз гына сәер китапларга тукталырга булдык. Һәм сәер, бездә бик үк билгеле булмаган язучыларга. Аларның әсәрләрендә сүз система колы булырга теләмичә, аның кагыйдәләре, кануннары белән килешмичә, үз дөньяларына китеп яшәүче затлар турында бара. Бу язучылар безгә тормышның өстән агып яткан агымнарын түгел, ә тирәнрәк чоңгылларын ачып күрсәтә. Чынбарлыкның җайсыз кешеләрен. Аларның чоңгылларында без кайчак үзебездән дә яшереп яшәгән чын үзебезне таба алабыз.

АРЪЯККА БЕР КАРАШ, ЯКИ КИТАПЛАР БЕЗНЕ НИК ТАШЛАП КИТӘ?

Хуан Хосе Мильяс, «В алфавитном порядке», «У тебя иное имя»

Автор:
Луиза Янсуар

Хуан Хосе Мильяс турында рус телендә мәгълүмат табу шактый читен. Русчага да аның ике генә китабы тәрҗемә ителде, алар мәртәбәле «Иностранка» нәшриятында басылып чыкты, ә менә Испаниядә ул шактый киң танылган язучы һәм журналист. Берничә басмада колумнист, Гуманитар фәннәр Югары мәктәбендә мөгаллим. Аның «Эль Паис» газетасында чыга торган җомга колонкаларын көтеп алалар, яратып укыйлар. Журналистика белән проза чигендә торучы яңа жанрга нигез салучы булып исәпләнә Мильяс. Ул аны «шәхси жанрым» дип атый, жанр таләпләре буенча, фантазияңне эшкә җигеп, көндәлек хәлләрне тәнкыйди бәяләргә мөмкин, дигән караштa тора. Ә әдәбиятка ничек килүе турында сорасалар, җавабы тагын да серлерәк: «Кайчандыр, балачакта, Испан энциклопедиясендәге «үлем» төшенчәсе турындагы статьяга юлыккан идем, мине әдәбиятка әнә шул статья китерде».

Әлеге сүзләр Мильяс иҗатына чын мәгънәсендә ачкыч булып тора. Роман герое, Хулио (аны Мильяснык альтер-эгосы дип шикләнмичә атый алабыз), югары температура белән авырып ята. Әсәр әлеге яшүсмернең безгә эчендәге тәэсирләрен сурәтләү белән башланып китә. Язучы безне, әйтерсең, бик борынгы чагыбызга – әле мәгарәләрдән джунглилар чатырманына килеп чыккан мәлебезгә кайтара. Мильяс фабулага әллә ни игътибар бирми, аның төп игътибары – тәэсирләр аша логикага китереп чыгару, эчке катаклизмнарны иң төбенә төшеп анализлаганнан

соң, хәрабәләрдән чын тормыш картинасының бөтенлеген кайтару. Билгеле бер моментта син геройның бизгәге эчендә адашып йөрисең шикелле тоела башлый. Әлеге авыру тудырган фантасмогорияләрдән чәчләр үрә тора. Юк, алар без ияләшкән хоррор жанрына тартым булганлыктан, шкафлардан скелетлар очып чыгып, паласларга кан таплары җәелүдән түгел. Мондагы шом, куркыныч башка – ул тышкы тәртип артында яшеренеп яткан, богаулап куелган хисләр өермәсенең бәргәләнүе. Ул бер-берсенә якын булган кешеләрнең – бер гаилә эчендә – сүзләр, кул көче кулланып түгел, ә ярымтоннар, ярымкарашлар, эндәшмәүләр аша бер-берсен җәберләве. Кеше кешегә салган сукмакларның ни дәрәҗәдә иллюзор булуын күрсәтә Мильяс. Әниегезне беләсезме сез? Ә балагызны? Ирегезне? Әтиегезне? Беләм, дип авыз тутырып әйтергә кыясызмы? Юк, дип ачыргаланып кычкырасы килә, Хулионың сүзләрдән мәхрүм калган параллель дөньясына тирәнрәк күмелгән саен. Уку барышында син тулаем роман героеның күзәнәкләренә сеңеп бетәсең.

«Время от времени над нами пролетали книги – поодиночке или целой стайкой, – и мы весело смотрели им вслед... Я торопливо шагал домой, но, проходя мимо газетного киоска заметил на тротуаре огромную тень – ее отбрасывала газета, тоже раскинувшая крыльяи пустившаяся в полет. Киоскер был в отчаянии: журналы, подергавшись немного на своих прищепках, высвобождались и улетали. Газеты, плавно и величаво взмахивавшие огромными волнообразными крыльями, напоминали орлов, а журналы – соколов...

Энциклопедия и прочие отцовские книги пока стояли на своих местах, но, если прислушаться, можно было уловить негромкий беспокойный рокот, так что казалось, будто там, в глубине этой безжизненной, неодушевленной материи, совершается какая-то скрытая от глаз таинственная работа. Между тем на экране министр культуры призывал граждан не пытаться удерживать книги на полках, поскольку уже наблюдались случаи, когда в подобных ситуациях книги вели себя буйно».

Китаплар артыннан кешелек дөньясы берәм-берәм сүзләрдән дә мәхрүм кала бара. Ә югалган сүзләрне искә төшерә алмагач, кешеләр, кыенсыныпмы шунда, аларны хәтерләтеп торучы предметларны да чыгарып ташлый башлый. Иң беренче булып өстәл сүзе юкка чыга, һәм кешеләр, өстәлдән ваз кичеп, идәнгә утырып ашарга керешә. «Хәлләр болайга барса, без тиздән хайван хәленә калачакбыз», – дип пошаманга төшә Хулионың әтисе. Һәм ул хаклы булып чыга. Күз иярмәс тизлек белән кешеләр мең еллар буена тупланган культураны югалта, тиздән алар, бер кучкә җыелып, учаклар ягып, кыргый рәвештә ризык бүлешергә керешә. Хулио, бу хәлләрне ярымтөш пәрдәсе аша чынбарлыкның «аргы ягына» чыгып күзәтеп тора. Һәм ул берзаман ваемлап ала: дөнья чынлап та ике яклы. Ул бер чынбарлыктан икенчесенә генә күчеп йөреп калмый, ә әтисенең иң кадерле, күз карасыдай саклый торган бердәнбер исән калган китабы – энциклопедиягә дә сәяхәтләр ясый. Әйтик, якты дөньяга килә алмыйча калган сеңлесен эзләп, «аборт»лар мәкаләсе эчендә адашып йөри. Озак еллар авырып яткан, әтисе белән мөнәсәбәтләре начар булган бабасы дөнья куйгач, аны җирләгәннәрен күрер өчен урынында яткан килеш «зират»лар дигән сәхифәгә күчә. Тора-бара әлеге энциклопедия аны кыргыйлашып барган өлкәннәр дөньясыннан саклаучы да, әле үзе аңлап та өлгермәгән олы тормышка әйдәп баручы да булып әверелә.

Мильясның герое үсеп җитеп, балигъ булгач та, тормышның чынбарлыктагысына параллель «арьяктагысы» юкка чыкмый, ул Хулионың көндәлек тормышын биләп, яшерен генә яши бирә. Без аны офисларда, кафеларда, урамнарда күрәбез, әмма янәшәдән атлап узган бу кешенең эчендәге чатырманнарны гына шәйләмибез. Хәер, без үзебез дә шундый түгелмени? «У тебя иное имя» исемле икенче китабында Мильяс ул чатырманнарның тагын да эченәрәк чакыра. Мондагы Хулио героенда һәммәбез дә үзен таный ала – тормышның иң четерекле, кризислы мизгелләрендә безнең әнә шул «арьягыбыз» калкып чыга һәм еш кына чынбарлыктагы тәртипкә салынган дөньябыз белән идарә итә башлый.

КОРЕЯНЫҢ КИТАП АРТ-ХАУСЫ, ЯКИ ЧЫН АСЫЛЫБЫЗ КАЙДА?

Хан Ган, «Вегетарианка»

Хан Ган исеме 2017 елда рейтинглардан төшмәде. 2016 елда, Халыкара Букерны алганнан соң, язучы күз ачып йомган арада гаять популяр һәм укыла торган авторга әверелде. Букер тарихта беренче тапкыр Корея язучысына бирелгәч, Хан Ган шәхесенә булган кызыксыну бермә-бер артты. Үзе тирәсендәге шау-шуны өнәмәүче Хан Ган тыйнак кына шәхси тормышына кагылмауларын үтенә, һәм язучы белән гадәти кеше арасында тигезлек билгесе куймаска өнди. Инглиз укучысына Хан Ган шактыйдан таныш. Букер уңае белән мәртәбәле премиягә ия булган «Вегетарианка» романын, ниһаять, рус укучысына да ирештерделәр.

Хан Ган Кореянең Кванджу шәһәрендә күренекле язучы Хун Сунвонь гаиләсендә туып үсә, дәрәҗәле Сеул университетында укый һәм үзе дә язучылык һөнәрен сайлый. Ике абыйсы шулай ук Кореядә әйбәт билгеле язучылар. Хан Ганның «Любовь каторжника», «Монгольский след», «Твои холодные руки» романнары кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне чагылдыруга багышланган, авторны заманча яссылык кына түгел, ә тарихи үткән һәм аның бүгенге көнгә тәэсире дә гаять кызыксындыра. Әдәбияттан тыш, Хан Ган музыка һәм рәсем сәнгате белән мавыга, ул музыкаль диск авторы буларак та мәгълүм.

«Вегетарианка» турындагы фикерләр бик тә каршылыклы. Күпләр аны ачыктан-ачык кабул итми. «Корея дөньясы минем өчен бөтен ямен югалтты» диючеләр бар. Сабыр, тыенкы холыклы Хан Ган үзе мондый каршылыклы мөнәсәбәткә әзер булмавын әйтсә дә, әсәре аша кемнәрнедер сискәндерә, проблеманың күзенә туры карата, кешеләрнең үзаңына тәэсир итә алуына сөенүен белдерә. Авырту, әрнү, яшерен газаплар турында шактый беләм, дип исәпли

PRESSA.RU



тотулар аша тәмам хәлсезләнгән Ёнхенең аң төпкеленә апасы бераз үтеп керә. Ул аның ит ашаудан гына түгел, гомумән, ашаудан баш тартып, үсемлек булып әверелергә теләвен аңлагандай була. Кешелек кыйммәтләреннән ваз кичеп, системаны җимереп, үз дөньясына киткән, әти-әниләре тарафыннан да кабул ителми башлаган сеңлесенә, ниһаять, бөтенләе белән беренче асылына кайтырга ярдәм итә: ул аны, табиблардан яшереп, урманга җитәкләп алып китә. Шулчак аның аңында беренче тапкыр «ә бәлки, минем сеңлем җуләр түгелдер, бәлки барысын да үтә нечкә тоючыларга чыннан да бу тормыш шаукымыннан ераккарак китәргә кирәктер» дигән уй кереп урнаша.

«Вдруг пришло ощущение, что она не жила на этом свете, и ей стало страшно. Да, на самом деле. Она не жила. Лишь терпела, сколько себя помнит, с самого детства. Она считала себя добрым человеком и жила, веря в свою доброту, не причиняя никому вреда. Искренняя, довольно успешная в своем деле, она надеялась всегда оставаться такой. Однако случилось странное. Перед этим развалившимися строениями и высокой травой она почувствовала себя просто ребенком, не более того, просто ребенком, никогда не жившим на этом свете».

үзен Хан Ган. Ул күп еллар дәвамында мигреньнан интегә, туганын югалтканнан соң бу хакта тулы бер әсәр яза, китабының үзенә күрә терапия булуын ассызыклый. Гомумән, язу эшенең асылы турындагы фикере искиткеч дәрәҗәдә актуаль аның:

«Раньше я писала лихорадочно, как безумная. Мне кажется, я просто писала… чтобы выжить. Может быть, и сейчас я продолжаю писать ради этого. Я думаю, что писать – это как зажечь спичку, а потом смотреть, как она горит, пока пламя не потухнет. Возможно, все, что может сделать литература, – это задать вопросы о человеке и жизни в тот момент, пока мы смотрим на пламя. В некотором смысле я как будто толкаю свою жизнь вперед, переходя от одного романа к другому».

«Вегетарианка» романына гаепләүләр белән ташланганчы, аның язылу тарихына, дөресрәге, аңа илтүче яшерен җепләргә игътибар итүләрен дә теләр идем романны укырга алынучыларның. Хан Ганга 10 яшь булганда, ягъни 1980 елда әти-әниләре ашыгыч рәвештә Сеулга күченә. Бу хәл «ит чабучы» кушаматлы генерал Чон Ду Хван илдә түнтәрелеш ясап, хәрби режим игълан иткәннән соң була. Кванджудагы студент демонстрацияләре кан кою белән төгәлләнә, «гади кешеләр, әйтерсең, иттарткыч аша чыгарылды» дип искә ала бу хәлләргә шаһит булучылар. Хан Ган үзе бу вакыйгага артык тукталмый, әсәренә илһам бирүче чыганак буларак Корея шагыйре Ли Сан шигырен китерә. Кореяне Япония үз колониясенә әверелдергән чордагы үтереш-суешлар дәверендә яшәгән әлеге шагыйрь «кешеләргә килгән җәбер-золымны күрмәс өчен үсемлек булып әверелергә генә кала» дип яза. Бу шигырьнең төп лейтмотивы «Вегетарианка»ның буеннан-буена сузыла.

Әсәрдә бер генә тапкыр да төп героиня үзенең вегетарианлыкка күчүе турында сүз алып бармый, бу терминны кулланмый, гомумән, ит ашаудан баш тарткан көннән башлап, ул сөйләшүдән, нинди дә булса физик контактлардан да баш тарта. Шунда гына ире аңарга чын-чынлап игътибарын юнәлтә: моңарчы мин хатынымның нинди дә булса күзгә ташланган үзенчәлеге бар, дип санамый идем, әмма ул ит ашамый башлагач, мин аңарга игътибарымны юнәлттем, дип башланып китә әсәр икенче пландагы геройның сүзләре белән. Һәм шулай – азаккача. Хан Ган безне героинясы Ёнхенең уйларын, кичерешләрен белү шикелле бүләк белән сөендерми, аның эчке агымнарын әйләнә-тирәдәгеләрнең Ёнхе хакында чыгарган нәтиҗәләренә, белдергән фикерләренә генә төреп бирә. Һәм, аңлыйбыз, аларның берсе дә чын дөреслеккә туры килми. «Аръяк», чатырман бу очракта аръяк һәм чатырман булып кала да бирә. Ахыр чиктә, хастаханә, психиатрия клиникасы, биктә

Әсәр ябышкак тынчу клаустрофобик уемтысы эчендә әйләндерә-әйләндерә дә, кинәт ничек башланса, шулай тәмамланып та куя. Ул калдырган авыр тойгыдан арына алмый йөрисең. Эчке катламнарында ваемлау процессы әле дәвам итә. Әнә шуның белән көчле Хан Ган – ул структурасы буенча әкияткә, риваятькә тартым яңа платформа тудыра да, сиңа күзәтүче ролен бирә. Әмма син, әсәр буена «ни өчен шулай соң?!» дигән соравыңа җавап таба алмаганлыктан, күзәтүче генә булып кала алмыйсың, сиңа тирәнгәрәк үтәргә кирәк була башлый – героиняның логикасына. Нәрсә тота кешене бу гаиләдә, бу җәмгыятьтә, җир шарында? Кешене нәрсә кеше итә, ә нәрсә кеше булудан туктата ала? Дөресрәге, нәрсә кешеләр арасындагы кеше булудан аек акыл белән баш тартуга китерә ала?! Бу сорауга җавапны киләсе әсәрдә дә эзлибез.

ТЫНЛЫККА СУСАУ, ЯКИ 27 ЕЛГА СУЗЫЛГАН ЯЛГЫЗЛЫК

Майкл Финкель, «Я ем тишину ложками»

Алдагыларыннан аермалы буларак, бу романдагы герой инде – реаль кеше. Һәм аның тарихы да реаль тарих. Кристофер Найт 20 яшендә өйдән китә һәм урманда яши башлый. Моның өчен күзгә ташланып торган әллә нинди сәбәпләр дә булмый, гаиләләре, ярлы булса да, үз көнен күреп, тыныч кына көн күрә. Балаларга белем дә бирәләр. Найтны кулга алганнан соң, аның балачак травмасы бардыр, дип, төрле психологик тайпылышлар эзлиләр. Әмма юк, ул гадәти бала һәм үсмер була. Гаиләдә аны кыйнамыйлар да, җәберләмиләр дә. Әмма билгеле бер мизгелдә Найт бу куллланучылык җәмгыятендәге кануннардан арый һәм тынлыкны, системадан тыш яшәүне сайлый.

«Она хочет понять, зачем было уходить жить в лес, но Найт говорит, что не может назвать определенных причин. Она указывает на заживающие шрамы у него на запястье.

– Как вы лечились?

– Я не принимал никаких лекарств и никогда не ходил к врачу. С возрастом порезы и шрамы заживают медленнее, но мне повезло – у меня не было серьезных травм.

– Вам случалось заболеть?

– Нет. Чтобы заболеть, нужно контактировать с другими людьми.

– Когда в последний раз вы контактировали с другим человеком?

После ухода в лес он ни разу ни с кем не имел физического контакта. Но однажды, в 1990-х, он встретил туриста, идущего по лесу.

– Что вы ему сказали?

– Я сказал ему «Привет!»

Кроме этого случая он не сталкивался и не говорил с другим человеком на протяжении двадцати семи лет».

27 ел эчендә ул үзенең урмандагы тормышын җайга сала. Яшерен бер ышык урында лагерь булдыра, шул еллар эчендә бер генә тапкыр да учак якмый (ут яктысын күреп, кешеләр аны эзләп табарга мөмкин дип шикләнә). Әмма цивилизациядән баш тартып яшәүнең бәрабәре нәрсә соң? Беренче арада ул урмандагы ризык-нигъмәтләр белән туена, әмма учак ягудан баш тартканнан соң, аулап алган җәнлекләрне хәстәрләп ашау мөмкинлеге булмагач, ризыкны башка юл белән табарга кирәк булуына төшенә. Тирә-яктагы җәйге йортлардан азык-төлек юнәтә башлый. Найт теләсә нинди катлаулылыктагы йозакларны ачып керергә өйрәнә. Үзенә җитәрлек кенә ризык һәм кирәк-яраклар алып чыга, ничек ачып керсә, шулай бикләп тә чыгып китә бу өйләрне. Битлз, классик музыка яздырылган пластинкалар белән китаплар да урлый. «Мин урмандагы тормышымда кешеләрнең булуын теләмәсәм дә, кешелекнең иң шәп затлары тудырган сәнгатьне үзләштерергә теләдем», – ди үзе Найт.

Артыннан эз калдырмый, берәүнең дә күзенә чалынмый торган Дәрвиш барлыгын тирә-юньдәгеләр яхшы белә. Аңа башта ачулары кабара, кемнәрдер, киресенчә, Дәрвишнең яшәү рәвешен романтик дип таба, аны яңа заман каһарманы итеп күрә. Найт Мэн штатының легендасына әверелә. Тотылгач һәм урлашулар өчен җинаятьтә гаепләнеп, төрмәгә утыргач, ул үзенең тарихын бердәнбер журналистка сөйли – бу журналист Майкл Финкель була.

Үзе дә ара-тирә урмандагы йортына китеп, атна-ун көн ялгызы яшәп алырга ярата торган Финкель Найтка «мин сезне аңлыйм шикелле» дип хат яза, хатка үзенең берничә мәкаләсен дә беркетә. Һәм, ни гаҗәп, кулга алынганнан соң, ике-өч җөмләдән артыгын сөйләшмәгән Найт аның хатына җавап бирә һәм очрашырга да ризалаша. Финкель аның янына төрмәгә килеп йөри башлый. Алар арасында сәер әңгәмә башлана һәм тора-бара ул үзенә күрә дуслыкка да әверелә. «Минем беркайчан да кызыксыну объекты буласым килмәде, һәм хәзер дә килми, мин үземне аңламауларын күрәм, әмма, бәлки, сез хаклыдыр, аңлатырга кирәктер кешеләргә ник минем болай яшәгәнлегемне», – ди аңа бер очрашу вакытында Найт. Һәм үзе үлгәннән соң аның турында китап язуына каршы килми.

Финкель «Я ем тишину ложками» китабын иртәрәк яза. Ул бу басманы әзерләгәндә, система Найтны инде төрмәдән чыгара һәм ул, урманыннан баш тартырга мәҗбүр була. Төрмәдә чакта әнисеннән оялып, аның белән очрашудан баш тарта Найт. Ул мине урлашырга өйрәтеп үстермәде, ничек итеп аның күзенә карыйм, ди. Ләкин кайткач, аның янында, үзенең балачагы, үсмер еллары узган бүлмәдә яшәргә кала, туганына машиналар ремонтларга булыша башлый. «Иллегә җиткән ир болай яшәргә тиеш түгел, аңа урманнан кечкенә генә бер участок алып биреп буладыр бит», – дип, органнарга да, опека хезмәтенә дә мөрәҗәгать итеп карый Финкель. Әмма системаның җавабы каты: урман Дәрвише социальләшергә, яңадан кешеләр арасына, җәмгыятькә әйләнеп кайтырга тиеш.

Инде бар да яхшы, дип җиңел суларга гына калганда, Финкельга сәер дустыннан хат килеп төшә. Аңарчы бер очрашуда күзләре яшь белән томаланган һәм читлектәге җәнлекне хәтерләткән Найт Финкельга төшен сөйли: ул төштә Дәрвиш Урман Хатынын күрә, кайчандыр коточкыч салкын бер кышта әлеге Хатын аның янында утырып тора, Дәрвишне алырга килүен әйтә, әмма Найт аның белән китүдән баш тарта. «Хәзер аңлыйм: ул Үлем булган, – ди Найт дустына. – Хәзер килсә, мин аның белән кире урман эченә китәр идем...» Ә хатта ул Финкельгә беркайчан да башка хәлен белергә килмәскә куша һәм ул вакытын гаиләсенә бүләк итәргә өнди. Найтның лагерен тулаем чистарталар һәм аңардан эз дә калмый. Әйтерсең, ул беркайчан булмаган да...

«Временами я спрашиваю себя: а что если? Что, если бы сержант Хьюз не оказался столь проворен, и Найта бы не поймали? Крис говорил мне, что остался бы в лесу навсегда. Он мечтал умереть в своей палатке, там, где был по-настоящему счастлив. Его бы охватили ветки, сквозь него проросли бы корни... Он не собирался оставлять после себя ни единой записи, ни фото, ни мысли. Никто бы не узнал о его опыте. Крис просто исчез бы, и никто на этой бешеной планете не заметил бы этого. Даже легкая рябь не пробежала бы в его честь по поверхности Северного пруда. Это была бы абсолютно безупречно прожитая жизнь».

PRESSA.RU

Илсөяр Иксанова 1966 елның 7 февралендә Татарстан АССРның Лаеш районы Татар Сараланы авылында туган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укый. Университетны тәмамлагач, «Татарстан китап нәшрияты»нда – корректор, «Яшь ленинчы», «Шәһри Казан», «Салават күпере» басмаларында – хезмәткәр, «Ялкын» журналында – бүлек мөхәррире, «Сөембикә» журналында бүлек мөхәррире булып эшли. Хәзерге көндә – «Түгәрәк уен» журналының баш мөхәррире. Илсөяр Иксанова күпсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы. Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

Илсөяр Иксанова

БОЛЫТЛАР АРТЫНДА КОЯШ БАР

хикәя

– Әтием, мин сине бик-бик яратам!.. Әйдә, бер-ике-өч...

Телефон төймәсенә кайсы беренче баскандыр, күз алдында кызының елмаюы гына эленеп калды. Саубуллашканда кызы Әминә аңа һәрвакыт шулай ди: мин сине бик-бик яратам! Бу сүздән җанда кояш кабына. Тик Әнвәр үзе яратам сүзен хисе күңеленнән ташып торганда да җиңел генә әйтә алмый. Ул хис ничектер сүзсез генә аңлашылырга тиеш кебек. Ә хәзерге яшьләр башка: алар яратуларын да, яратмауларын да ярып салалар. Бәлки шулай дөрестәдер, ап-ачык. Әллә нәкъ менә шушы гап-гади сүзләрне вакытында, урынында әйтә белмәү аркасында тормышы шундый чуалчык булып чыктымы соң Әнвәрнең?

Кинәт тиктомалдан күңелне тирән моңсулык сарып алды. Моңсулык кына түгел, әйтеп бетерә алмаслык бушлык биләде җанны. Гүя дөнья бөтенләй башка үлчәмгә, башка яссылыкка күчте.

Бу халәт Әнвәргә таныш. Әмма бүген туган йортының капкасын ачып кергәндә ул һич кенә дә мондый халәткә төшәр төсле түгел иде. Яшел чирәмле киң ишегалды аны елмаеп каршы алды. Ишегалдының һәр почмагында кояш уйный, сап-сары болдыр кырыена тезелеп куелган аяк киемнәре: яшел, зәңгәр төстәге җәйге резин башмаклар, кызыл эчле ялтыравык галошлар да хуҗа кайтканга сөенеп елмаешып торалар төсле. «Апа кайтып киткән икән» дип уйлап алды ул, яхшылап юылган болдыр идәнен, тәртип белән тезелгән аяк киемнәрен күздән кичереп.

Әти-әнидән соң бушап калган йортны алар – ике туган – хәл кадәренчә яшәтергә, туган нигездә тормышны сүндермәскә тырышалар иде. Көз ахырында гына өйне ябып торалар да язга чыгуга кайтып ачалар. Үзара килешенгән канун: кем кайтса да, яшелчә-чәчәкләргә су сибеп, киткәндә үзе артыннан өйне җыештырып китә. Бигрәк тә ачык җирдә тычкан-фәлән иямләшерлек ризык калдырырга ярамый. Хуҗалар кайтканда сораныл йөрүче песиләр күп булса да, йорт буш калгач, ул мырауларның бу тирәдә эзләре булмый, ахры. Менә әле дә, каян сизә диген, Әнвәрнең артыннан ук Тиенкәй килеп керде. Яз башында өйне ачкач та килеп ияләшкән яшь песигә озын, йөнтәс койрыгына һәм песиләргә хас булмаганча сикергәләп атлавына карап, апасы Тиенкәй дип исем биргән иде. «Үзең син – тиенкәй, бертуктаусыз тормыш тәгәрмәчен әйләндерәсең». Апасына карата күңелендә туган җылы хисләрен Әнвәр, билгеле, сүзгә күчерә алмады. Ә Тиенкәй бигрәк үз итте аларны. Кайтып кергәннәрен сагалап кына тора. Аның көтеп торганын белеп, хуҗалар да кучтәнәчсез кайтмый. Әнвәр бу юлы да авылда көтеп торучысы барын онытмады, аэропорт буфетына кереп сосиска алып чыкты. Шуны чистартып, песи тәлинкәсенә салды. Тиенкәй иснәп кенә карады да... матур койрыгын болгап читкә китте. Өстәл астына кереп, Әнвәргә яшькелт күзләреннән үпкәсен сирпеп алды: син нәрсә, кешеләр генә ашый торган итсез сосиска ич бу, моның белән песи халкын алдыйм димә! Үз чиратында, Әнвәр дә: «Тамагың туктыр», – диде дә, юл сумкасын болдыр идәненә куеп, өйгә дә кереп тормастан, арткы капкадан бакчага чыкты.

Менә кайда ул рәхәтлек! Бакча шау чәчәктә: кашкарыйлар, дәлияләр, хризантемалар, петунияләр... Яз башыннан нәркисләр, лаләләр, ирислардан башлап, җәйгә кучкәндә пионнар, лилияләр, розалар, соңрак флокслар, инде менә көзгә чәчәкләр белән балкып торган бакча Әнвәргә апасының матур-бизәкле күңел дөньясы кебек тоела. Тик ул күңел дөньясын аңлаучы, санлаучы, сокланучы бармы соң?! Җизнәсе сүзгә дә, хискә дә саран, тормышның якасына ябышып дөнья көтә торган кеше булып чыкты. Апасы белән кара-каршы торып шәһәр читендә йорт җиткерделәр. Җизнәсе әйтмешли, хезмәт белән тәрбияләгән балалар, тәрбия яшеннән чыккач, тиз-тиз хезмәттән качтылар: кызлары интернет аша танышып, әти-әнинең ай-ваена карамастан, унсигезе тулуга казах егетенә кияүгә чыгып китте. Уллары армиягә киткән җиреннән Себер якларында төпләнде. Хезмәт тагын апасы белән җизнәсенең икесенә генә калды. Апасына күбрәк тә төшә. Чөнки җизнинең авылы шәһәрдән ерак, төп йортта энесе яши, анда елга бер генә кайтып киләләр. Ә хатынының нигезенә кайтып йөрүне җизни кеше кирәксенми; хатынын тыймый, үзе кайтмый. Апасы шулай итеп, ике арада бөтерелә. Ике арада, ике бакчада. Күрсәнә, помидорлары барысы сабагында кызарып-саргаеп утыралар. Картинага төшереп куярлык! «Бу бакчаны синең өчен үстерәм бит, алып кит инде помидор-кыярны булса да», – дип битәрли апасы Әнвәрне. И апа-апа, кайчан гына үзеңне уйлап яшәргә өйрәнерсең икән! Хәер, бу яшьтә инде үзгәреп булмыйдыр шул.

Бакчадагы гөл-чәчәкләрдән иңгән яктылык өйгә дә ияреп керде. Өй эче дә кояшка күмелгән иде. Әнвәр беренче эш итеп тәрәзәләрне ачып җибәрде. Ачкан чакта чебен-черки кермәсен өчен тәрәзәләргә тарттырган челтәрләрләрнең кнопкалары кубып төшкәләде, шуларны рәтләп шактый әвәрә килде. Нәкъ әнисе исән вакыттагы төсле тәрәзә төбе саен балкып утырган яраннарга карап, тагын бер кат апасын уйлап куйды. Тәрәзә төбендә гөл үсмәгәч, өй ятим кебек, дип ел саен яздан көзгә кадәр гөлләр үстерә, аннан ул гөлләрне кайсын күршеләргә таратып, кайсын шәһәргә алып китеп мәш килә. Үзләре кайта алмый торганда, күрше апа да кереп су сибештерә. Әле дә гөл төпләре дымлы иде.

Кайтып җиттем, дип хәбәр бирергә кирәктер инде дигән уй белән апасының номерын җыйды Әнвәр. «Ай, энем, әйдә, тиз генә җыен да безгә кил, Казахстаннан кодалар килеп төште, җизнәң шашлык кыздыра...» – дип тезеп китте апасы, аның «кайттым» сүзен ишетүгә. Үзе Әнвәр белән сөйләшкәндә, беррәттән янындагылар белән дә гәпләшеп ала һәм гадәтенчә, мөгаен, телефонын яулык астына кыстырып, нилләрдер эшләп тә маташа иде. Телефонның теге очындагы ыгы-зыгы монда кадәр сизелеп тора. Әнвәр аэропорттан туры авылга кайтып киткәнлеген көчкә аңлатып, телефонны куйды.

Аэропорт аларның авылыннан ерак түгел, шуңа күрә бер-ике көнгә генә командировкага барганда, машинасын аэропортта калдырып тора ул. Аннан кирәксә, шәһәргә, теләсә, авылга кайтып китә.

Апасы белән саубуллашып кына өлгерде, телефоны аваз салды. Кызы скайпка чыгып маташа. Кем уйлаган, шушы авылдан торып, дөньяның икенче кыйтгасындагы кешене күреп сөйләшеп булыр дип. Ничек тиз үзгәрде замана! Менә, телефон төймәсенә генә басты, Әминәсе елмаеп каршында тора! Гадәттәгечә, беренче сүзе: «Ой, әтием, мин бик ашыгам, әз генә вакытым бар», – булды. «Ничек кайтып җиттең? Минем барысы да әйбәт, эш күп. Хәзер туристлар җыелып бетә дә, китәбез. Минем өчен борчылма. Әтием, мин сине бик-бик яратам! Әйдә, бер-ике-өч!»

Кызының елмаюы гына күз алдында эленеп калды.

Кызы инде икенче ел чит илдә эшли: үткән ел Төркиядә эшләгән иде, быел Гарәп Әмирлекләренә үк китеп барды. Чит телләр факультетын тәмамлаган кешегә юллар ачык шул хәзер. Үзе үк аны дөнья күрергә этәрсә дә, бердәнбер якын, газиз кешеңне, кыз баланы күз күрмәгән җирләргә чыгарып җибәрү җиңел түгел икән. Ярый әле, бу скайп дигән хикмәт бар, көн саен диярлек күрешеп-сөйләшеп торалар. Шулай да ул сөйләшү әнә шул «Әтием, мин бик ашагам» була инде.

Кинәт дөнья убылган төсле булып китте. Бөтен тирә-юньне күзгә күренмәс шыксыз бушлык биләп алды. Өй эчендә уйнаган кояш та сүрелде. Әнвәр урамга карады. Кояш инде офык артына төшеп бара, ә күкне юка гына аксыл болыт элпәсе каплап килә иде. Ул ашыгып тәрәзәләрне япты. Әле җәй үтеп бетмәсә дә, җәйнең азагы, август ахыры шул инде. Көннең кыскарганлыгы да, бик тиз холык алмаштыруы да сизелә. Шушы көн төсле, күңел халәте дә үзгәрде дә куйды.

Бу халәт аңа таныш. Балачакта әнисе берәр кая китсә, шулай була торган иде: күңелдә кояш сүнә. Бөтен дөнья буп-буш калган сыман була. Һәм син үзеңне япа-ялгыз, бик бәхетсез, югалып калган кебек хис итәсең. Әнвәр төсе белән әтисенә охшаса да, күңеле белән әнисенә якынрак шул. Алар әнисе белән бер-берсенең күңел халәтен бик нечкә тоялар, ләкин беркайчан да бу турыда сөйләшмиләр иде. Әнисенең күңел дөньясын шулай тирән тойгангадыр, Әнвәр күп еллар әтисенә карата ачулы-үпкәле бер халәттә яшәде. Дөрес, бу халәтен ул беркайчан да сүзгә күчермәде. Юк, бер тапкыр әтисенә каршы чыгып карады, тик әнисе аны бик тиз туктатты.

Инде үзен бу дөньяны тулысынча аңлыйм дип санаган, егетлек чорына аяк атлаган чагы иде. Уналты яшь! Авылда печән өсте. Әтисе тагын ике-өч көн күрше урамда яшәп кайтты. Печән өстендә, утын әзерләгәндә аның күрше урамда югалгалап торуы беренче генә түгел. Моны инде бөтен авыл белә. Әнисе дә арып-таушалып, аракы сөременнән айныр-айнымас кайткан иренең кайда булганлыгын белеп тора. Белеп тора... һәм берни булмагандай: «Мунча ягылган, бар, юынып чык!» – дип иңенә сөлге чыгарып сала. Нигә башка хатыннар кебек чыр-чыр талашмый, тегe хатынның йортына барып буран куптармый, һичьюгы кычкырып-бакырып еламый соң әнисе?!

Юк, җитәр, әнисе түзгән җитәр, ул түзмәс, әнисен тагын да болай кимсетергә юл куймас! Бөтен кыюлыгын җыеп, ул әтисенең мунчадан чыгуын көтә башлады. Әйтәсе сүзләрен башында тәртипкә салырга тырышты. Тик вакыт үткән саен, әйтер сүзләр таркаулана, йөрәк тибеше кызулана барды. Ул хәтта дөп-дөп типкән йөрәген тынычландыру өчен күкрәк турысын кулы белән кысып торды. Менә мунча ишеге ачылды. Аннан әтисенең кызырган-сафланган йөзе күренде. «Әти...» – диде Әнвәр, тамак кырып. Тавышы каядыр эчкә таба китте. Йөрәк тибеше тавышын каплый төсле иде. Каты итеп әйтергә теләгән «әти» сүзе дә бик сыек кына чыкты. Әтисе дә ипле генә итеп: «Нәрсә, улым?» – диде. Әтисенең йомшак дәшүе аны тагын каушатты. Чөнки ул үзен кискен сөйләшүгә әзерләгән иде. Тегe вакытта әтисенең әнисе белән сөйләшүен ишетеп ятты, анда әтисенең тавышы бик кырыс, кисеп ала торган иде: «Безнең нәселдә хатын аерган кеше юк, нәселдә булмаганны кылдырма!» Ишекнең каты ябылуыннан өй селкенеп куйды. Бу тавышка ул инде йоклаган булса да уянырга тиеш иде, тик «уянып», әнисен уңайсыз хәлгә куюдан куркып, күзләрен чытырдатып йомды. Күзләрен йомса да, әнисенең ул йоклаган түр якка шыпырт кына башын тыгып каравын сизми калмады. Бу сөйләшү дә шундыйрак тонда булырга тиеш иде. Тик монда ультиматумны ул куяр: «Йә без, йә...» Кем дип әйтергә соң ул хатынны? Исеме беләнме, берәр ямьсез сүз беләнме?.. Ул уйларын җыеп өлгермәде, «Нәрсә сөйләшмәкче идең, улым?» – дип, әтисе аның иңенә кулын салды. Бу инде әти кешенең улы белән олыларча, җитди сөйләшергә әзер булуына ишарә иде, ә ул... олыларча сөйләшәсе урында, сабый бала кебек, калтыранган тавыш белән: «Син әнине, безне хурлап йөрисең, бөтен авыл бездән көлә!» – дип кычкырды дабакча ягына атылды. Өйдән чыгып килгән әнисен дә күз чите белән генә күреп калды. Бу хәлләрдән соң әнисе белән алар тагын да якынаерга тиеш төсле иде, тик... киресенчә булды.

Әнисенең салкын карашын беренче һәм бердәнбер тапкыр шул кичне тойды ул. «Әнвәр, башкача әтиеңә каршы сүз әйтәсе булма!» – диде әнисе басынкы, әмма кискен тавыш белән. «Әни, син үзең дә...» дип башлаган иде, «Миңа әйтергә ярый, сезгә – балаларга – юк! Ул сезнең әтиегез!» – дип кырт кисте. Бу йортта, хуҗа кешенең кайбер гөнаһларына да карамастан, әти исеме зур иде шул. Ул гөнаһлар алга таба кабатлангандырмы, тик шунысы хак: әлеге барып чыкмаган сөйләшүдән соң, әтисенең күрше урамда куна калганын хәтерләми Әнвәр.

Әтисен ул соң, бик соң гына, аны югалтып шактый еллар үткәч, тормышның әйтеп аңлатып булмаслык борылмаларында үзе дә шактый абынганнан соң гына аңлады. Тик үкенеч, исән чакта аңлаша алмау үкенече калды. Мәңгегә калды. «Үзем исән чакта нигезне бетермәм!» – дип, әтисенә күңеленнән вәгъдә бирде. Бу хакта әтисе белән беркайчан да сөйләшкәннәре булмаса да, ата күңелендәге теләк аңа аңлашыла иде. Ничектер, бер утырып, ирләрчә сөйләшә дә алмый калдылар шул, әтисе алтмышы да тулмастан кисәк китте дә барды. Инсульт.

Әтисенең үз куллары белән салган һәрбер бүрәнәсен аерым-аерым күздән кичергәндә, күңелдәге үкенечле уйлар Әнвәрнең йөрәген чемердәтеп алды. Йорт калын нарат бүрәнәләрдән биек-иркен итеп салынган. «Мари урманында кыш киселгән бүрәнәләр ул!» – дип горурланып әйтә иде әтисе. Авылда бер балта остасы иде, алтын куллы. Артык озын гәүдәле булмаса да, киң күкрәкле, нык бәдәнле чибәр кеше иде. Әнисе, киресенчә, зифа буйлы, какча гәүдәле, олыгайгач та сылулыгын югалтмады. Тик артык тыйнак, басынкы холыклы әнисе, җор телле, ачык күңелле ире янында беркадәр боеграк булып күренә иде. Әтисенең читкә карауларының сәбәбе шунда да булгандыр, ир-ат бит шат күңелле, уенчак хатыннарны ярата. Алай дисәң, Әнвәрнең күңелендә беренче тирән хисләр уяткан кыз да тыйнак, сабыр холыклы иде бит. Мөгаен, ул аны, үзе дә аңламастан, әнисенә охшатып яраткандыр.

Әле күңелне биләгән бушлык халәтен ул кабат нәкъ менә шул кызны югалтканда кичергән иде.

«Мин сине олы абыем кебек кенә күрдем, син дә миңа сеңел итеп кенә карыйсың дип уйлаган идем...» Венера тагын да ниләрдер сөйләде бугай, тик Әнвәр нидер аңлый алырлык хәлдә түгел иде. Аның алдында җир убылды, күкләр ишелде, дөнья бетте. Ничә еллар күңелендә иң якты нур булып дөньясын балкытып торган хисләр кадерсезгә калды. Күңел хисләре белән уртаклашмаса да, Венера аны сүзсез дә аңлый дип ышанган иде бит ул. Әле дә Венерага яратуын кычкырып әйтмәгән булыр иде, җәйге каникулдан килүенә, «Венера кияүгә чыга икән, Казаннан китә, читтән торып уку бүлегенә күчеп йөри» дигән хәбәр аны тәмам өнсез итте.

Төзелеш отрядында танышып-дуслашып алганнан соң, алар – физфак егетләре белән биофак кызлары – аерылмас бер төркем булып оештылар. Кызлар, Әнвәрләргә кушылып, университетның «Кар десанты» төркеменә дә язылдылар, язларын сплавка да йөрделәр. Чәчрәп тормаса да, кирәк урында сүзен ярып әйтә белгән кыю йөрәкле, юкка-барга зарлануны сөймәгән сабыр холыклы Венераны башкалардан аерып үз итте Әнвәр. Кайчан үлеп гашыйк булды соң ул аңа? Әйтә алмый. Бары иртәсен Венераны сагынып уяна, кичен аны уйлап йоклап китә башлагач кына, үзенең чып-чынлап гашыйк икәнен аңлады. Һәм нигәдер Венера да аңа карата шундый ук хисләр кичерә дип ышанды. Чөнки ул да Әнвәрне күргәч балкып елмая, походларда да гел бер тирәдә булалар, Әнвәрнең үзенә карата игътибарын да шулай тиеш кебек кабул итә иде.

Һәм... менә, көтмәгәндә, Әнвәрнең йолдызы сүнде. Бар дөнья буш, төссез, мәгънәсез булып калды. Ул элеккечә үк походларга йөрде, сплавларга барды... Тик беркайда да күңеленә ямь таба алмады.

Университетны тәмамлагач та, хәрби заводка урнашып, бетмәс-төкәнмәс командировкалар башлангач, үзен икенче яссылыкка күчкәндәй хис итте. Аңа нәкъ шундый эш, заводка исә нәкъ шундый белгеч кирәк булып чыкты. Икешәр-өчәр айга сузылган командировкаларга ул берсүзсез чыгып китә, хәтта тормышын инде бер урында гына күзалдына да китерә алмый башлаган иде. Илдә чираттагы үзгәрешләр башланып, хәрби заводлар ябылып, халык эшсез калган бер вакытта, Әнвәр дә яңа тормышка яраклашып, үз эшен ачып җибәрде. Нәкъ шул чакта гомеренең яңа бер сәхифәсе башланды: уйламаганда-көтмәгәндә күңегелгән буйдак тормышы белән хушлашты да куйды.

Хезмәттәшләре фирманың исәп-хисап эшләрен алып баручы Мөршидәнең үзенә карата битараф түгеллеген сиздергәләп торсалар да, Әнвәрнең үзе чибәр, үзе чая бу кызыйга беркайчан да ир-ат күзе белән караганы булмады. Ир-ат күз белән ярата, дисәләр дә, Әнвәр өчен кешенең күңел дөньясы мөһимрәк иде. Ә Мөршидә белән күңел дөньяларының ераклыгын сизде ул. Сизде... әмма, кызның яратуына каршы тора алмады. Әтисенең: «Улым, үзеңә тиң кешегә генә өйләнергә кирәк!» – дип әйткән сүзләрен Мөршидә белән тормыш итә башлагач исенә төшерде Әнвәр. Әтисен дә нәкъ шул вакытта аңлый башлады. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, өзелеп әйткән икән бу сүзләрне әтисе.

Авыл кызлары арасында беренче егет булып йөргән җор телле, шаян холыклы әтисе авылга килгән укытучы кыз, билгеле инде, аныкы булырга тиеш дип ышанган. Алай-болай сүз катып карап та, кызның үзенә исе китмәгәнлеген чамалагач, алдын-артын уйлап тормастан, укытучыны урлаган да кайткан. Үзенә мөкиббән китеп йөргән кызларның кайсысына гына өйләнсә дә, бәхетлерәк булыр иде, мөгаен... Хатыны аны санлап яшәсә дә, яратмавын, тиңсенмәвен тоеп гомер итү авыр булгандыр. Улына да васыять кебек итеп әйтте: «Үз тиңеңә генә өйләнергә кирәк, улым!» Тик улы да ата киңәшен тота алмады шул. Үзен «яратам» дигән кешегә, «мин яратмыйм» дип әйтә алмады. Үзе яратып та, яратуын җиткерә алмыйча югалткан Венерасын уйлады, үзе Мөршидәгә өйләнде. Венераның да Әнвәрне яратып йөрүен, аннан, өмете өзелеп, аңа үч итеп, ятларга китеп барганлыгын ишетеп, җаны бәргәләнгән чагы иде...

Мөршидәсенә дә, яратмавын әйтә алмаган кебек, яратуын да җиткерә белмәде. Илаһи бу тойгы Әнвәр күңеленә хатынын бала табу йортыннан алып чыкканда кагылды. Хатынының беркадәр агарып калган талчыккан йөзендә шундый да бер илаһилык иде... Әнвәрнең күңеленнән «Мадонна» дигән уй сызылып үтте. Шул арада шәфкать туташы кулына китереп салган нарасыйның сулышын тою гүя боз катламы астында яткан җанын эретте. Күңелендә кояш кабынды, меңәрләгән гөрләвекләр челтерәде, дөнья уянды. Бу минутта кулындагы нарасые белән янәшәсендә басып торган хатыны аңа бербөтен булып тоелды. Бу аның ин газиз, иң кадерле кешеләре иде. Бу аның.тормышының мәгънәсе иде. Аның, беренче тапкыр, хатынын кысып-кысып, җанына сеңдергәнче кочаклыйсы килде. Тик куллары буш түгел иде. Ә күңелдә туган хисләрне җиткерергә сүзләр таба алмады. Хатынының колагына «рәхмәт!» дип пышылдавы да ничектер ясалма чыкты кебек тоелды...

Аннан тормыш диңгезе тагын үз кочагына бөтереп алды. Һәм бу диңгезне кичү юлларын икесенең ике төрле күзаллавы арага дулкыннар булып ятты.

Көннәрнең берендә Әнвәр дә әтисенең сүзләрен кабатлады: «Безнең нәселдә хатын аерган кеше юк!» «Ярар, – диде Мөршидәсе салкын гына, – миңа да законлы аерылышу кирәк түгел. Бары мин калган гомеремне үземне яраткан кеше белән үткәрергә телим. Әйе, әйе, син яратмагач та, мине дә яратучы кеше бар ул. Күптән, бик күптән ярата. Әле сиңа кияүгә чыкканчы ук... Ә мин сине сайладым. Бергә яши башлагач, ярата алырсың дип уйлаган идем. Юк, син ярату хисеннән мәхрүм кеше булып чыктың». Мөршидә бераз уйланып торды да: «Алай ук түгел, хатын-кызны ярату хисеннән дип әйтмәкче булам, – дип өстәде. – Әминәбезне ничек яратканыңны беләм, шуңа күрә ул үсеп җиткәнче түздем. Апаңны да яратасың... Мине генә...» Кинәт Әнвәр Әминәләрен бала табу йортыннан алып чыккан вакытны күз алдыннан кичерде. Мизгел эчендә бөтен тереләге – сурәте, хисләре белән шул күренеш күңеленнән үтте. Менә хәзер Мөршидәсен кысып-кысып кочакларга булыр иде. Тик... иренең сузылган кулларын хатын дорфа гына этеп җибәрде дә, йокы бүлмәсенә кереп, алдан әзерләп куйган юл сумкасын алып чыкты. «Нигә син? Бәлки, мин чыгып китәргә тиештер бу фатирдан?» Әнвәрнең беркатлы соравына хатыны борын астыннан кинәле генә көлемсерәп куйды. «Анысын уйлашырбыз, минем өйдән чыгып китүем түгел, без Грециягә ял итәргә барып кайтабыз», – диде, «без»гә басым ясап. Бу Мөршидә иде. Әнвәр янәшәсендә гомер кичкән Мөршидә. Бала табу йортындагы илаһи Мадоннадан ерак, бик ерак хатын. Яратам сүзен Мадоннага әйтергә кирәк иде шул!..

Мөршидә ишекне ябып чыкканда, Әнвәрнең гадәти дөньясы кабат убылып төште. Күңелне таныш, бик таныш халәт – бушлык чорнап алды. Дөнья буш, шыксыз, өметсез төсле тоелды.

Ул вакытта әлеге халәттән аны кызы йолып алды. Әминә: «Мин әти янында калам», – дип, катгый үз сүзен әйткәч, Мөршидә яраткан кешесе янына күченде. Шулай итеп, фатир бүлеп йөрү мәрәкәсеннән дә арындылар. Бакчадагы йортны исә Әнвәр Мөршидә исеменә күчереп куйды.

Кызын искә төшергәч, Әминәнең әле генә күз алдында эленеп калган елмаюы биеп алды. Еракта булса да, җылысы монда кадәр җитә бит. Кояш кебек. Аның уйларын хуплагандай, кинәт өй эченә кызгылт яктылык инде. Әнвәр тәрәзәдән тышка карады. Баеп баручы кояш, ертылып киткән болыт пәрдәсе артыннан үрелеп, соңгы яктылыгын сибәргә ашыга иде.

Бер хәдистән укыган фикер исенә килде: кемне дә булса яратсаң, аңа яратуыңны әйтергә кирәк, яратуыңны әйтми калу гөнаһ, диелгән иде анда. Әнвәрнең гөнаһлары күп икән шул. Әнисе, әтисе, апасы, Венера, Мөршидә, кызы... Күңелендә кояш нурларыдай якты-кайнар хисләр йөртеп тә, берсенә бер җылы сүз әйтми яшә әле!.. Ул телефонын кулына алып, экрандагы зәңгәр төстәге S тамгасына басты. Экранда пәйда булган рәсемнәр арасыннан кызының фотосы турысына төртеп алды. Телефон шактый гына гөрелдәп тавыш биреп торды. Аннан Әминәнең бераз аптыраулы йөзе пәйда булды: «Әтием, ни булды?» «Берни дә юк, кызым, бая әйтергә өлгерми калдым, мин дә сине бик яратам!»

Саралан – Бәкер.
2014 ел, сентябрь

PRESSA.RU

2017
ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ
«ТАТАРСТАН»
ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

ЕЛ ВУЗЫ



КМТТУ-КАИ: ҺАМАН ЮГАРЫГА

«Татарстан» журналы сайты аша укучылар арасында уздырылган тавыш бирү нәтиҗәсе буенча КМТТУ-КАИ «Ел вузы» номинациясендә 2017 ел лауреаты булды. Тавыш бирү нәтиҗәләре шуны раслый*: сораштыруда катнашканнарның абсолют күпчелеге беренчелекне А. Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИга биргән.

КМТТУ-КАИның мактаулы номинациядә җиңүе очраклы түгел. Әлеге югары уку йорты инженер кадрлар әзерләү һәм югары технологияләр өлкәсендә гамәли мәсьәләләрне чишү буенча илебездә һәрчак иң алдынгы үзәкләрдән булды. КАИның 85 еллыгы билгеләп үтелгән 2017 ел университет өчен алга таба чын-чынлап зур адым булды. Юбилей чаралары кысаларында монда ике яңа үзәк ачылды: Россия федераль атом-төш үзәге белән уртак «Цифрлы икътисад» полигоны һәм Японияненң FANUC[1] ширкәте (сәнәгый автоматлаштыру өчен җиһазлар ясаучы абруйлы компания) белән бергә – Станок төзелеше үзәге. Мәгълүмат тапшырганда югары дәрәҗәдә саклык булуын тәэмин итә торган Россиядә һәм БДБ илләрендәге беренче күптөенле квант челтәре дә – КМТТУ-КАИның новаторлык потенциалын тагын бер тапкыр раслаган ачык үрнәк.

Болар белән бәйле рәвештә янә бер бик мөһим вакыйга көтелгән закончалык итеп кабул ителде. Ул университетның югары дәрәҗәсен генә раслап калмыйча, ә күп яктан аның алга таба үсеш юнәлешен дә билгеләде. КМТТУ-КАИ РФ Хөкүмәтенең «Инновацияләр булдыру мохитенең үзәге буларак вузлар» үстенлекле проектында җиңүчеләр исемлегенә керде һәм төбәкләрне инновацияле, технологик һәм социаль үстерү университет үзәкләре дип танылган 51 вузның берсе дип танылды. Төрле бәйрәм чаралары белән билгеләп үтелгән юбилей елында бу җиңү, мөгаен, уку йортының иң зур казанышларыннан берсе булгандыр. Сүз уңаеннан, юбилей чаралары чын-чынлап якын, җылы, гаилә бәйрәме – төрле шәһәрләрдән, төрле төбәкләрдән килгән кунаклар, бу уку йортын тәмамлаучылар һәм хезмәттәшләр әйләнәсендәге искиткеч зур концерт белән тәмамланды.

Мөһим бер үзенчәлекне телгә алып узыйк. КМТТУ-КАИда 85 еллык уңаеннан узган бер бәйрәм чарасын да бары тик юбилей өчен генә дип атап булмый. «Боинг» компаниясенең Россиядәге президенты белән очрашу, «Авиация двигательләре берлеге» халыкара ассоциациясе утырышы, WorldSkills[2] стандартлары буенча КМТТУ-КАИның сайлап алу чемпионаты уздыру, Шэньчжэнь алдынгы технологияләр институты җитәкчелеге белән сөйләшүләр… – болар да, башка вакыйгалар да эчтәлек ягыннан бик бай булды һәм анык фәнни һәм уку-укыту мәсьәләләрен чишүне күздә тотты. Моны, аерым алганда, Шэньчжэнь һәм AMTEC[3] ГмбХ (Идел-Днепр) вәкилләре белән хезмәттәшлек һәм партнерлык турында документлар имзалану да раслый.

Алга киткән һәр илнең икътисады сәнәгать тармакларына таяна, ә инженерлар – процессларны тәртипкә салучы һәм автоматлаштыручы, программалар эшләүче, стартаплар уйлап табучы, инновацияләр кертүче, җитештерүнең барлык техник асылын тормышка ашыручы профессионаллар ул. КМТТУ-КАИда бүген нәкъ менә шундый югары квалификацияле белгечләр әзерлиләр. Бу вуз дипломын алып тормышка аяк басучыларга ихтыяҗ булу – моның иң яхшы дәлиле. КМТТУ-КАИ ректоры Альберт Гыйльметдинов – Россиянең техник вузлары ассоциациясе вице-президенты. Бу ел башында уздырылган, сәләтле студентларга ярдәм күрсәтү һәм күзәтеп торуга багышланган Бөтенроссия җыелышына ректор югары квалификациясе белгеч сыйфатында чакырылган иде, һәм ул «Яңа җаваплылык. Сәләт. Җәмгыять. Яңа мөмкинлекләр» дип исемләнгән пленар сессиядә катнашты. Анда модератор буларак РФ Президенты ярдәмчесе Андрей Фурсенко чыгыш ясады.

КМТТУ-КАИда фәндә һәм белем бирүдә инновацияле ысулларны кертү үткәндә булдырылган һәм тупланган иң яхшы нәрсәләргә сакчыл мөнәсәбәт, аларны куллану белән бик җайлы яраша. Моның ачык мисалы – тавыштан тизрәк очарга сәләтле Ту-144 пассажир самолеты нигезендә уку йортында интерактив музей булдыру проекты. Былтыр бу ниятне тормышка ашыра башладылар да. Искә төшереп үтик: узган елның язында КМТТУ-КАИ искиткеч катлаулы операция башкарды: әллә ничә тонналы очкычны яңа җиргә күчереп, урнаштырып куйды. Әлеге легендар лайнер базасында киләчәктә интерактив музей ясау өчен, университетка Россия Федерациясе Президенты гранты бирелде.

Ту-144 самолеты нигезендә балалар һәм яшьләр өчен тиңдәшсез интерактив музей һәм техник уку-укыту комплексы булдыру проектын җәмәгатьчелеккә тәкъдим иткәндә, КМТТУ-КАИ ректоры Альберт Гыйльметдинов шуны билгеләп узды: бу проект ачык профориентация, патриотик тәрбия, үсеп килүче буында табигать фәннәренә һәм инженериягә карата кызыксыну уяту кебек ил өчен стратегик әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә йөз тота. Булачак комплекс инженерия һәм техник иҗат өлкәсендә сәләтле балалар өчен федераль дәрәҗәдәге уку-өйрәнү мәйданчыгы булыр дип планлаштырыла.

2018 елның 31 декабрендә, тәҗрибә өчен ясалган Ту-144 очкычының тәүге очышына 50 ел тулган көнне, самолет салонында тиңдәше юк интерактив техника музее ачарга ниятлиләр. Дөньяда тавыштан тизрәк очарга сәләтле беренче самолетның очучы кабинасы, штурман һәм бортинженерның эш урыны, салонының бер өлеше яңадан торгызылачак. Монда бер тапкыр булып чыккач, малайлар һәм кызларның самолетлар һәм күккә очу теләге белән «чирләячәге» һич шик уятмый. Аларның күбесе соңыннан КМТТУ-КАИга керәчәк, инженерлар, конструкторлар, яңа Ильюшиннар һәм Туполевлар – үз иленең горурлыгы булачаклар!

Фото КМТТУ-КАИдан алынды. Реклама.

* www.protatarstan.ru, [1] Фанук, [2] Ворлдскиллс, [3] АМТЭК.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 29нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

РАФИНАТ ЯРУЛЛИН: «МИН ЯХШЫ КЕШЕЛӘРДӘН УҢДЫМ»

Фото: Олеся Бондаревская

«ТАНЕКО», «ТАИФ-НК», «Аммоний» мегапроектлары һәм «Казан Оргсинтез» белән «Түбән Кама Нефтехим» берләшмәләрендәге яңа җитештерүләр Татарстанга инвестицияләр генә түгел, ноу-хау да җәлеп итәләр. Республика – Россия нефть-газ химиясендәге инновацияләр лидеры. «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ нең алыштыргысыз генераль директоры Рафинат Яруллин – уртак нәтиҗәгә керткән өлеше беркемдә дә шик тудырмаучы шәхесләребездән.

ПОРТРЕТКА БУЯУЛАР ӨСТИБЕЗ

– Рафинат Саматович, сез «Түбән Кама Нефтехим» берләшмәсендә эшләгәндә бер хезмәткәрегез: «Рафинатның холкы шикәр түгел», дип әйткән булган. Әңгәмәләрегез, эшлекле форумнардагы чыгышларыгызга карап фикер йөрткәндә, сез, чыннан да, һәртөрле сантиментларга вакыт әрәм итмисез.

– Ә сез иртәнге җидедән башлап, көн буена унбер завод директоры синнән бертуктаусыз нәрсәдер таләп иткән җитештерүдә эшләп карагыз әле! Яки төнге сәгать икедә: «Яруллин, сине алырга автобус китте – монда ут капкан!» – дип шалтыраталар. «Түбән Кама Нефтехим» берләшмәсе минем өчен җитди мәктәп булды. Комбинатка килеп төшкәндә (ул әле кечкенә иде), әлеге торбалар үрелешен беркайчан да аңлап җиткермәм кебек тоелды. 25 ел эшләү дәверендә шуңа төшендем: иң мөһиме – кешеләр белән шәхси мөнәсәбәтләрне җайлау. Баштарак безне, кичәге студентларны, аппаратчылар аптыраткыч сораулар биреп йөдәтә иде. Мәсәлән, «иярчен» нәрсә ул, дип. Бу исә – төп продуктүткәргеч янәшәсендәге җылыткыч чыбык кына. Һөнәри сленг нечкәлекләренә шулай әкренләп төшендек. Бүлек башлыгы Иван Федорович Березний каттый таләп тә итә, каттый тикшерә дә иде, әмма барысы да без тизрәк эшкә өйрәнсен өчен. Аннары мин үзем дә яшьләрне шулай өйрәтә башладым.

– Сезгә аеруча көчле йогынты ясаган өч кешене атап китмәссезме?

– Мин яхшы кешеләрдән уңдым. Армиядә хезмәт иткәндә, бер командирыбыз бар иде. Валентин Пикульнең «Честь имею» романындагы кебек чын рус офицеры: акыллы, белемле, зыялы, намуслы һәм гадел. Ул безне, солдатларны да, шулай тәрбияләде.

КХТИ да акыллы мөгаллимнәребез күп иде. Бигрәк тә профессор Наил Сибгат улы Әхмәтов хәтердә калды. Сүз уңаеннан, аның «Орга-

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Рафинат Самат улы Яруллин, «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ генераль директоры. 1943 елның мартында Удмуртия АССРның Можга шәһәрендә туган. Хезмәт юлын Бондюг химия заводында (Менделеевск) башлый. Казан химия-технология иеститутын (1970) һәм Мәскәү идарә институтын (1981) тәмамлый. 1970 елда Түбән Кама химия комбинатында мастер-технолог булып эшли башлый. Смена башлыгы, цех башлыгы, баш инженер булып эшли, озак вакыт буе «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ җитештерү идарәсен җитәкли.

1994 елдан – «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ генераль директоры. Рафинат Самат улы ТР нефть химиясе комплексындагы берничә предприятиенең директорлар советына керә, ул – «Кама инновацияле территориаль-җитештерү кластеры» Коммерциячел булмаган партнерлык ассоциациясе президенты. Татарстан Республикасының атказанган химигы, химия фәннәре докторы, КМТТУ (КХТИ) синтетик каучук технологиясе кафедрасы профессоры. «Инновацион эшчәнлектәге казанышлар өчен» номинациясендә «Ел җитәкчесе-2005» Республика иҗтимагый конкурсы лауреаты. «Дуслык» ордены, «Хезмәттәге уңышлары өчен» медале белән бүләкләнгән.

Реклама



БЕЛЕШМӘ

1990 елдан 1995 елга кадәр Татарстанда нефть чыгару 26 процентка кимегән. Нефть үзебездә эшкәртелмәгән, бөтен нефть диярлек чимал сыйфатында республикадан читкә җибәрелгән. Нефть химиясе предприятиеләренә углеводород чималы җитмәгәнгә, продукциянең үзкыйммәте арткан. Совет чорыннан калган җиһазлар бик тузган. Предприятиеләр арасындагы кооперация элемтәләре өзелгән, кече бизнес булмаган, фәнни-техник потенциалга ихтыяҗ кимегән.



ник булмаган химия» дәреслеген бизәгәндә, идеяләре белән яхшырак таныштым – үз вакытында сәнгать мәктәбен дә тәмамлаган идем бит. Өченче остазым – Николай Васильевич Лемаев, 1963-1985 елларда «Түбән Кама Нефтехим» директоры, соңрак – СССР химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министры.

– Сезнең өч төп принцибыгыз нинди?

– Беренчесе – зур түрәме ул яки гади эшчеме, һәркемне дә тигез күреп сөйләшү: беркемне дә түбәнсетергә ярамый, беркемгә дә ялагайланырга кирәкми. Мине әти-әнием балачактан шулай тәрбияләде. Икенчесе – даими, бертуктаусыз нәрсәгә булса да өйрәнү. Хәтта хәзер дә әле, текстта таныш булмаган сүз очратсам, сүзлекләрдән төгәл мәгънәсен тапмыйча тынычланмыйм. Балаларымны да шуңа өйрәттем. Өченчесе – рухи, әхлакый яктан камилләшү, яхшырак булырга тырышу, башкаларга зыян китерерлек гамәлләр кылмау. Ни кызганыч, хәзер нәкъ киресенчә эшләүчеләр бик күп шул.

– Сез Аллаһка ышанасызмы?

– Әйе, һәм, минемчә, һәр кеше гомеренең ниндидер мизгелләрендә илаһи көчнең булуын һәм йогынтысын тоя. Статистика мәгълүматлары буенча, фән белән шөгыльләнүчеләрнең 76 проценты илаһи зат барлыгына ышана. Шунлыктан мин ялгыз түгел.

Ә гомумән алганда, минем күзаллавым «советча»: кеше, җәмгыять, икътисад белән максат, идея идарә итәргә тиеш. Кытайның икътисадый уңышларына карагыз әле. Аларга күп очракта партиянең хәлиткеч роле нәтиҗәсендә ирешелгән. СССРда да партия җитәкче роль уйный иде. Мин КПСС сафларына 1962 елда армиядә, Кариб кризисы вакытында кердем. Күпчелек кебек үк, аның хаклыгына ышандым. Ни генә булса да, партия максатны күргән, стратегияне билгеләгән, бурычлар куйган. СССРда шулай булган, хәзер исә башка заман.

ИННОВАЦИЯЛӘР САНДЫГЫ

– 1994 елда Татарстанның нефть-газ-химия секторында «Татнефтехиминвестхолдинг»

1. Рафинат Яруллин, Түбән Кама химия комбинатының смена җитәкчесе.

2. Николай Васильевич Лемаев. 1963-1985 елларда «Түбән Кама Нефтехим» директоры, соңрак – СССРның химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министры.

Фотолар «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖнән алынды

PRESSA.RU

Фотолар «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ-нән алынды

әйдәп баручыга, юл күрсәтүчегә әйләнде. Сез анда ничек килеп эләктегез?

– Озак ризалашмадым. Тобольск, Менделеевск предприятиеләренә чакырулар күбрәк кызыктыра иде... Мин бит җитештерүче, практик, галим белән идарәче арасындарак белгеч буларак формалаштым, ә биредә – чиновниклык, кәгазь эше, аны мин алдан ук өнәмәдем. Шулай да планнар төзи, икътисадны саный башлагач, кызыксыну туды, ә иң мөһиме, конкрет зур эшләр башланды. Бу советның башка әгъзаларын да мавыктырды.

Мәсәлән, «Татнефть» компаниясенең бөтен генераль директорлары – Ринат Гыймаделисламович Галиев тә, Шәфәгать Фәхразыевич Тәһәветдинов та, Наил Өлфәтович Маганов та – химия икътисадын үстерүнең нефть сәүдәсеннән тамырдан аерылуын бик шәп аңлый иделәр. Республика җитәкчелеге дә, холдингка кергән компанияләр директорлары да күреп тора: чимал сату – бик җиңел һәм аз керемле эш, ә менә аңардан базарда ихтыяҗ булган әзер продукт җитештерү һәм өстәмә кыйммәт салымын республикада «эшләргә» мәҗбүр итү – катлаулырак бурыч.

– Сез ничек уйлыйсыз, холдинг каршына куелган бурычка ирешелгәнме?

– Әлбәттә, юк. Барлык районнарда технопарклар төзү яхшы нәрсә, әмма аларда эш урыннары булдыру катлаулырак шул. Күптән түгел бер министр белән бәхәсләштек: ул җитештерүчәнлекне ничек тә үстерүне данлый, ә мин әйтәм, аның үсеше эшсезлекне арттыра икән, аннан ни файда? Җитештерүне шундый итеп оештырырга кирәк ки, яңа продукция яңа эш урыннары да барлыкка китерерлек булсын. Моннан 10 ел элек без нефть-газ-химия комплексын үстерүнең кластер схемасын эшләгән идек. Анда Татарстандагы барлык җитештерүләрне, шулай ук биредә чыгарырга мөмкин булган, республикадагы ресурсларга технологик бәйле продуктларны да исәпкә алдык. Бу схемада «ак таплар» һаман күп әле.

Менә «Казан Оргсинтез» һәм «Түбән Кама Нефтехим» комбинатларына эшкә урнашып карагыз әле – вакансияләр юк. Мондый юнәлешләр исә үсәргә тиеш: һәр елны яңа җитештерүләр ачарга, яңа эш урыннары булдырырга кирәк. Әмма илдә сәүдә төп тармак булып кала бирә, һәм институт тәмамлаучыларның күбесе сәүдәгә китә, чөнки җитештерүдә аның белгечләренә ихтыяҗ юк.

– Нефть-газ-химия комплексын киңәйтүгә нәрсә комачаулый: технологияләр, финанслар яки теләк юклыгымы?

– Технологияләр турында сөйләсәк, Көнбатышның икътисадый санкцияләре дә комачаулый, булганга канәгать предриятие хуҗалары да. Әгәр дәүләт предприятиеләрнең контроль пакетларын үзендә калдырса, кадрлар буенча да, фәнни-тикшерену һәм сынау-конструкторлык эшләре (НИОКР), шулай ук яңа продукция чыгару буенча да үз сәясәтен үткәрер иде. Стратегик предприятиеләрнең шактый өлешен дәүләт кулында калдырып, әлеге балансны саклый алган Минтимер Шәрипович Шәймиев эшчәнлеге нәтиҗәсендә Татарстан бүген динамик үсештә әле.

БЕЛЕШМӘ

1999 елдан республиканың нефть-газ-химия комплексы (НГХК) бердәм структура буларак, ТР НГХК үстерү бишьеллык программаларын гамәлгә кертү юлы белән үсә.

Хәзер 2015-2019 елларга 4 нче Программа гамәлгә кертелә. 1999-2017 елларда НГХК предприятиеләре 1,3 триллион сумга якын инвестицияләрне төп капиталга үзләштергән. Нефть чыгару күләме 25,8 миллион тоннадан (1998) 35,5 миллион тоннага (2016) җиткән.

Нефть эшкәртүнең бердәм комплексы формалашкан, пластик чыгару – 4,5 тапкырга (1,7 миллион тоннага җиткән), синтетик каучуклар җитештерү – өч тапкырга (670 мең тоннага җиткән), резин һәм пластмасса эшләнмәләр ясау 6,5 тапкырга арткан. НГХК продукциясе структурасында эшкәртү секторы өлеше 62 процентка җиткән (1998 елда 35 процент булган).

Реклама

“ – Республика җитәкчелеге химиянең Татарстан өчен нинди мөмкинлекләр ачуын яхшы күрә.

Республика җитәкчелеге Татарстан өчен химиянең нинди мөмкинлекләр ачуын яхшы күрә. Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов, Премьер-министр итеп билгеләнгәч, химия белән чынлап торып кызыксына башлады: нефть эшкәртү һәм нефть химиясе турында бик күп әдәбият белән танышты, хәзер белгечләр белән бер телдә сөйләшә ала. Әгәр 1994 елда елына нибары 3-4 миллион тонна гына нефть эшкәртелсә, хәзер әлеге күрсәткеч 15 миллион тоннага җитте. Һәм һәр яңа җитештерү – акча, яңа эш урыннары дигән сүз.

Ни өчен Кытай химия сәнәгатен үстерү буенча беренче урынга чыга? Чөнки Си Цзиньпин Пекиндагы химия-технология институтын тәмамлаган һәм химиянең иң керемле бизнес булуын яхшы аңлый. Әгәр машина төзелешендә табыш – 30, электроникада 50 процентка җитсә, химия һәм нефть химиясендә табыш 60 процентка, фармацевтикада исә 120 процентка да җитәргә мөмкин! Нефть химиясе буенча СССР дөньяда икенче урында торган, чөнки Леонид Аркадьевич Костандов һәм Виктор Степанович Федоров кебек җитәкчеләр хәтта Н.С.Хрущевны да аның белән шөгыльләнүнең зарурлыгында инандыра алган.

– Сәнгать мәктәбен тәмамлаган кеше буларак, сезнең үзегезне химиядә нәрсә җәлеп итте соң?

– Туганнан туган абыем МХТИда укый иде, бер кайтуында нәрсәләргә өйрәнүен шундый мавыктыргыч итеп сөйләде ки, ул чакта алтынчы сыйныфта укыган мин дә химия белән чын-чынлап кызыксына башладым.

ИДЕЯДӘН КОНВЕЙЕРГА КАДӘР

– Холдинг эшчәнлегенең кайсы юнәлешен иң мөһим дип саныйсыз?

– Безнең төп вазыйфабыз – инновацияләрне «туплау». Иң беренче булып безгә бу бурычны әле ул чакта хөкүмәт җитәкчесе булган Рөстәм Миңнеханов куйды: ил буйлап йөрергә, иң яңа технологияләрне табарга һәм бездә кертергә. Совет чорында булган бик күп фәнни-тик-

БЕЛЕШМӘ

1999 елдан НГХКның бөтен предприятиеләре яңартылган, сәнәгать һәм көнкүреш пластмассаларыннан күп төрле эшләнмәләр җитештерү буенча куәтләр булдырылган, бәйсез нефть чыгару компанияләре консорциумы төзелгән.

Реконструкцияләгәннән соң Миңлебай газ эшкәртү заводы «Казан Оргсинтез» ГАҖнә этан җибәрүне икеләтә арттырган (2008 елдагы 96 мең тоннадан 2017 елдагы 181 мең тоннага кадәр), соңгысында полиэтилен җитештерүгә зурайтылган һәм поликарбонатлар чыгарыла башлаган.

«ТАНЕКО» АҖ нефть эшкәртү комплексы төзелгән, анда 2016 елдан бирле карасу төстәге нефть продуктлары чыгару тулысынча туктатылган.

«ТАИФ-НК» ААҖндә нефтьне беренчел эшкәртү җайланмасы яңартылган, бензиннар һәм авиакеросиннар җитештерүләре булдырылган.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ галобутилкаучуклар, неодим һәм литий катализаторларындагы полибутадиен каучуклар, дивинил-стирол каучуклар җитештерүне үзләштергән. Пластиклар сегментында полиэтилен, полипропилен, полистирол, АБС-пластиклар җитештерүләре булдырылган. «Түбән Кама Нефтехим» – изопрен каучугы глобаль базарында лидер һәм бутил каучуклары җитештерү буенча дөньяда өченче урында тора. Альфа-олефиннар җитештерүне яңарту нәтиҗәсендә 2016 елда линияле полиэтилен чыгару арттырылган.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә шиннар җитештерү модернизацияләнгән, 2009 елдан тоташ металл кордлы шиннар заводы, 2015 елдан аларны төзәтү заводы эшли.

2015 елда «Аммоний» АҖндә аммиак, метанол һәм карбамид җитештерү буенча яңа комплекс эшли башлаган.

Республиканың иң зур индустриаль мәйданчыклары – «Алабуга» МИЗ һәм «Химград» Технополисы 10 елдан артык эшли. Яр Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән һәм Чистай шәһәрләре алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (АСИҮТ) статусын алды.

PRESSA.RU



шеренү институтларын, РФА институтларын урадык, мәгълүмат алмашуны җайга салдык. Яңа материаллар буенча Россия Фәннәр академиясе белән эшлибез, мин үзем дә КХТИда шулар буенча лекцияләр курсы укыйм.

Хәзер төркем белән Томскига җыенабыз, Новосибирскида берничә тапкыр булдык. Анда соңгы баруыбызда миңа: «Сиңа кадәр бирегә Кытайның Премьер-министры үз командасы белән берничә көн утырды», – дип сөйләделәр. Кытайлар безнең күп институтта булган инде, һәм күргәннәренең шактыен үзләрендә гамәлгә дә кертәләр. Безнең хезмәткәрләребез дә яңа техник чишелешләрне бөтен дөнья буйлап эзли. Чималны тирәнтен эшкәртүгә өстенлек бирелә. Без ике нефть эшкәртү заводы өчен технологияләр таптык, Менделеевскидагы минераль ашламалар заводын төзү проектын эшләдек. Бүген карбамидларны эшкәртү, комплекслы ашламалар җитештерү вариантларын эзлибез.

Яңа юнәлешләр арасында – композитлар җитештерүне үзләштерү. Нефть химиясе һәм автомобиль сәнәгате тоташкан урын – «Иннокам» кластерында яңа җитештерүләр булдырыла: IT-технологияләр, робот техникасы, аддитив технологияләр, акыллы материаллар. Берничә шәһәрнең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (АСИҮТ) статусын алуы яңа мөмкинлекләр ача: төрле күргәзмәләрдә эшләгәннән соң без берничә тәкъдим алып кайттык инде.

– Сез инновацияләр кертүнең катлаулы эш булуын кабатларга яратасыз. Төп кыенлыклар нәрсәдә?

– Фәнни-тикшеренү институтларында һәм югары уку йортларында үткәрелгән НИОКР нәтиҗәләренең җитештерүгә ник шулай әкрен кертелүен мин бирегә пунктлап санап чыгар идем. Беренчедән, сынау-сәнәгать апробациясенең зәгыйфь структурасы. Технологияләр булдыру өчен, пилот җайланмалары кирәк. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә пилот җайланмалары үзәге бар, анда фәнни нәтиҗәләр тикшерелә, тик ул бер генә.

Икенчесе – күп предприятиеләр һәм кайбер институтлар «ябык». Без хәтта үз республикабыздагы кайбер предприятиеләрнең мөмкинлекләрен һәм хаҗәтләрен белмибез. Алар турында тулы мәгълүмат булмагач, фән эшләнмәләрне кемгә тәкъдим итәргә белми аптырый, бизнес исә тикшеренүчеләргә төгәл бурыч куя алмый: соңгылары предприятиенең проблемаларын хәл итми торган сынаулар үткәрә. Хәзер без югары уку йортлары ректорлары белән бу юнәлештә эшлибез.

Өченчедән – югары уку йортларының үзара кооперациясе юк: һәр вуз тикшеренүгә бүленгән акчаны берьялгызы гына үзләштерергә омтыла. Уртак тикшеренү үзәге булдыру урынына, эре уку йортлары еш кына тематикалары буенча бер-берсен кабатлый торган үз лабораторияләрен ача.

Һәм әле тагын кадрлар мәсьәләсе дә бар: инновацияләр белән бөтен этапларда да югары дәрәҗәдәге һөнәрмәндләр эшләргә тиеш, ә безнең югары уку йортлары һәм предприятиеләребез арасында кирәкле белгечләр әзерләүдә өзеклек килеп чыга. Мин институтка кергәндә, бер урынга 7-8 кешелек конкурс иде, соңгы елларда исә килгән һәркемне алдылар. Хәзер вазгыять җайлана башлады, студентлар да үзгәрәк: теләсә кайсы идеяне шундук эләктереп алып, азагына кадәр уйлап җиткерәләр. Инновацияләр кертү белән шөгыльләнергә әзер кешеләр дә күп инде. «Татнефть», ТАНЕКО, «Түбән Кама Нефтехим» берләшмәләрендә, «Алабуга» махсус икътисадый зонасында һәм кече нефть компанияләрендә башланган проектларда технологияләрне бик шәп белүче белгечләр буыны үсеп җитте. Әлеге заводларда булганда, алар белән сөйләшкәндә, мин мондый белгечләрнең акылына, фикерләү тизлегенә шаккатам. Аларны хәзер үк Россия буенча шундый җитештерүләрне үстерү белән җитәкчелек итәргә куярлык.

– Ноу-хау кертүләрне финанслау белән эшләр ничегрәк тора соң?

– Бу – төп проблема. Ни өчен Германия, Корея яки АКШта инновацияләрне финанслау эше яхшы куелган? Анда уңайлы кредитлар бар. Безнең банкларда алар юк. Банклар тәкъдим иткән шартларда кредит алырга проектларының рентабельлелеге 200-300 процент тәшкил иткән бик аз предприятиенең генә хәленнән килә. Акча бар ул үзе, тик банк системасы начар эшли.

Фотолар «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖннән алынды

Реклама

КӨН КАДАГЫНА

– 2018 елда һәм якын киләчәктә тармакта нинди әһәмиятле эшләр көтелә?

– «ТАИФ-НК» ААҖндә нефтьнең авыр калдыкларын тирәнтен эшкәртү комплексын файдалануга тапшырырга, алдагы бер-ике елда ТАНЕКОда составы буенча дөнья стандартларына туры килә торган автобензин җитештерүне үзләштерергә җыенабыз.

2021 елга каучукның бөтен төрләрен җитештерү күләмен елына миллион тоннага җиткерергә исәп тотабыз һәм «Түбән Кама Нефтехим» яңа олефин комплексының елына 600 мең тонна этилен куәтле беренче чиратын эшләтеп җибәрүне планлаштырабыз. 2025 елдан, икенче чират сафка бастырылгач, җитештерү күләме икеләтә артачак һәм, димәк, полиэтилен, полипропилен, полистирол җитештерү буенча яңа куәтләр пәйда булачак.

БЕЛЕШМӘ

2005-2016 елларда республикадагы НГХК предприятиеләре әйләнә-тирә мохитне саклауга 150 миллиард сумнан артыграк акча бүлгән. Берничә завод реконструкцияләнгән. 2008-2016 елларда «Татнефть» ГАҖ иярчен нефть газын утильләштерү проектларын гамәлгә кертүгә 4,6 миллиард сумнан артыграк акча сарыф иткән, хәзер аны нәтиҗәле файдалану дәрәҗәсе 96,4 процентка тәңгәл. Яңа технологияләр кертү нәтиҗәсендә еллык төче су алу күләме өчтән бер тапкырга кимегән.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ экологик программаны тормышка ашыруга шактый акча бүлә. 2016 елда биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләүнең беренче этабы тәгәлләнгән. Су торбаларын чистартканнан калган, җиргә күмелә торган каты калдыкларның күләме кимегән. 2018 елда сәнәгать сулары өчен 13 километрлы яңа коллектор төзелә башлаячак.
«ТАИФ-НК» ААҖндә нефтьнең каты калдыкларын тирәнтен эшкәртү комплексын файдалануга тапшыру эшкәртү тирәнлеген 98,5 процентка җиткерергә һәм калдыксыз диярлек җитештерү булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Сәнәгать юынтык суларын локаль чистарту цехын реконструкцияләгәннән соң судан нефть продуктлары сыйфатында 99,99 процент пычрак юкка чыгарыла, чистарту корылмаларыннан һаваны пычрата торган матдәләр 90 процентка азрак чыгачак.

«ТАНЕКО» АҖ ндә яңа җайланмалар төзелеше технологияләрен сайлаганда экологик яктан нәтиҗәләренә өстенлек бирелә. Юынтык суларны чистарту комплексында кулланыла торган технологияләр чистартылган суның 75-80 процентының җитештерүгә кабат кайтарылуын тәэмин итә. 2015 елдан бирле РФА Казан фәнни үзәгенең
Е. А. Арбузов исемендәге ОФХИ белән берлектә шламнарда нефть продуктлары күләмен киметергә һәм аларны тулысынча зарарсызландырырга мөмкинлек бирә торган яңа биодеструкторларны сынау эше бара.

PRESSA.RU

Эре тоннажлы химия тармагындагы перспективалы юнәлеш – газ химиясе, акрилонитрил, эпихлоргидрин, эпоксидлы, полиэфирлы һәм винилэфирлы сумалалар җитештерүләрен булдыру. Шулай ук аз тоннажлы һәм махсус химияне дә үстерәчәкбез. Биотехнологияләр өчен бик мөһим булган бөртекне тирәнтен эшкәртү проекты да эшләнә.

– Проектларның экологик асылы турында да сорамый булдыра алмыйм, тармак бик үзенчәлекле бит.

– Германиядәге Людвигсхафенда нефть-химия комплексы Түбән Камадагыдан 3-4 тапкырга зуррак. Әмма анда экологиягә бәйле сораулар тумый. Югары культура – безгә дә менә шуңа ирешергә кирәк. Җиһазларны һәм куәтләрне яңарту (бигрәк тә дегидрогенизация цехларында) технологияләр заманча булсын һәм антропоген йөкләмәне киметсен өчен үткәрелә.

– Хәзер республикада нефть-газ-химиясенең кайсы юнәлеше аеруча мөһим?

– Нефтьтән алынган продуктларны тагын да эшкәртүгә юнәлтелгән барысы да. Өстәмә кыйммәт алып һәм аны Татарстанда калдырып, яңа продуктлар җитештерү ассортиментын һәм күләмен арттырырга, импортны киметеп, полимерлы һәм композицион материалларның ассортиментын киңәйтергә кирәк.

– Сүз уңаенда, яманаты чыккан санкцияләр турында. Кыенлыклар тудымы, импортны алыштыру ни хәлдә?

– Безнең продукцияне экспортка чыгаруга килгәндә чикләүләр әлләни зыян китермәде. Эре компанияләрнең чит ил партнерлары белән бәйләнешләре еллар буена сыналган һәм үзгәрешсез кала. Ә кайбер технологияләрне тарату элегрәк тә лицензияләр белән чикләнгән иде. Шунлыктан республикада перспективалы нефть химиясе продуктларының тулы бер уемталары юк: пропилен оксиды, изоционатлар һәм полиуретаннар, инженерлык пластикларының, җилем һәм сумалаларның күп төрләре технологияләре хакында сүз бара.

Шул ук вакытта безнең предприятиеләребез импорт чималыннан, материал һәм җиһазларыннан бәйлелекне киметә. Нефть чыгару һәм эшкәртүдәге импорт реагентлары һәм ярдәмче материаллар, шин, көнкүреш химиясе, пыяла сүсе, полимер әлпәләр җитештерүдәге кайбер компонентлар үзебезнең илдә эшләнгәннәренә алыштырылды.

– Республикада махсус химия һәм пластмассалар тармагында чит ил инвесторлары катнашында нинди проектлар гамәлгә кертелгән?

– «Алабуга» махсус икътисадый зонасында техник газлар җитештерү буенча Франциянең "Эр Ликид" заводы, коррозиягә каршы сыек каплагычлар җитештерү буенча Американың «3М» предприятиесе, Төркиянең «Дизайн-Рус» пластик торбалар заводы эшли. «Химград» технополисы резидентлары арасында Германиянең «БАСФ Төзелеш системалары» һәм «Шүлкен Форм Рус» бар. Быелтыр нанокомпозит каплагычлар җитештерү буенча Американың «Адвенира Энтерпрайс» предприятиесе ачылды.

Уртак проектлардан «Татнефть» компаниясенең пыяла сүс җитештерү буенча Германия компаниясе һәм ЦМК-шиннар торгызу буенча италиялеләр белән уңай тәҗрибәсен аерып әйтер идем.

– Сез полимерлар эшкәртүнең республика икътисады өчен «алтын ятмасы», акча һәм эш урыннары «сугу станогы» булуы турында сөйлисез. Һәм гәрчә Татарстанда моның белән хәзер йөздән артык предприятие мәшгуль булса да, барыбер канәгатьсезлек өчен сәбәп табасыз...

1. «Алабуга» МИЗ.

2. «ТАНЕКО» АҖ

3. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ

4. «Казан Оргсинтез» ГАҖ.

Фотолар «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖнән алынды

– «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ һәм «Казан Оргсинтез» ГАҖ Россиядә чыгарыла торган база полимерлары күләменең яртысына якынын җитештерә, шулай булгач, аларны республикада булмыйча кайда эшкәртергә соң? Әмма бурычны катлауландырырга кирәк: куллану үзлекләре югарырак, өстәмә кыйммәте зуррак булган, тагын да катлаулырак югары технологияле конструкцияләрне, югары температуралы һәм башка «акыллы» полимерларны үзләштерү таләп ителә. Бурыч катлаулы. Хәтта барлык пластмасса һәм каучук эшкәртүчеләрнең эшен көйләү генә дә кыенга туры килә. Кайбер мономерлар һәм җитештерү өчен кирәкле реакторлар юк. Аларны табарга, тикшеренүләр үткәрергә кирәк. Бу – зур фәнни һәм өйрәнү эше. Пластмасса һәм каучуклар чыгару җиһазларын үзебезнең илдә җитештерүне дә җайга салырга кирәк, чөнки без аларны хәзергә европалылардан һәм кытайлардан сатып алабыз. Монда да эш без элегрәк сөйләгән финансларга килеп терәлә. Араларында кече һәм урта бизнес вәкилләре күп булган полимер эшкәртүчеләргә ярдәм чаралары – кредитлар, банк гарантияләре кирәк.

– Холдинг ярдәмендә республика бу бурычны да уңышлы хәл итәр, дип өметләнәм. Беренче тапкыр гына түгел бит. Эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт. »Татарстан» журналы редакциясе исеменнән сезне 75 яшь тулу белән котлыйбыз һәм ихластан нык сәламәтлек, гаилә иминлеге, яңа уңышлы идеяләр телибез!

> **“ – Араларында кече һәм урта бизнес вәкилләре күп булган полимер эшкәртүчеләргә кредитлар, банк гарантияләре кебек ярдәм чаралары кирәк.**

БЕЛЕШМӘ

Кайбер предприятиеләр өчен яңа, импортны алыштыру юнәлешләрен үзләштерү үсеш драйверына әйләнде. Россиядә бердәнбер галобутилкаучук, түбән тыгызлыктагы полиэтилен, альфа-олефиннар («Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ) һәм поликарбонат («Казан Оргсинтез» ГАҖ) җитештерүчеләр Татарстанда урнашкан. Полимерлар эшкәртә торган «Данафлекс» компанияләр төркеме һәм «Ай-Пласт» ЖЧҖ дә импортны алмаштыру белән шөгыльләнә, аларның продукциясе экспортка да чыгарыла.

Пыяла сүс («П-Д Татнефть-Алабуга Пыяла-сүс» ЖЧҖ) һәм углеводородлы сүс («Алабуга-сүс» ЖЧҖ) җитештерү предприятиеләре эшләтеп җибәрелгәч, республикада полимерлы композицион материаллар тармагы формалаша башлады. Яңа чимал автомобиль төзелеше («Каматек» ЖЧҖ) һәм төзелеш («Татнефть-Пресскомпозит» ЖЧҖ) өчен эшләнмәләр ясауда кулланыла.

«Сингер» Җитештерү-коммерция фирмасы ЖЧҖ гель барлыкка китерә торган утсүндергеч «Аквасим» порошогын – акрил кислотасы һәм аның тозлары нигезендә дымсаклагыч суперабсорбент – уйлап тапкан һәм базарда сата. «Аммоний» АҖ базасында карбамидтан меламин җитештерүен төзү мөмкинлеге карала. 2016 елда полимерлар эшкәртү буенча «Данафлекс», «Техстрой», «Тасма», «Мультипласт», «Кама полимер материаллары заводы», «Сафпласт» проектлары гамәлгә кертелә башлаган. Яңа җитештерүне башлап, «Нәфис Косметикс» полимер төрү материалы ясау өчен 3D-принтердан файдаланган.

Реклама

PRESSA.RU

Тимур Шаһивәлиев,
«Алабуга» Сәнәгать-җитештерү тибындагы МИЗ» АҖ генераль директоры

Сез – туган җирнең чын патриоты

Хөрмәтле Рафинат Саматович!

«Алабуга» махсус икътисадый зонасының бар коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм. Сезнең 75 яшьлек бәйрәмегез – Татарстан Республикасының бөтен нефть химиясе тармагы өчен, сез укыткан, сез өйрәткән һәркем өчен зур вакыйга.

Татарстан нефть химиясе үсешенә керткән өлешегез бәяләп бетергесез. Республикабыз Россиядә бу тармакның үзәге булып тора, һәм мондый казанышка ирешүдә Сезнең ролегез бик зур. Сез – туган якның, илнең чын патриоты, Россиягә, Татарстанга мәхәббәтен, тугрылыгын сүз белән генә түгел, ә хезмәте белән дә раслаучы кеше.

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында Сезне остаз, укытучы һәм чын профессионал буларак беләбез һәм югары бәялибез. Нефть химиясе өлкәсендә дә, аңа бәйләнешле башка тармакларда да төрледән-төрле проектларны әзерләгәндә һәм тормышка ашырганда, без һәрвакыт Сезнең биниһая зур һөнәри тәҗрибә һәм җитди аналитикага корылган төпле фикерегезгә таяндык һәм таянабыз. Сез безгә яңа инвесторлар җәлеп итүдә, «Алабуга» МИЗының яңа үсеш планнарын чынга ашыруда ярдәм итәсез.

Сез төрле тармаклардагы берничә буын белгечнең остазы һәм укытучысы. Белемегез, бай тәҗрибәгез, үткен зиһенегез һәм аналитик фикерләү сәләтегез – Татарстан өчен чын хәзинә, ихлас кызыксыну белдергән һәркем белән бу байлыкны Сез ихлас бүлешәсез. Рафинат Саматович, Сезгә юбилеегыз көнендә «Алабуга» махсус икътисадый зонасының корпоратив университеты проектына булышлыгыгыз, аның студентлары белән аралашуга тапкан вакытыгыз өчен аерым рәхмәт белдерергә телим. Тормышларын нефть химиясе сәнәгате белән бәйләргә ниятләгән яшьләргә бу әңгәмәнең һәр минуты, һичшиксез, бәяләп бетергесез кыйммәт, алар Сездән мөмкин кадәр күбрәк белем, үрнәк алырга тырыша.

Юбилеегыз көнендә Сезгә саулык-сәламәтлек, озын гомер, барлык яңа план һәм проектларны чынга ашыруда көч-куәт телим. Энтузиазмыгызны, тормышка мәхәббәтегезне һәм хезмәткә бирелгәнлекне саклап, Татарстан Республикасы язмышы өчен җан атып яшәгән һәркем өчен үрнәк булып калыгыз.

Фото «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖнән алынды

Фото «Татэнерго» АҖ-нән алынды

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Рафинат Саматович!

Сезне чын күңелдән 75 яшьлек гомер бәйрәмегез белән тәбрик итәбез! Мондый белем дәрәҗәсенә, үткен акылга, югары компетенциягә һәм зур тәҗрибәгә ия кешеләр республикада гына түгел, хәтта Россия күләмендә дә күп була алмый. Сез хезмәт юлыгызны гади эшчедән башлап, һөнәрегезне тормыш мәгънәсенә әйләндердегез. Әлеге хезмәт юлында туплаган гыйлем-тәҗрибәгезне хезмәттәшләрегез һәм шәкертләрегез белән бик юмарт уртаклашасыз. Шуңа күрә Татарстанда фән һәм сәнәгатьнең төрле тармакларындагы йөзләгән белгеч Сезне үз остазы, укытучысы дип атый.

75 яшьлек юбилеегыз – шәхси бәйрәм генә түгел, республика, аның нефть химиясе комплексы өчен зур вакыйга. Күпьеллык һәм уңышлы хезмәтегез нәтиҗәсендә Сез партнерларыгыз арасында бик зур абруй, хөрмәт казандыгыз. Үз эшенә күңелен биргән һәр кешегә хас булганча, Сезгә дә яңа идеяләр һәм өметле планнар көч-куәт өстәп тора.

Хөрмәтле Рафинат Саматович, Сезгә озак елларга җитәрлек ныклы сәламәтлек телим. Моннан соң да һәр көнегез дәрт-дәрманга тулып торсын, мәгънәле үтсен. Йортыгыз һәрвакыт шатлык-куанычлар белән балкып, мәхәббәт җылысына төренсен!

Фото «Союзхимпромпроект» институтыннан алынды

Павел Кочнев,
«Союзхимпромпроект»
институты директоры

Хөрмәтле Рафинат Саматович!

«Союзхимпромпроект» институты җитәкчелеге һәм коллективы Сезне олы бәйрәмегез – 75 яшьлек туган көнегез белән ихластан котлый.

Яңа меңьеллык башыннан бирле институтыбыз эшчәнлеге Сез җитәкләгән структура белән тыгыз бәйләнгән. СССРның инвестицияләрдән дистә елларга мәхрүм хәрби-сәнәгать тармакларыннан берсендәге юнәлешле институт буларак оештырылган «Союзхимпромпроект» күп яктан Сезнең тырышлык белән Татарстан Республикасы нефть химиясе комплексы составында яңа тормышка юллама алды!

Республиканың нефть эшкәртү һәм нефть химиясе кластерын үстерү стратегиясе Сез җитәкләгән «Татнефтехиминвестхолдинг» компаниясенең актив катнашында тормышка ашырыла. Әлеге стратегия институтыбызга Татарстанның мөһим тармакларында иң әһәмиятле инвестиция проектлары буенча эшләгән оешмалар арасында лаеклы урын алырга мөмкинлек бирә. Проектларны башкарганда, яңа технологияләрне, конструктив ысулларны чынга ашырганда туа торган катлаулы, кайчак хәтта бәхәсле сорауларны чишүдә ярдәм итүегез, акыллы киңәшләрегез өчен без Сезгә тирән рәхмәтле.

Киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлекне дәвам итәргә өметләнәбез һәм Сезгә ныклы сәламәтлек, энергия, оптимизм, ерак офыкларны күздә тоткан планнарыгызның, колач җитмәслек проектларыгызның тормышка ашуын, лаеклы, ышанычлы партнерлар юлдаш булуын телибез!

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов

«ТОТЫНГАНСЫҢ ИКӘН, НАМУС БЕЛӘН ЭШЛӘ»

Ул, әтисе эзеннән барып, чын күңеленнән тормышын авыл хуҗалыгы белән бәйләргә уйлаган булган. Әмма райкомда оештыру сәләте һәм инженер-механик белеме башка урында яхшырак ачылыр дип исәпләгәннәр. Һәм аны Арча нефтебазасына директор итеп җибәргәннәр. Бүген Рөстәм Сабиров – Татарстанның атказанган нефтьчесе, Россия ягулык-энергетика комплексының Мактаулы хезмәткәре.

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ:

Рөстәм Наил улы Сабиров 1958 елның 14 мартында Арча районының Дүсем авылында туа. «Авыл хуҗалыгын механикалаштыру» белгечлеге буенча Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый (1980). «Сельхозтехника»ның Әтнә бүлегендә автоколонна инженеры, Арча АТПның пассажир автоколоннасы башлыгы, КПССның Арча райкомында авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы булып эшли. 1985–1998 елларда – «Арчанефтепродукт» ААҖ директоры. 1998 елдан – «Татнефтепродукт» генераль директоры.
«Ел җитәкчесе-2005» Республика иҗтимагый конкурсында «Корпоратив идарә итүдәге югары дәрәҗә» номинациясендә лауреат. «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, ТР Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. ТР Дәүләт Советы депутаты, Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әгъзасы.

КАРЬЕРА ҺӘМ УҢЫШ ФАКТОРЛАРЫ ТУРЫНДА

Рөстәм Сабиров «Татнефтепродукт»ка җитәкчелек итә башлаганнан бирле дә егерме ел вакыт үтеп киткән. Бу катлаулы, әмма кызыклы эшнең беренче көннәрен һәм айларын ул вак-төягенә кадәр бик яхшы хәтерли:

– 1998 елга «Татнефтепродукт» предприятиеләре приватизацияләнгән иде инде. Үзенең Казан үзәгендәге офис бинасы гына калган. Чынлыкта кабат җыелган команда һәм республика җитәкчелеге ярдәме белән эзлекле, катлаулы эш башланды, аның төп максаты компанияне саклап калудан гыйбарәт иде. Беренче эш итеп, холдингка акцияләрнең контроль пакетын кайтару өчен, һәр директор белән аерым-аерым сөйләшергә туры килде. Параллель рәвештә республикада заманча ягулык салу станцияләре челтәре концепциясен үстерү буенча зур эш алып барылды: яңа АЗСлар төзелде, искеләре үзгәртеп корылды. Ул чакта бер ел эчендә генә дә без 10нан артык АЗС төзедек, 15кә якынын яңартып кордык. Һәм бу елдан елга кабатланып торды.

Компания тулысынча диярлек үзенең АЗСлар челтәрен яңартты, 56 яңаны төзеде һәм гамәлдә булган 59 станцияне үзгәртеп корды. Бу «Татнефтепродукт» Холдинг компаниясе» АҖгә Татарстанда бик тиз үсеш алган нефть продуктларын куллану базарында үз позицияләрен саклап калырга һәм республиканың башка операторлары белән уңышлы көндәшлек итәргә мөмкинлек бирде. Барысы да клиентка, хезмәт күрсәтүне яхшыртуга һәм объектларның куркынычсыз эшләвен тәэмин итүгә юнәлтелде. Без республикада нефть продуктларын ваклап сату базарында иң эре операторларның берсенә әверелдек. Предприятие өчен катлаулы булган бу чорда коллегаларымның югары потенциалы ачылды, бездә көчле креатив команда оешты. Мин ул чакта оештырган эшебез белән горурланам. Һәм үзләрен тулысынча эшкә багышлаган хезмәткәрләремә мин бик рәхмәтле.

Вакытлар үзгәрә, тормыш та, мәгълүм булганча, бер урында тор-

Реклама

Фото «Татнефтепродукт» ХК» АҖннән алынды.

мый. Замана чынбарлыгы шундый: бүгенге шартларда нефть продуктлары белән тәэмин итү системасы бары тик нефть табудан башлап, аны эшкәртү һәм сатуга кадәр тулы циклга ия булган вертикаль интеграцияләнгән компанияләр эчендә генә үсә ала. Шуңа күрә без, республикада нефть продуктларын ваклап сату базарында иң эре операторларның берсе буларак, «ТАИФ» Компанияләр төркеме составына кердек.

Бүген компания нефть продуктлары белән күмәртәләп сәүдә итүдә махсуслаша, нефть продуктларын кабул итү, саклау, нефть продуктларын җибәрү һәм күчерү буенча хезмәтләр күрсәтә, махсуслашкан инженер-техник, эксперт һәм регламент эшләрен алып бара, шулай ук нефть продуктларына лаборатор сынаулар үткәрә.

ГАИЛӘСЕ ТУРЫНДА

Рөстәм Наилевич үзе әйтүенчә, аңа тормышта дөрес юнәлеш сайларга һәм профессиясендә уңышка ирешергә гаиләсе ярдәм иткән. Аны да, энекәшләре Илһам белән Азатны да әти-әниләре: «Нинди генә эшкә тотынсаң да, намус белән эшлә», – дип өйрәткән. Алар үзләре дә тырышлыкта һәм максатчанлыкта үрнәк булып торган: әниләре, Ләлә Габделхаковна, бер сайлаган эшенә хыянәт итмичә, китапханәче булып эшләгән. Әтиләре Наил Закирович күп еллар буе Арча һәм Әтнә районнарында хуҗалык җитәкчесе булган. Ныклы абруйга ия әтиләре бүген дә улларына зирәк киңәшче булып тора.

Рөстәм Наилевич энергиянең төп чыганагын әти-әнисе, хатыны, уллары, туганнары, оныклары белән аралашудан таба. Тату гаилә күп нәрсәләргә өйрәтә.

КЕШЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮ ТУРЫНДА

Ике ел элек ТР Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Сабиров янына бер кеше үзенең борчуы белән килә: паспортсыз да, акчасыз да калган, Волгоград өлкәсенә – өенә кайтып китәрлек чамасы юк... «Өч мең җитәме?» – депутат, уйлап та тормыйча, аңа акча суза. Күптән түгел ул рәхмәт әйтергә дип кабат килә: «Беләсезме, сез биргән акча һәм хат шулкадәр булышты! Документларымны торгыздым, җиремне, өемне кайтарып ала алдым...» – ди.

Уңышларга ирешкәч тә, Сабировлар кече ватаннарын онытмый. Аларның Әтнә ягындагы туган авылларында юлларга асфальт җәелгән, мәчет, мәктәп һәм балалар бакчасы төзелгән.

Балачагыннан җирдә үскән Рөстәм Сабиров иң мөһиме – икмәк дип саный. Шуңа күрә дә республика аграрийларына үз вакытында һәм даими рәвештә ягулык-майлау материалларын җиткереп тору – «Татнефтепродукт» ХК АҖ өчен һәрвакыт өстенлекле урында. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, алар авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен язгы чәчү һәм урып-җыю чорында тотыла торган барлык ягулыкның яртысы белән тәэмин итә.
Рәсемдә күптәнге партнёрлар – «Татнефтепродукт» ХК АҖ генераль директоры Рөстәм Сабиров һәм ТР вице-премьеры, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов.

СПОРТ ТУРЫНДА

Гольф, тау чаңгылары, бильярд, шахмат, хоккей – Рөстәм Сабировның мавыгулары моның белән генә чикләнми әле. Рөстәм Наилевич үзе дә, уллары Руслан белән Рамил дә хоккей белән мавыга. Тыгыз эш графигына да карамастан, атнага ике-өч тапкыр бозга чыгарга җай табалар. Республика Президенты командасының уенчысы статусы һәрвакыт яхшы физик формада булуны таләп итә.

Рөстәм Наилевич җитәкчелегендәге «Татнефтепродукт» ХК АҖ республика спортчыларына актив ярдәм күрсәтә. Коллегалары әйтүенчә, Татарстан спортының дөнья дәрәҗәсенә чыгуында Сабировның аерым роле бар. Әйтик, компания 15 тапкыр Россия чемпионы булган «Динамо» чирәм хоккее командасына спонсорлык ярдәме күрсәтә, Рөстәм Сабиров анда күп еллар президент (соңгы 10 елда – вице-президент) булып тора.

Сабировларның зур һәм тату гаиләсе.

Фото Сабировларның гаилә архивыннан алынды.

«Татнефтепродукт» ХК АҖнең тату коллективы үзенең генераль директорын 60 яшьлек юбилее белән котлый! Сезгә, якыннарыгыз һәм кадерле кешеләрегезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек телибез!

Айрат Фәррахов,
VII чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, медицина фәннәре докторы, февральдә үзенең 50 яшьлеген билгеләп үтә.

Искәндәр Миңнуллин,
«Республика тире-венерология клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы

Милләт сәламәт булсын өчен

– Хөрмәтле Айрат Зәкиевич, диспансерның барлык коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлый алуыма шатмын. Бу бәйрәм – Сезнең Татарстан һәм Россиянең сәламәтлек саклау тармагына керткән өлешегезне билгеләп узу өчен күркәм бер сәбәп.

Сез бар гомерегезне медицина өлкәсенә багышладыгыз. Искиткеч эшсөючәнлек, эрудиция һәм табиблык сәләте бәрабәренә Сез бик шәп хирург, галим, ә аннары республика сәламәтлек саклау тармагының җитәкчесе дә булдыгыз. Ул вакытта Татарстанда бу юнәлешне камилләштерү программасы уңышлы тормышка ашырылды һәм бик күп сандагы инновацияле проектлар гамәлгә куелды. Медицина ярдәменең югары технологик төрләрен үстерүдә алга китү, хастаханәләр һәм медицина үзәкләрен үзгәртеп кору, аларны заманча, сыйфатлы җиһазлар белән тәэмин итү, зур-зур дәвалау-диагностика комплекслары булдыру… Болар барысы да Сезнең колачлы фикер йөртү, дөрес карарлар кабул итү һәм медицина учреждениеләре җитәкчеләре белән уртак тел таба алу сәләтегез ярдәмендә генә мөмкин булды.

Республика тире-венерология клиник диспансерында да ул елларда бер төркем көнүзәк проект чынга ашырылды. Диспансер үзгәртеп корылды, Казанда яңа тире-венерология дәвахәнәсе, заманча гистология лабораториясе ачылды, Россиядә беренче булып чит ил гражданнары өчен «бер тәрәзә» принцибы нигезендә медицина тикшерүе үткәрә торган үзәк ачылды.

Безнең өлкә бүген дә тик тормый. Республика тире-венерология хезмәтенең 2018 елдан 2025 елга кадәр үсеш стратегиясе эшләнгән. LA ROCHE-POSAY фондының «Пациентларның үз-үзен конфликтлы тотышы очракларына карата табибларның эмоциональ тотрыклылыгын формалаштыру» дип исемләнгән яңа халыкара программасы кысаларында дерматология өлкәсендәге иң альтруистик проект өчен алган грантыбыз конфликтология һәм стресска каршы торучанлык буенча табиблар өчен бик әһәмиятле

тренинглар уздырырга мөмкинлек бирде. Казанда 6000 кв. метр мәйданлы, 6 катлы яңа диспансер бинасы төзергә планлаштырабыз. Бу исә барлык стационар бүлекчәләрне һәм лабораторияләрне бер түбә астында тупларга мөмкинлек тудырачак. Күп функцияле миграция үзәге ачуга әзерләнә. 2018 елда «Дустанә дәвахәнә – Татарстан стандарты» проекты буенча Казанның өч дәвахәнәсендә һәм республикадагы тире-венерология диспансерларының биш филиалында капиталь ремонт ясалды. Соңгы елларда республикада күбесенчә җенси юл белән күчә торган инфекцияләр һәм йогышлы тире авырулары тотрыклы рәвештә кимүгә бара. Ә бу – эшебезнең иң төп нәтиҗәсе.

Хөрмәтле Айрат әфәнде! Татарстанлыларның сәламәтлеге өчен Сезнең ният-теләкләр белән чыннан да күп нәрсә эшләнде. Һәм бүген, РФ Дәүләт Думасында республикабыз сайлаучыларының вәкиле булып, Сез медицина тармагында, ил халкының сәламәтлеген саклау өлкәсендә иң мөһим мәсьәләләрне чишү эшен дәвам итәсез. Форсаттан файдаланып, Сезнең үзегезгә дә саулык, тормыш сөючәнлек, ният һәм проектларыгызның чынга ашуын телибез.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ
Реклама

Һәрчак кирәкле һәм бәясе юк тәҗрибә

Илгиз Әхмәтҗанов,
«Республика наркология диспансеры» Дәүләт сәламәтлек саклау автоном учреждениесенең баш табибы

– Хөрмәтле Айрат Зәкиевич, Татарстанның сәламәтлек саклау өлкәсендәге мактап телгә алырлык бүгенге эш нәтиҗәләрендә, берсүзсез, Сезнең дә зур хезмәтегез бар. Республикада Сезнең инициатива белән тормышка ашырылган бик күп проектлар медицина хезмәте күрсәтү сыйфатын яхшыртуга булышлык итте. Бу сүзләр 2017 елда үзенең 40 яшен билгеләп үткән безнең диспансерлык хезмәтенә дә кагыла. Татарстанда наркологик авыруларга бер-берсен тулыландыра торган ярдәм күрсәтү системасы булдырылды. Авыруларны тернәкләндерүнең төрле тарафларын күз уңында тоткан комплекслы ысуллар куллану һәм наркология хезмәтенең эшен оештыру наркологик ярдәмнең куллану мөмкинлекләрен һәм нәтиҗәлелеген арттырды.

Республика наркология диспансерының «Россиянең иң яхшы 100 товары» һәм «Татарстанның иң яхшы 100 товары» конкурсларындагы «Халык өчен хезмәт» номинациясендә җиңү яулавы да дәвалау учреждениесе күрсәтә торган медицина хезмәтенең югары сыйфаты турында сөйли. Без наркомания һәм эчкечелекнең таралуын булдырмый калу өчен профилактик эш алып баруга бик зур игътибар бирәбез. Бу юнәлештә эш алып бару өчен руханиларны, эш белән тәэмин итү хезмәтен, иҗтимагый оешмалар һәм фондларны җәлеп итәбез. Россиядә беренче булып, безнең диспансер базасында тормышка җайлашу һәм эшкә урнаштыруны колачлаган җәмгыятькә кайтару (ресоциализация) моделе уңышлы сынау узды. Диспансер – Татарстан Республикасы ресоциализация фондын оештыручыларның берсе. Бу фонд авыр хәлгә тарыган затларга махсус ярдәм программасын әзерләү һәм гамәлгә ашыру белән шөгыльләнә. Пациентлар тернәкләнеп аякка баскач, зарарлы гадәтләргә урын булмаган тулы канлы, нормаль тормышка яңадан кайтсын өчен, кулыбыздан килгәннең барысын да эшлибез.

Хөрмәтле Айрат Зәкиевич! Республиканың һәм Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгында, Россиянең Финанс министрлыгында туплаган бай тәҗрибәгез бүген илебез парламентында да кирәк. Ләкин читтә вакытта да безнең өчен, Татарстан табиблары өчен, Сез элеккечә хезмәттәшебез булып каласыз. Республика наркология диспансеры коллективыннан 50 яшьлек бәйрәмегез уңае белән иң ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз: саулык, игелек, муллык һәм озын-озак иҗат гомере телибез Сезгә!

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Реклама

Илдус Мостюков,
галим-конструктор, Социалистик Хезмәт Герое, «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасы рәисе, март аенда 90 яшен билгеләп үтә.

Фото: Ольга Туманская

Тормышын һәм талантын – Ватанга!

Владимир Гинсбург,
«Казан электротехника заводы» ГАҖ генераль директоры

Фото: Михаил Козловский

– Хөрмәтле Илдус Шәйхелисламович! Бар коллективыбыз һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 90 яшьлек олы юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм! Сез – Ватан мәнфәгатьләрен һәм аның куркынычсызлыгын һәрнәрсәдән өстен куйган һәм күңелегез белән хәзер дә аңа тугрылыклы булып калган кеше. Күренекле галим, Россия хәрби фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы буларак, Сез күп еллар дәвамында гаять зур дәүләти әһәмияткә ия мәсьәләләр башкардыгыз. Турыдан-туры Сезнең кул астында бердәм гомумгаскәр «Пароль» дәүләт радиолокацион тану системасы уйлап табылды һәм җитештерүгә куелды.

Шуннан бирле, инде менә кырык елга якын, әлеге система армия һәм флотка хезмәт итә. Россиядә генә түгел, ә союздаш илләрдә дә! Сезнең төп хезмәт җимешегез дәүләтне саклауда кулланыла торган иң мөһим чараларның берсенә әйләнде! Аннан да яхшырагы әлегә кадәр уйлап табылмады! Искиткеч катлаулы мәсьәләне шулкадәр яхшы чишкән өчен СССР Радиосәнәгать министрлыгының Казан фәнни-тикшеренү электр физикасы институты (хәзер «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, ә Сез Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булдыгыз. «Радиоэлектроника» фәнни-тикшеренү институты бу көнгә кадәр төп үзәк булып кала бирә. Ул СССР таркалган чорны да, авыр 90 нчы елларны да уздырып җибәрә алды. Ул әле һаман да эшен туктатмый, һәм монда Сезнең өлешегез дә бар!

Сез директор булып торган утыз ел дәвамында институт өчен «Пароль» системасы һич тә бердәнбер зур проект түгел иде. Аның белән бергә бик күп өр-яңа махсус техника үрнәкләре ясалды, һәм алар халык хуҗалыгында кулланылыш тапты. Сез 50 фәнни хезмәт һәм 24 төрле уйлап табуның авторы! Илебез фәне, сәнәгате һәм оборонасы каршындагы әлеге казанышларыгыздан тыш, Сезнең кешеләр алдында да аерым мактауга лаек хезмәтләрегез бар. Институт хезмәткәрләре Сезне бүген дә яхшы сүз белән искә ала, чөнки илкүләм әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишкән вакытларда да, Сез кешеләр турында онытмадыгыз. Йортлар, балалар бакчалары, тулай тораклар, пионер лагерьлары, ял базалары төзеттегез! Институтка өметле яшь галимнәрне җәлеп итеп, ул елларда штатны ун тапкырдан күбрәккә арттыра алдыгыз! Шуңа да карамастан, Сез һәрвакыт гаҗәеп тыйнак һәм тормышта талымсыз кеше булдыгыз, әле дә шундый булып каласыз. Бу тирән ихтирам уята торган сыйфатлар.

90 нчы елларда, ветераннарны борчыган проблемалардан йөз чөермичә, Сез «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасының идеологы һәм аны оештыручы булдыгыз. Менә инде утыз ел буена диярлек ул яшьләргә патриотик тәрбия бирә, тарихыбызны ялганга төреп күрсәтүгә каршы көрәшә һәм башка бик күп мәсьәләләрне хәл итә.

Хөрмәтле Илдус Шәйхелисламович! Сез Россия һәм Татарстанга һәрвакыт тугрылык белән хезмәт иттегез. Сезнең катнашта башкарылган эшләр – кешелек куәтенең ачык чагылышы. Үзегезгә дә, якыннарыгызга, кадерле кешеләрегезгә дә ныклы сәламәтлек телибез!

Фото «Казан электротехника заводы» ГАҖ маркетинг бүлегеннән алынды

Фото: Игорь Глазырин

Милли горурлык

Альберт Гыйльметдинов,
КМТТУ-КАИ ректоры

Хөрмәтле Илдус Шәйхелисламович!

Шәхсән үз исемемнән, барлык студентлар һәм укытучылар коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихластан котлыйм!

Сезнең язмышыгыз һәм бөтен эшчәнлегегез Ватанга, аның куркынычсызлык мәнфәгатьләренә хезмәт итү белән тыгыз бәйләнгән. Сез – Россия Хәрби фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, хөрмәтле галим, җәмәгать эшлеклесе. Илебезне саклауда мөһим роль уйнаган гомумгаскәр «Пароль» бердәм дәүләт радиолокацион тану системасын эшләү һәм җитештерүгә кую Сезнең исем белән турыдан-туры бәйләнгән. КМТТУ-КАИның Мактаулы профессоры булуыгыз, һәм үзегез белдергәнчә, нәкъ менә безнең университетның Сезгә «тормыш юлламасы» биргәнлеге белән чиксез горурланабыз. Бер әңгәмәгездә мондый сүзләр яңгырады: «КАИда мин тормышымны билгеләргә булышкан белемнәрне алып чыктым».

Студентларыбыз арасында күңел биреп уку һәм эшләүгә, актив патриотик позициядә торуга һәрчак зур омтылыш булды. Шуңа күрә Сезнең шикелле галим кешедән мондый ихлас сүзләр ишетү – уку йортыбыз өчен зур дәрәҗә. Сез бар талантыгызны, мөмкинлекләрегезне һәм тирән белемегезне СССР Радиосәнәгать министрлыгының үзегез җитәкләгән Казан фәнни-тикшерену электр физикасы институтының (хәзер «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге) искиткеч эш нәтиҗәләренә ирешүенә генә юнәлтеп калмадыгыз. «Пароль» системасы белән беррәттән, монда бик күп өр-яңа махсус техника төрләре ясалды һәм алар халык хуҗалыгында кулланылыш тапты. Сез күпсанлы фәнни хезмәт һәм уйлап табулар авторы да әле. Сезнең кул астында өметле яшь галимнәр зур энтузиазм белән хезмәт куйды.

Яшьләр, студентлар белән бүген дә бик теләп һәм күп аралашасыз. Мактаулы исемнәрегезгә, дәрәҗәләрегезгә карамастан, көн саен нәрсәгә дә булса өйрәнүне һич тә оят санамыйсыз. Татарстан Республикасы һәм Россия өчен югары профессиональлеккә ия фән һәм техник кадрлар хәзерләүнең көнүзәк мәсьәләләрен КМТТУ-КАИның әүвәлгечә Сезнең белән хезмәттәшлектә чишүенә горурланабыз.

Хөрмәтле Илдус Шәйхелисламович! Сез – милли горурлыгыбыз, абруйлы дәүләт эшлеклесе һәм гаҗәп зыялы кеше. Бу сыйфат Сезгә зур фәнни уңышларга ирешергә, хезмәттәшләрегез, дусларыгыз һәм укучыларыгызның хөрмәтен яуларга ярдәм итте. Шундый күркәм көндә Сезгә яңа җиңүләр өчен көч-куәт телибез. Ныклы сәламәтлек, муллык һәм җан тынычлыгы насыйп булсын!

Фото КМТТУ-КАИдан алынды

PRESSA.RU

Андрей Поминов,
Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, мартта 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Фото: www.mon.tatarstan.ru

Альберт Гыйльметдинов,
КМТТУ-КАИ ректоры

Белем һәм тәҗрибә – бәһасез ресурс

Хөрмәтле Андрей Иванович, Сезгә барлык студентлар, укытучылар һәм үз исемемнән 60 яшьлек бәйрәмегез белән тәбрикләүләр ирештерүемә шатмын. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары вазыйфасында сез лаеклы рәвештә абруй һәм хөрмәт казандыгыз. Моңа югары һөнәри осталыгыгыз, принципиальлек, тирән белем һәм тәҗрибәгез булышлык итә. Сез узган хезмәт юлы, җаваплы урыннардагы нәтиҗәле эшчәнлегегез тырышлык һәм хезмәткә тугрылык үрнәге булып тора.

Профессиональлек, эрудиция һәм аналитик фикерләү сәләтегез Сезгә мәгариф системасындагы актуаль мәсьәләләрне чишүнең нәтиҗәле юлларын табарга мөмкинлек бирә. Киләчәктә республикабыз икътисадын үстерергә сәләтле белгечләр хәзерләү эшендә без һәрдаим Сезнең ярдәмне тоябыз. Сез һәрвакыт нигезле, дәлилле әңгәмәгә әзер.

Тормышта сайлап алган эшегезгә күңел салып хезмәт кую, куәтле максатлар кую һәм аларга ирешү осталыгы белән теләгегез өчен, форсаттан файдаланып, рәхмәт белдерәм. Иң кыю уй-ниятләрегезнең, проект һәм планнарыгызның чынга ашуын телим. Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет һәм игелекләр телим!

Реклама

Фото КМТТУ-КАИдан алынды

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

PRESSA.RU

САТЫШ: БҮТӘНЧӘ ЯШӘҮ

Республиканың кайсы гына авылына барып чыксаң да, бер үк проблема турында сөйлиләр: яшьләр юк, балалар тумый. Саба районының Сатыш авылында исә моның киресе күзәтелә: һәр ике йортның берсендә яшь гаилә яши. Узган елда 16 сабый туса, яңа елның ике аенда гына да 14 булачак ана табиб күзәтүенә куелган. Быел балалар бакчасын зурайтырга җыеналар, чөнки урыннар җитми. Башкалар: «Авыллар бетә, нишләргә?» – дип уфтанган арада Сатышта бу проблемадан котылу юлын тапканнар.

Автор:
Руфия Фазылова

«КАРТИНАЛАРНЫ БҮЛӘККӘ ТАРАТАМ»

Сатыш зур һәм төзек авыл. Биредә 226 хуҗалык исәпләнә, авылда 686 кеше яши. Урта мәктәп эшли. Биредә бөтен төр социаль, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары бар. Безнең исә әлегә кадәр башка авылларда очратмаган һөнәр ияләрен күрәсебез килде. Шундыйларның берсе – рәссам Рамил Әбүбәкеров. Сатышта туып-үскән егет. Өч бала әтисе. Авыл мәдәният йортында газ операторы булып эшли. Гап-гади авыл кешесе. Рәсем сәнгате буенча махсус белем алмаган, хәтта түгәрәкләргә дә йөрмәгән. Ә ясаган картиналарын күргәч, аның осталыгына сокланасың! Менә бит ул Аллаһы Тәгалә биргән сәләт!

– Мин аларны үзем өчен генә ясыйм, – дип тыйнак кына елмая Рамил. – Сату-фәлән дигән уйның башыма да килгәне юк. Бары бүләк итәм. Авылда мин ясаган картиналар бик күп. Абый Яшел Үзәндә яши, яңа гына әллә ничә картинамны алып китте.

– Хезмәт бит ул. Ни өчен картиналарыгызны бушка таратасыз? – дим.

– Аларны ДВП тактасына гына ясыйм, киндер сатып алганым юк. Чын картина булсын өчен сыйфатлы материал, рамнар да кирәк. Бу эш белән ныклап шөгыльләнү, булдырасың, диючеләр бар. Тик мин моңа әзер түгел, димме, һәрхәлдә әлегә...

Рамил Әбүбәкеров кечкенәдән рәсем ясаган. Мәктәптә, Мәдәният йортында берәр чара уңаеннан рәсем ясарга, язарга кирәк булса, гел аннан үтенгәннәр. Аның сәнгать училищесына китәргә дә теләге булган. Тик әнисе сүзен тыңлап авылда – төп йортта калган.

– Армиядән кайткач, укырга китәм, дигән иде, җибәрмәдек, – дип сүзгә кушылды җирле рәссамның әнисе Зөһрә апа Әбүбәкерова. – Ул да читкә китсә, без нишләрбез, дидем... Ирем Исхак белән ике ул, бер кыз үстердек, Рамил – төпчегебез. Кызлардан да акыллырак булды ул. Эчми, тартмый. Бер каршы сүз әйткәне булмады. Хәзер дә шулай, колак ишетмәсен. Ул яктан бик бәхетле мин, талашып яшәмәдем. Ирем дә «эх» дип тә әйтмәде.

– Бер картинаны ясау өчен күпме вакыт кирәк? – дим Рамилгә.

– Төрлечә була. Өч көндә дә ясыйм, бер атна да. Рәсем ясау белән эшләр беткәч, кышка кергәч шөгыльләнәм. Җәй көне картина ясарга вакыт юк, бакчаны карыйсы, печән әзерлисе...

Фото: Лилиана Вәлитова

1

2

– Яз әле, яз кызым, улымның матур рәсемнәрен бөтен халык күрсен, – дип, безнең әңгәмәне сөенеп тыңлап утырды Зөһрә апа.

Башына ак яулык бәйләгән бу анадан җылы бер нур бөркелә. Зөһрә апага 75 яшь тулган икән, ул Сатыш авылында туып-үскән. Гаиләдә сигез бала булганнар, бүгенге көндә алты туганы исән-сау. Ундүрт яшеннән фермада эшли башлаган.

– Безнең йорт ферма буенда гына иде, – дип сөйләде Зөһрә апа Әбүбәкерова. – Бригадир абый: «Сеңлем, бозау карарга кер әле», – дигәч каршы килмәдем. 1957 ел иде ул. Тормышлар авыр. Әзгә дә риза булып йөрисең. Азрак эшләгәч, сыер саварга алындым. Хайваннарга ашлыкны чиләк-көянтә белән ташыдык. Көянтәгә – ике, кулга тагын бер чиләк асасың. Ашлыкны улчәүгә куйгач, барысы бергә алтмыш кило була торган иде. Унҗиде яшь тулгач, үз авылыбыз егетенә – Исхакка кияүгә чыктым. Бик рәхәт яшәдек. Ирем дә фермада эшләде. Гомер буе күп итеп мал-туар асрадык. Әле Аллага шөкер, хәзер дә тик утырмыйм. Маллар янына да чыгам, җәен килен белән күп итеп җиләк җыябыз, печән чабабыз. Исән-сау булырга насыйп итсен, балам...

Зөһрә апа сөйләшергә ярата. Килене белән улын да мактап кына сөйләде. Гомумән, шөкрана кылып яши торган күркәм холыклы татар апасы ул! Дөнья ямен күрә белә. Төпчек улы Рамилнең энә шундый гаҗәеп картиналар ясавы да әнисеннән күчкән кебек тоелды: Зөһрә апа балаларын әчке матурлыкны тоемларга өйрәткән, күрәсең.

ГАСЫРЛАР СЕРЕ

Сатыш борынгы мәдрәсәсе белән даны еракларга таралган сирәк авылларның берсе булып тора. 100 елдан артык волость үзәге булып, күп шәхесләр үстергән авыл ул. Сатыш турында китап та бар. Әле яңарак кына дөнья күрде. «Сатыш – гасырлар аша. 1170-2017 еллар» дип атала ул. Дөресен генә әйткәндә, Сатыш белән кызыксынуыбыз да әлеге китап кулга кергәч башланды. Китап авторларының берсе – бүгенге көндә Казанда яшәүче икътисад фәннәре кандидаты, Казан дәүләт энергетика университеты доценты Фәнил Гадрахманов. Ул Сатышта туып-үскән.

– Авылның тарихын өйрәнүдә унбер галим катнашты, – диде Фәнил әфәнде.

Авыл тарихы китапларын язганда күп очракта төгәл елларны күрсәтү авыр. Сатыш белән дә шулай. Китап авторлары авылны 1170 нче елларда оешкан дип яза, әлбәттә, бу якынча дата. Берәү дә «Сатышка 1170 нче елларда нигез салынды» дип язып калдырмаган. Ни өчен шул чор атала соң? Беренчедән, 2017 елның май-июнь айларында бу өлкәдә тәҗрибәле галим Альберт Борханов җитәкчелегендә казу эшләре үткән. Шулвакыт Сатыштагы Төмшә елгасының Саба суына кушылган урынында XII гасырның икенче яртысына караган авыл нигезләре табыла. Һәм тагын археологлар җир астында яткан бакыр, тимер калдыклары, кадак, бизәнү әйберләре, шулай ук ат, сыер кебек мөгезле эре терлек сөякләре калдыкларына да дә юлыгалар. Күп материаллар туплангач, галимнәр белән авылның иң актив кешеләре җыелып, Сатыш ХП гасырнын икенче яртысының уртасында оеша дигән фикергә киләләр.

– Авылдашларбыз Сатышның оешкан вакыты дип 1170 елны алырга булдылар, – ди Фәнил әфәнде. – Һәрхәлдә, бу шартлы сан. Бер ел эчендә генә авыл оеша алмый. Әмма фәнни, тарихи өйрәнүләр шуны дәлилли.

Китап авторы тагын менә нинди кызык фикерләр әйтте:

– Күңелне иң әрнеткәне: Сатышны XVIII гасырда оешкан дип, ә якын гына урнашкан рус авылларын XVI гасырда оешкан дип, төгәл саннар куялар. Рус авылларының күбесе бүген юкка чыкты. Ә Сатышыбыз яши. Фикер сөрешләре мондый булган галимнәр сүзенә таянсак, без руслардан соң килеп утырган килмешәк халык булып чыгабыз. Китапны язганда, тарихчылар белән бергәләп моңа нокта куярга булдык. Әбрар Кәримуллинның «Саба якларының мең елдан артык зур тарихы булуын, аның Болгар дәүләте чорында ук данлы зур төбәк икәнен онытмыйк» дигән фикеренә таяндык. Ә иң кызыклысы: Казан университеты типографиясендә басылган 1877 елгы IV археологик съезд материаллары файда булды.

1. – Картиналарны өч көндә дә, бер атна да ясыйм. Рәсем белән эшләр беткәч, кышка кергәч шөгыльләнәм. Җәй көне картина ясарга вакыт юк, бакчаны карыйсы, печән әзерлисе, – ди Рамил Әбүбәкеров.

2. – Яз әле, яз кызым, улымның матур рәсемнәрен бөтен халык күрсен, – дип, безнең әңгәмәне сөенеп тыңлап утырды Зөһрә апа.

PRESSA.RU

1. Кәҗә фермасында ике апа да йөри иде: Раушания Габдрахманова белән Зөһрә Әхмәдуллина бергә эшли икән.

2. Җәй көне кымызга ихтыяҗ күбрәк, – ди Раушания Гыйззәтуллина.

3. Шәхси эшмәкәр Ирек Әхмәтшин 2013 елда, дәүләттән бер тиен дә акча алмыйча, гараж салган, зур югыч алган һәм автомойка ачкан.

Сатыш авылында яшәүчеләр санын алуны ике чорга бүләргә була: 1800 елга кадәр һәм аннан соң. Ни өчен ике чор? Чөнки Сатышның сөрү җирләре, тегермәннәре күрсәтелгән 1798 елгы карта табыла.

– «Марс» колхозында ике мең гектар сөрү җире булып, шуның бер мең гектарын бабайлар урманнарны чистартып ясаганнар, калган бер мең гектары 1800 елдан алып Бөек Ватан сугышына кадәрге чорда барлыкка китерелгән, – ди Фәнил Габдрахманов. – 1834 елдан 1938 елга кадәр тугыз тапкыр халык санын алганнар. Әлеге мәгълүматларга ышансак, авылда 1800 елдан 1938 елга хәтле уртача 1674 кеше яшәгән, һәм алар 1798 елдан 1938 елга кадәр авылның сөрү җирләрен бер мең гектарга арттырганнар. Бер мең гектарны 1674 кешегә бүлсәк, 140 ел эчендә авылның һәр кешесе 59 сутый урманнан сөрү җире ясаган. Бу уртача күрсәткечне 1800 елга хәтле чорга туры китерсәк, 300 кешесе булган авылга бер мең гектар урманнан сөрү җире барлыкка китерү өчен 800 елга якын вакыт кирәк. Шуның нигезендә авылны X гасырда оешкан дип санарга була.

– Авылның борынгылыгы һәм Болгар дәүләте чорында яшәве турында бездән ерак булмаган шәһәр дә сөйли, – дип дәвам итә сүзен китап авторы. – Мамадыш районының рәсми порталында Борынгы Болгар шәһәре «Ак кирмән» (Мамадыштан Сатышка таба-20 чакрым) XII гасыр башында барлыкка килә, диелгән. Шәһәрләре булгач, аның авылы да оешкан инде...

Әлеге китапка танылган тарихчылар да бәя биргән. Әйтик, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков болай дип яза: «Сатыш авылы тирәләре Казан ханлыгы чорында яшәгән авыллар белән әйләндереп алынган. Мәсәлән, Мамалай авылында күн тиресенә язылган хан ярлыгы табыла. Аккүл-Бигәнәй авылы янында «ханнар зираты» дигән каберлек бар һ.б. Шуның өстенә, бу якларда Арча, Болгар вилаятендә билгеле булган Кирмәнчек (Ак Кирмән) шәһәре дә әллә ни ерак түгел. Ягъни Сатыш һәм аның тирә-якларында урнашкан авыллар борынгы авыллар рәтендә каралырга тиешләр».

КӘҖӘ МАЛ ТҮГЕЛ, ДИСӘЛӘР ДӘ...

Чал тарихлы Сатышта бүген йорт саен ике-өч сыер асрау – гадәти хәл. Аннан күбрәк мал тотучылар да байтак. Ике крестьян-фермер хуҗалыгы бар. Ләкин, кем әйтмешли, безнең сыер күргән бар, бу турыда сан саен диярлек язабыз. Игътибарыбызны икенче бер малкай җәлеп итте – Сатышта кәҗәләргә хөрмәт зур, хуҗалыкларда утызлап «сөтлебикә» асрыйлар. Ә иң гаҗәбе: авылда кәҗә фермасы бар. Дөрес, ул аерым бер хуҗалыкны түгел, ә «Саба» Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Сатыш бүлекчәсенә карый. Гади итеп әйткәндә, элеккеге колхоз инде. Сабада җирләргә, фермаларга агрохолдинглар хуҗа түгел, анда һаман да колхоз системасы буенча яшиләр. Әйе, исеме заманча яңгырый, тик җисеме барыбер элеккечә кала бирә. Халык та «колхоз» дип кенә сөйләшә. Менә шушы «Саба» җәмгыятенең Сатыш бүлекчәсенә 2011 елда дистә баш кәҗә алып кайтканнар. Җитәкчеләрнең максаты – бүлекчәдә төрле маллар үстерү, баш санын арттыру.

Кәҗә фермасында булганым юк иде, күрергә насыйп булды. Тыштан сыерлар яши торган бинаны хәтерләтсә дә, эче икенче төрле итеп эшләнгән. Савыла торган кәҗәләрне бергә, яшьрәкләрен аерым япканнар. Фермада ике апа да йөри иде: Раушания Габдрахманова белән Зөһрә Әхмәдуллина бергә эшли икән.

– Кәҗә акыллы һәм бик чиста хайван, – диде Раушания апа. – Махсус аппарат белән савабыз. Әнә, ферманың аскы ягында аерым бер бүлмә бар, шунда малларны сигезәрләп санап кертәбез дә тезеп бастырабыз. Тыңлыйлар, сөзмиләр дә.

Сатышта күпләр терлекчелектә, игенчелектә хезмәт куя. Сыер савучылар ике бригада булып эшли. Иртәнге дүрттән көндезге уникегә кадәр бер төркем, уникедән кичке сигезгә кадәр икенче төркем килә. Сыерларны өч тапкыр савалар. Сигез сәгатен тутырмыйча кеше эштән китәргә тиеш түгел!

– Кәҗә сөтен нишләтәләр? – дим Раушания апага.

– Саталар, кымыз ясыйлар. Яз-көз айларында атна саен Ка-

2



Яңа гына табадан төшкән «Сатыш – гасырлар аша. 1170–2017 еллар» китабы.

занга ярминкәләргә алып бардылар. Гади кешеләр дә сатып ала, кәҗә сөте бик файдалы бит. Аеруча аллергияле балаларга, тән авырулары булган олы кешеләргә эчәргә киңәш итәләр. Зәй кәҗәләренең (төре шундый – авт.) сөтеннән күпләргә ошамый торган үзенчәлекле тәм килми. Сөтне дә чагыштырмача күп бирәләр, тәүлегенә уртача өч-дүрт литр савабыз.

Кымыз ясау бүлмәсенә дә кереп чыктык. Моның белән Раушания Гыйззәтуллина шөгыльләнә икән. Махсус аппаратта көн саен йөз шешә кымыз ясый.

– Җәй көне кымызга ихтыяҗ күбрәк, – ди Раушания Гыйззәтуллина. – Эшчеләр дә кереп ала. Эсседә салкын кымыз тәмлерәк кебек.

– Эш тәртибен аңлатыгыз әле, – дим Раушания апага.

– 20–30 литр әчегән сөткә (закваска) шундый ук күләмдә кәҗә сөте салам. Шуңа азрак су өстим, чөнки кәҗә сөте майлы була. Аннан барысын бергә әлеге махсус машинада әйләндерәм. Бер сәгатькә якын әйләнгәч, эчемлек әзер була. Һәм шешәләргә тутырып ябып куям.

Саба кымызы төрле кибетләрдә сатыла икән. Ярты литрлы шешәнең бәясе 60 сум тора. Саклану вакыты – 15 тәүлек.

– Кәҗә мал түгел, дисәләр дә, мин бу хайванны яратам, – ди Раушания Гыйззәтуллина. – Өйдә дә кәҗә асрыйбыз. Сыерга караганда мәшәкате күпкә аз. Көн саен сөтле чәй эчәсең, ә аның файдасы!

...Язмам башында: «Сатышта яшьләрне авылда калдыру җаен тапканнар», – дигән идем. Аның сере бик гади – кешеләргә эш бар. Әлбәттә, Сатыш географик яктан уңайлы җирдә урнашкан. Халык җиде чакрым ераклыктагы Саба, күрше Теләче, Шәмәрдән бистәсенә йөреп эшли. Колхозда да йөздән артык кеше хезмәт куя. Ләкин биредә үз эшен башлаган кешеләр күп. Ике шиномонтаж, автосервис ачканнар. Сату-алу белән шөгыльләнүчеләр дә байтак. Мал асрыйлар. Барысы да – үз тырышлыклары белән.

Шәхси эшмәкәр Ирек Әхмәтшинны гына алыйк. 2013 елда, дәүләттән бер тиен дә акча алмыйча, гараж салган ул, зур югыч алган һәм автомойка ачкан. Бүген шунда матур гына эшләп ята, авылдашларына машиналар юа, вак ремонт эшләре белән дә шөгыльләнә.

– Әллә ни зур акчалар керми, әлбәттә, – диде Ирек абый. – Тик тормыш алып барырга җитә. Мәктәптән бушаган арада улым да булыша, авылда укытучы булып эшли ул. Берәүгә дә кеше китереп бирми. Махсус тимер тоткычлар ясаттым, келәмнәр дә юабыз. Тырышсаң, тәвәккәллек булса, теләсә кайсы өлкәдә яшәр өчен акча эшләргә була.

Ирек абыйның бу сүзләреннән соң нәрсәдер язу артык кебек. Менә шул.



3

PRESSA.RU

«Туган җирем Кайбыч районы Кошман авылында Утташ чаты, Уңар үзәнлеге, Гәрәй талы басуы, Шәрәп борыны, Сәет бабай үзәне, Изге кыз каберлеге, Керәшен зиратына бәйле кызыклы риваятьләр, телдән-телгә сөйләнеп, буыннан-буынга күчеп, бүгенгәчә яшәп килә», – дип язды безгә күптәнге авторыбыз Хәмидә Гарипова. Бүген шуларның берсе белән сезне дә таныштырып үтәбез.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ:

Гәрәй талы басуындагы фаҗига

Кайбыч белән Кошман авыллары арасындагы үр өстендә әби-бабаларымның балачагында бик җылы сулы түгәрәк күл булган. Тирә-юнендәге камышлыкта кыр үрдәкләре бала чыгарган. Мәрхәмәтле Гәрәй бабай күл тирәли яшь таллар утырткан. Игеннәр урылып, ашлыклар амбарларга салынганнан соң, тирә-юньдәге авылларда туйлар гөрли башлаган.

Морза Бәрлебашыннан Зур Урсакка килен төшерүче яшь кияү белән кашыгы-суы белән йотарлык чибәр килен, бер-берсенә сыенып, арка терәп утырган арбадагы бизәкле бирнә сандыгы өстенә йомшак юрган-мендәрләр өелгән булган. Җилдән җитез туй атлары яшь парны очыртып кына авылга алып кайтып килгәндә, бәхетсезлеккә күрә, каршыларына икенче бер пар очраган. Бу сөйгән ярын Кече Кайбычтан никахлап алып кайтырга сәфәр чыккан гашыйк егет булган. Аның бизәлгән тарантасында гармунчы янәшәсенә ут йөрәкле дуслары тезелешеп утырган, елкылдап торган тулпар атлар Гәрәй талы басуындагы көзгеле күл буендагы аланга ажгырып килеп кергән.

Бик борынгы мәҗүси йола буенча, туй атлары кара-каршы килгән очракта, кияү егетләре тиз генә арбадан сикереп төшеп, чит атларның камыт бавын кисеп өлгерергә тиеш булган. Бу җитезлеккә сынау гына түгел, ә киләчәктә камыт бавы киселгән пар аттагы яшь гаиләнең тормышы имин булмаячак, дигән инануга бәйле гамәл булган. Һәр ике яктагы кияү егетләре каударланып камыт бауларын кисеп җибәргән мәлдә аяк астындагы мәйданчык убылган, ә туй атларын кешеләре-ние белән җир йоткан. Ни кызганыч, бу яман хәлдән соң, Убыр авызы сыман ыржаеп торган тирән чокыр янәшәсендәге күлнең суы кипкән, Гәрәй таллары корыган.

АЙ КӘЕФЕ: **ЧАҢГЫ ЯРЫШЫ**

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!